Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Вәгазьләр һәм дәресләр

Түбән Кама 2009

# Кереш сүз

[illegible]

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребезнең ﷺ юлы. Барча яңалык — бидгать, вә барча бидгать — адашу һәм барча адашу утка илтә.

•يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلا تَمُوتُنَّ إِلا وَأَنْتُمْ مُسْلِمُونَ• آل عمران

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка хак тәкъвалык белән тәкъваланыгыз. Аңа итагать итегез, каршылык вә гөнаһ кылмагыз. Аны зикер кылыгыз, вә онытмагыз. Аңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!».**

•يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالا كَثِيرًا وَنِسَاءً وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا• النساء: ١

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Сезне бер нәфестән (Адәмнән) халык кылучы Аллаһка тәкъва булыгыз! Ул (Аллаһ), Адәмнең ﵇ үзеннән хатын (Хәваны) яратты, вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһка тәкъвалык кылыгыз, Ул — Аллаһ исеме белән бер–берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, һәм Аллаһ ризалыгы өчен сорагач кешенең кире какмаганлыгын беләсез. Шулай**

**булгач, Аллаһны зурлагыз вә якын туганлык җепләрен өзүдән сакланыгыз! Аллаһ бит сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче».**

•يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَقُولُوا قَوْلًا سَدِيدًا ! يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَمَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا• الأحزاب: ٧٠-٧١

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка тәкъва булыгыз, вә хак булган файдалы, дөрес сүзләрне генә сөйләгез! Аллаһ әйткәнчә эш кылсагыз, Аллаһ эшләрегезне вә гамәлләрегезне төзәтер, вә гөнаһларыгызны ярлыкар. Берәү чын күңелдән Аллаһка, вә Аның расүленә итагать итсә, ул кеше һичшиксез өстенлеккә вә изге теләгенә иреште».**

Дөреслектә, хәзерге заманда Аллаһ тәгаләгә якынайта торган гамәлләрнең берсе, ул — гади кеше дә, гыйлемлесе дә аңлый торган итеп кешеләргә гыйлем бирү һәм алар арасында пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтен тарату. Бу гамәлне тиешлечә итеп мәчет имамнары һәм мәдрәсә мөгаллимнәре эшли. Чөнки алар намаз алдыннан, яки намаздан соң аз гына булса да вакыт табып кешеләргә нәсыйхәт кылалар. Ошбулардан чыгып, мин бу китапны да, кешеләр намазларга җыелганда биш-ун минут булса да гыйлем алсыннар өчен дип әзерләдем. Чөнки гыйлемсезлек, кешегә тормышта да, ахирәттә дә төрле авырлыклар китерүгә сәбәп була. Аллаһ Раббыбыз ошбу эшләребезне Үзенең ризалыгы өчен ихлас кылып, динебезгә файдалы гамәлләрдән әйләсә иде. Бу китапта булган аз гына тырышлык, хәерлесе вә дөресе Аллаһ тәгаләдән:

•وَعَلَّمَكَ مَا لَمْ تَكُنْ تَعْلَمُ• النساء: ١١٣

Мәгънәсе: **«Аллаһ сиңа белмәгәнеңне өйрәтте».**

•وَلا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلا بِمَا شَاءَ• البقرة: ٢٥٥

Мәгънәсе: **«Аллаһ гыйлеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ теләгәнне генә белерләр».**

Ә инде китапта хата вә кимчелек булса — минем үземнән вә шәйтаннан:

•قُلْ هُوَ مِنْ عِنْدِ أَنْفُسِكُمْ• آل عمران: ١٦٥

Мәгънәсе: **«Әйт: «Бу үзегезнең нәфсегездән», — диген».**

•وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِلْإِنْسَانِ خَذُولا• الفرقان: ٢٩

Мәгънәсе: **«Шәйтан кешегә батылны матурлап вә хакны кабахәт кылып, алдап ташлап китәр булды».**

Йә Раббым! Барчабызга да һидәят-тәүфыйк бир! Кушканнарыңны үтәп, тыйганнарыңнан тыелып яшәргә насыйп ит!

Йә Раббым! Безне Үзеңнең туры юлыңнан алып бар, хакны хак итеп белгерт һәм безне хаклыкка якынайт, батылны батыл итеп белгерт һәм безне батылдан ерагайт. Коръән вә сөннәткә тотынучылардан кыл, һәм ихлас-тәкъва бәндәләреңнән әйләп, Үзеңнең рәхмәтең белән Фирдәвес Җәннәтләреңә керт! Әмин!

*Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи*

*Хатлар өчен: mullaniyaz@mail.ru*

## 🕮 Ихлас һәм ният хакында

•مَنْ كَانَ يُرِيدُ الْحَيَاةَ الدُّنْيَا وَزِينَتَهَا نُوَفِّ إِلَيْهِمْ أَعْمَالَهُمْ فِيهَا وَهُمْ فِيهَا لا يُبْخَسُونَ ۞ أُولَئِكَ الَّذِينَ لَيْسَ لَهُمْ فِي الآخِرَةِ إِلا النَّارُ وَحَبِطَ مَا صَنَعُوا فِيهَا وَبَاطِلٌ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ• هود: ١٥-١٦

Мәгънәсе: **«Берәү дөнья тереклеген вә тормышның матурлыгын гына теләсә, Без аларга дөньяви эшләренең файдасын дөньяда биреп бетерербез һәм аларга дөньяви эшләренә кимчелек китерелмәс. Әмма ахирәттә аларга уттан башка җәза булмас вә дөнья эшләре юкка чыгып, эшләгән гамәлләре батыл булыр».**

عَنْ عُمَر بن الخَطّاب رضي الله عنه قال: سَمِعْتُ رَسول الله ﷺ يَقول: «إنَّما الأعْمَالُ بالنّيات وإنّما لِكُلِّ امْرِئٍ ما نَوى فَمَنْ كَانَتْ هِجْرَتُه إلى الله وَرَسولِه فَهِجْرَتُهُ إلى الله وَرَسولِه وَمَنْ كَانَتْ هِجْرَتُهُ لِدُنْيا يُصِيبُها أَوْ امْرَأةٍ يَنْكِحُها فَهِجْرَتُهُ إِلى مَا هاجَرَ إِلَيْهِ» [ متفق عليه ]

Мәгънәсе: Гомәр бин әл-Хаттабтан ؓ: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Дөреслектә, барча гамәлләр дә нияткә карап бәяләнә, һәм дөреслектә, һәркемгә үзе ниятләгән нәрсә генә була. Кемнең һиҗрәте (күчеп китүе) Аллаһка һәм Аның расүленә булды икән — аның һиҗрәте Аллаһка һәм Аның расүленә булды, ә инде кемнең һиҗрәте дөнья нигъмәте яки никахланырга теләгән хатын-кыз өчен булды икән — аның һиҗрәте бары тик һиҗрәт кылган нәрсәсе өчен генә булды».***

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِي الله عَنْهُ قَالَ: سَمِعْتُ رسول الله صلى الله عليه وسلم يقولُ: «إنَّ أول النَّاس يُقْضَى يومَ القِيامَةِ عَلَيْهِ، رَجُلٌ اسْتُشْهِدَ فَأُتِيَ بِهِ، فَعَرَّفَهُ نِعْمَتَهُ فَعَرَفَهَا، قَالَ: فَمَا عَمِلْتَ فِيهَا؟ قَالَ: قَاتَلْتُ فِيكَ حَتَّى اسْتُشْهِدْتُ. قَالَ: كَذَبْتَ، وَلَكِنَّكَ قَاتَلْتَ لأنْ يُقَالَ: جَرِيءٌ! فَقَدْ قِيلَ، ثُمَّ أُمِرَ بِهِ فَسُحِبَ عَلَى وَجْهِهِ حَتَّى أُلْقِيَ فِي النَّارِ. وَرَجُلٌ تَعَلَّمَ العِلْمَ وَعَلَّمَهُ، وَقَرَأَ القُرآنَ، فَأُتِيَ بِهِ فَعَرَّفَهُ نِعَمَهُ فَعَرَفَهَا. قَالَ: فَمَا عَمِلْتَ فِيهَا؟ قَالَ: تَعَلَّمْتُ العِلْمَ وَعَلَّمْتُهُ وَقَرَأْتُ فِيكَ القُرآنَ، قَالَ: كَذَبْتَ، وَلَكِنَّكَ تَعَلَّمْتَ لِيُقَالَ: عَالِمٌ! وَقَرَأْتَ القُرْآنَ لِيُقَالَ: هُوَ قَارِئٌ، فَقَدْ قِيلَ، ثُمَّ أُمِرَ بِهِ فَسُحِبَ

عَلَى وَجْهِهِ حَتَّى أُلْقِيَ فِي النَّارِ. وَرَجُلٌ وَسَّعَ اللهُ عَلَيْهِ وَأَعْطَاهُ مِنْ أَصْنَافِ المَالِ، فَأُتِيَ بِهِ فَعَرَّفَهُ نِعَمَهُ فَعَرَفَهَا. قَالَ: فَمَا عَمِلْتَ فِيهَا؟ قَالَ: مَا تَرَكْتُ مِنْ سَبِيلٍ تُحِبُّ أَنْ يُنْفَقَ فِيهَا إِلاَّ أَنْفَقْتُ فِيهَا لَكَ. قَالَ: كَذَبْتَ، ولَكِنَّكَ فَعَلْتَ لِيُقَالَ: جَوَادٌ! فَقَدْ قِيلَ، ثُمَّ أُمِرَ بِهِ فَسُحِبَ عَلَى وَجْهِهِ حَتَّى أُلْقِيَ فِي النَّارِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Дөреслектә, Кыямәт көнне хөкем ителүче беренче кеше булып җиһәдтә һәлак булган кеше булыр. Аны китерерләр, һәм Аллаһ аңа нигъмәтләре турында искә төшерер һәм ул аларны таныр, ә аннары Аллаһ сорар: «Бу нигъмәтләргә шөкер итү йөзеннән син нәрсә кылдың?». Ул җавап бирер: «Мин Синең ризалыгың өчен һәлак булганга кадәр сугыштым!». Аллаһ әйтер: «Син ялганлыйсың, чөнки син, башкалар синең хакта: «Бу батыр кеше!», — дип әйтсеннәр өчен генә сугыштың, һәм алар шулай әйттеләр дә!» — аннан соң бу кешегә карата тиешле әмер бирелер, һәм аны йөзтүбән өстерәп Җәһәннәмгә ыргытырлар. Аннары белем алган, аны башкаларга өйрәткән һәм Коръән укыган кешене китерерләр, һәм Аллаһ аңа нигъмәтләре турында искә төшерер, һәм ул аларны таныр, ә аннан соң Аллаһ сорар: «Бу нигъмәтләргә шөкер итү йөзеннән син нәрсә кылдың?». Ул: «Мин Синең ризалыгың өчен белем алдым, аны башкаларга өйрәттем һәм Коръән укыдым», — дип әйтер. Аллаһ әйтер: «Син ялганлыйсың, чөнки син, башкалар синең хакта: «Бу кеше галим!», — дип әйтсеннәр өчен генә белем алдың, һәм Коръәнне (кешеләр): «Ул Карый!», — дип әйтсеннәр өчен генә укыдың, һәм алар шулай әйттеләр дә!» — аннан соң бу кешегә карата тиешле әмер бирелер, һәм аны йөзтүбән өстерәп Җәһәннәмгә ыргытырлар. Ә аннан соң, Аллаһ киң ризык һәм төрле байлыклар биргән кешене китерерләр, һәм Аллаһ аңа нигъмәтләре турында искә төшерер, һәм ул аларны таныр, ә аннан соң Аллаһ сорар: «Бу нигъмәтләргә шөкер итү йөзеннән син нәрсә кылдың?». Ул җавап бирер: «Мин ул байлыкны, акчалар-***

***ны Синең ризалыгың өчен, Син яраткан урыннарга сада-ка итеп таратудан туктамадым һәм бер генә дә мөмкин булган форсатны да калдырмадым». Аллаһ әйтер: «Син ялганлыйсың, чөнки син, башкалар синең хакта: «Бу кеше юмарт», — дип әйтсеннәр өчен генә кылдың һәм алар шулай әйтә иделәр!» — аннан соң бу кешегә туры килә торган әмер бирелер, һәм аны йөзтүбән өстерәп Җәһәннәмгә ыргытырлар».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Ният — барча гамәлләрнең дә нигезе булып тора, шуңа да кешенең гамәленең кабул булуы яки булмавы аның ниятенә нигезләнгән. Әгәр дә адәм баласы Аллаһка ихласлык белән, әҗер-савап өмет итеп һәм пәйгамбәребезнең сөннәтенә муафикъ рәвештә нинди дә булса гамәл кыла икән — кабул була иншәАллаһ. Ә кемнең инде нияте Аллаһ ризалыгы өчен булмаса, яки расүлебезнең сөннәтенә туры килмәсә, ул вакытта аның кылган гамәле файдасыз булыр, бәлки гөнаһ кына өстәр.

**Файдалар:**

**1)** Гамәлләрнең кабул булуына ихласлык һәм пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтенә муафикъылык шарт булып тора.

**2)** Ихласның әһәмияте зур, чөнки гамәл кабул булсын өчен, гамәлнең дөрес булуы гына җитми.

**3)** Ниятләрне һәргамәлгә дә дөресләп тору кирәк.

**4)** Ихлассыз, яки рия өчен кылынган гамәлләрнең хуҗасын Кыямәт көнендә хәсрәт көтә.

## 🕮 Гыйлемнең фазыйләте хакында

•قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لا يَعْلَمُونَ• الزمر: ٩

Мәгънәсе: **«Әйт: Гыйлемле кешеләр белән гыйлемсез кешеләр бертигез булырмы?».**

•يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنْكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ• المجادلة: ١١

Мәгънәсе: **«Сезнең арагыздан иман китереп итагать иткән вә гыйлем иясе булган (һәм гыйлемнәре белән гамәл кылган) мөэминнәрне, Аллаһ бу дөньяда да, ахирәттә дә зур дәрәҗәләргә күтәрер».**

•وَقُلْ رَبِّ زِدْنِي عِلْمًا• طه: ١١٤

Мәгънәсе: **«Әйт: Йә Раббым! Минем гыйлемемне арттыр!».**

وعَنْ مُعَاوِيةَ رَضِي الله عَنْهُ قَالَ: قالَ رَسول الله صَلى الله عَلَيْهِ وَسَلَّم: «مَنْ يُرِدِ اللهُ بِهِ خَيْراً يُفَقِّهْهُ في الدِّينِ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Мугавиядән ﵁ : пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ кемгә хәерлелекне (яхшылыкны) теләсә, ул кешене диндә фәһемле[1] кыла».***

عن أبي الدرداء رضي الله عنه قال: سَمِعْتُ رسولَ الله صلى الله عليه وسلم يقول: «مَنْ سَلَكَ طَرِيقاً يَبْتَغِي فِيهِ عِلْماً سَهَّلَ اللهُ لَهُ طَرِيقاً إِلَى الجَنَّةِ، وَإِنَّ المَلائِكَةَ لَتَضَعُ أَجْنِحَتَهَا لِطَالِبِ العِلْمِ رِضاً بِمَا يَصْنَعُ، وَإِنَّ العَالِمَ لَيَسْتَغْفِرُ لَهُ مَنْ فِي السَّماوَاتِ وَمَنْ فِي الأَرْضِ حَتَّى الحِيتَانُ في المَاءِ، وَفَضْلُ العَالِمِ عَلَى العَابِدِ كَفَضْلِ القَمَرِ عَلَى سَائِرِ الكَوَاكِبِ، وَإِنَّ العُلَمَاءَ وَرَثَةُ الأَنْبِيَاءِ، وَإِنَّ الأَنْبِيَاءَ لَمْ يُوَرِّثُوا دِينَاراً وَلاَ دِرْهَماً وَإِنَّمَا وَرَّثُوا العِلْمَ، فَمَنْ أَخَذَهُ أَخَذَ بِحَظٍّ وَافِرٍ» [أخرجه أبو داود والترمذي]

Мәгънәсе: Әбү Дәрдәдән ﵁: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Гыйлем эзләп юлга чыккан кешегә, Аллаһ тәгалә Җәннәткә юлны җиңеләйтә. Фәрештәләр гыйлем таләп итүченең гамәленнән ризалыкларын белдереп, канатларын җәяләр. Гыйлем иясенә барча нәрсә, хәтта судагы балык та истигъфар кыла (Аллаһтан гафу сорый). Гыйлем иясенең гыйбадәт кы-***

1 Гыйлемле, зиһенле, аңлы, акыллы һ.б.

***лучыдан өстенлеге, айның күктәге йолдызларга карата булган өстенлеге кебектер. Хакыйкатьтә, галимнәр — пәйгамбәрләрнең варислары, һәм алар (пәйгамбәрләр) динар да, дирһәм дә мирас итеп калдырмадылар, бәлки, алар мирас итеп гыйлем калдырдылар, кем ул мирасны алса — иң зур өлешне алган булды (пәйгамбәребез калдырган иң зур мирас — гыйлемдер, моннан да зуррак вә камилрәк мирас юктыр)».***

عن أبي هريرة رضي الله عنه أن رسول الله صلى الله عليه وسلم قال: «إذا ماتَ الإنْسانُ انْقَطَعَ عَمَلُهُ إلا مِنْ ثلاثٍ: صَدَقةٍ جارِيَةٍ، أوْ عِلْمٍ يُنْتَفَعُ به، أو وَلَدٍ صالحٍ يَدْعُو له» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кеше үлгәннән соң, өч гамәленнән башка барча гамәле дә киселә[2]: даими рәвештә әҗере килеп тора торган садака (мәсәлән: мәчет салдыру, дини китап бастыру һ.б.), яки үзе үлгәннән соң башка кешеләр файдалана ала торган гыйлем, яки Аллаһка аның өчен дога кыла торган изге балалар».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Шәргый гыйлем, динебездә бик тә зур вә олы урын алып тора. Шуның өчен дә Аллаһ тәгалә гыйлем таләп итәргә чакырды, һәм аны Аңа якынайта торган иң хәерле гамәлләрдән кылып, Җәннәткә керүнең сәбәбе итте. Гыйлем белән кеше Аллаһ тәгаләне, Аның шәригатен, кушканнарын вә тыйганнарын һәм динне торгызуны белә. Ошбулардан чыгып гыйлем ияләре пәйгамбәрләрнең варислары булды, чөнки пәйгамбәрләр үзләреннән соң шәригать вә дин гыйлемен мирас итеп калдырдылар. Кем шушы гыйлемне алырга теләсә — ул, пәйгамбәрләргә варис булды. Шуңа да Аллаһ тәгалә бер кешегә хәерлелекне (яхшылыкны) теләсә, аңа дин гыйлемен алуда җиңеллек бирә.

---

2 Ягъни, өч гамәлдән башка гамәлләрнең әҗер-савабы килеп торуы туктый

**Файдалар:**

**1)** Гыйлемнең һәм гыйлем ияләренең фазыйләте зур, чөнки галимнәр — пәйгамбәрләрнең варислары.

**2)** Динне аңлау — Аллаһ тәгаләнең кешегә яхшылыкны теләвенә дәлил булып тора.

**3)** Гыйлем таләп итү — Җәннәткә керүгә сәбәп булып тора.

**4)** Үзеңнән соң файдалы гыйлем калдыру — иң хәерле вә иң яхшы мирас булып тора, чөнки аның савабы, галим кеше үлгәннән соң да өзелмичә аңа ирешеп тора.

## Кешеләрне изгелеккә өндәүнең фазыйләте хакында

•هُوَ الَّذِي بَعَثَ فِي الأُمِّيِّينَ رَسُولاً مِنْهُمْ يَتْلُو عَلَيْهِمْ آيَاتِهِ وَيُزَكِّيهِمْ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ• الجمعة: ٢

Мәгънәсе: **«Ул — Аллаһ, укый-яза белми торган кавем эченнән үзләре кебек кешене — Мөхәммәдне ﷺ, дөньяның барча кешеләренә расүл итеп җибәрде, ул расүл — кешеләргә Аллаһ аятьләрен укый, вә аларны бозыклыклардан пакьлый һәм аларга Коръәнне, шәригать хөкемнәрен өйрәтәдер».**

•كُنْتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ• آل عمران: ١١٠

Мәгънәсе: **«Сез, кешелек дөньясына чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз. Кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өндисез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыясыз һәм Аллаһка иман китерәсез».**

عَنْ أبي مسعودٍ عُقْبَة بن عَمرو الأَنْصاري البَدْري رضي الله عَنْهُ قال: قالَ رَسول الله صلى الله عليه وسلم: «مَنْ دَلَّ عَلى خَيْرٍ فَلَهُ مِثْلُ أَجْرِ فَاعِلِه» [أخرجه مسلم]

Мәгънәсе: Әбү Мәсгуд Гукъбә бин Гамр әл-Әнсарий әл-Бәдрийдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Изгелеккә ишарәләүче, изгелекне кылучы кебек үк әҗер ала».***

عن أبي هريرة رضي الله عنه، أن رسول الله صلى الله عليه وسلم قال: «مَنْ دَعَا إلى هُدىً كَانَ لَهُ مِنَ الأجْرِ مِثْلُ أُجُورِ مَنْ تَبِعَهُ لا يَنْقُصُ ذَلِكَ مِنْ أُجُورِهِم شَيئاً، وَمَنْ دَعَا إلى ضَلالَةٍ كَانَ عَلَيْهِ مِن الإثْمِ مِثْلُ آثَامِ مَنْ تَبِعَهُ لا يَنْقُصُ ذَلِكَ مِنْ آثامِهِم شَيئاً» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Туры юлга чакыручы, үзе артыннан иярүчеләр кебек үк әҗер ала, һәм бу аларның үз әҗерләрен азга гына да киметми. Башкаларны адашуга чакыручы, үзе артыннан иярүчеләр кебек үк гөнаһ ала, һәм бу аларның үз гөнаһларын азга гына да киметми».***

عن أبي أمامة الباهلي رضي الله عنه قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «إنَّ الله وملائِكَتَه وأهلَ السَّماواتِ والأرضِ حتى النَّمْلَةَ في جُحْرِها وحتّى الْحُوتَ لَيُصَلُّونَ عَلى مُعَلِّمِي النَّاسِ الخَيْر» [ أخرجه الترمذي وقال: حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Үмәмә әл-Бәһилидән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә, фәрештәләр, күкләр вә җирнең барча әһелләре, хәтта оясындагы кырмыска да һәм балык та, кешеләрне изгелеккә өйрәтүчегә салават (дога һәм истигьфар) кылалар».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Кешеләрне дингә өйрәтү һәм изгелеккә чакыру — зур савaплы гамәлләрдән булып тора, чөнки бу пәйгамбәрләр гамәле. Аллаһ тәгалә бу эшкә пәйгамбәрләр итеп, иң хәерле бәндәләрен сайлады, һәм кем аларның юлында булып ошбу гамәлне дәвам итте икән — күп изгелек эшләде вә әҗер-савап туплады.

**Файдалар:**

**1)** Кешеләрне изгелеккә чакыру — пәйгамбәрләр гамәленнән.

**2)** Кешеләрне дингә өйрәтүнең фазыйләте зур, чөнки яхшылыкка өндәүчегә дә, эшләүченеке кебек үк савап була.

**3)** Яхшылыкка өйрәтүченең дәрәҗәсе зур, чөнки аңа Аллаһтан мактау, ә күкләр вә җир әһелләреннән истигъфар була.

**4)** Яхшылыкка өндәү вә начарлыктан тыю, зур фазыйләткә ия.

## 🕮 Аллаһ исеме зикер ителмәгән җыеннардан вә утырышлардан саклану хакында

•مَا يَلْفِظُ مِنْ قَوْلٍ إلا لَدَيْهِ رَقِيبٌ عَتِيدٌ• ق: ١٨

Мәгънәсе: **«Кеше нинди генә сүз сөйләмәсен, аның сөйләгән һәр сүзенә, шунда ук күзәтеп торучы фәрештә булыр».**

عن أبي هريرة رضي الله عنه عن رسول الله صلى الله عليه و سلم قال: «مَنْ قَعَدَ مَقْعَدَاً لَمْ يَذْكُرِ الله تَعَالَى فِيهِ كَانَتْ عَلَيْهِ مِنَ اللهِ تَعَالَى تِرَةٌ وَمَن اضْطَجَعَ مَضجَعاً لاَ يَذْكُرُ الله تَعَالَى فِيهِ كَانَتْ عَلَيْهِ مِنَ اللهِ تِرَةٌ» [ أخرجه أبو داود بإسنادٍ حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем, Аллаһны искә алмыйча, кая да булса утыра икән — аңа Аллаһның тирасы[3] булыр. Шулай ук, кем дә кем, Аллаһны искә алмыйча, кая да булса ята икән, аңа да Аллаһның тирасы булыр».***

عن أبي هريرة رضي الله عنه قال: قال رسول الله صلى الله عليه و سلم: «مَا مِنْ قَوْمٍ يَقُومُونَ مِنْ مَجْلِسٍ لاَ يَذْكُرُونَ الله تَعَالَى فِيهِ إلاَّ قَامُوا عَنْ مِثْلِ جِيفَةِ حِمَارٍ وَكَانَ لَهُمْ حَسْرَةٌ» [ أخرجه أبو داود بإسنادٍ صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә кешеләр бер урында утырганнан соң Аллаһ тәгаләне искә алмыйча торып китәләр икән, ул кешеләр***

---

3 Ягьни, ул кешегә хәсрәт булыр

***сасыган ишәк үләксәсе янынннан торып киткән кебек китәрләр һәм аларга хәсрәт булыр».***

عن أبي هريرة رضي الله عنه عن النبي ﷺ قال: «مَا جَلَسَ قَوْمٌ مَجْلِساً لَمْ يَذْكُرُوا الله تَعَالَى فِيهِ وَلَمْ يُصَلُّوا عَلَى نَبِيِّهِمْ فِيهِ إِلاَّ كَانَ عَلَيْهِمْ تِرَةٌ فَإِنْ شَاءَ عَذَّبَهُمْ وَإِنْ شَاءَ غَفَرَ لَهُمْ» [ أخرجه الترمذي وقال: حديث حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә кешеләр Аллаһ тәгаләне искә алмаган һәм пәйгамбәрләре өчен салават әйтмәгән җыенда булсалар, аларга һичшиксез тира (хәсрәт) ирешер, әгәр (Аллаһ) теләсә аларны җәза кылыр, теләсә — гафу итәр».***

عن ابن عمر رضي الله عنهما قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «لا تُكْثِرُوا الكَلاَمَ بِغَيْرِ ذِكْرِ اللهِ فَإِنَّ كَثْرَةَ الكَلاَمِ بِغَيْرِ ذِكْرِ اللهِ تَعَالَى قَسْوَةٌ لِلقَلْبِ وإِنَّ أَبْعَدَ النَّاسِ مِنَ اللهِ القَلْبُ القَاسِي» [ أخرجه الترمذي و حسنه الأرناؤط في جامع الأصول ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһны искә алудан башка сүзне күп сөйләмәгез, хакыйкатьтә, Аны искә алудан башка күп сүз сөйләү йөрәкне катылата һәм хакыйкатьтә, Аллаһка иң ерак кешеләр — каты йөрәклеләрдер».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Кешеләр нинди генә мәҗлескә яки җыенга җыелсалар да, анда сөйләшү вә сөхбәтләшү бар. Ләкин әгәр дә ул җыелып утыруларда Аллаһ тәгаләне искә алу, яки расүлебезгә салават әйтү булмый икән, бу утырышлар иң файдасыз вә иң кабахәт утырышлар санала. Чөнки пәйгамбәребез ﷺ мондый утырулардан сакланырга кушты һәм Кыямәт көнендә мондый кешеләргә хәсрәт булыр дип белгертте. Шулай ук мондый җыеннар йөрәкнең вә бәгырьнең катылыгына сәбәп булып тора, андый җыеннарда булган кешеләр вәгазьләр белән йомшармыйлар һәм үгет-нәсыйхәтне бик тиз кабул итмиләр, Аллаһу мүстәган. Ә кемнәр һәр утырган вә җыелган саен Аллаһны искә алып, яки расүлебезгә салаватлар әйтеп

динебез хакында сөйләшәләр һәм вәгазьләнәләр икән, бу кешеләрнең җыелып сөйләшүләре — иң хәерле җыелу була.

**Файдалар:**

**1)** Пәйгамбәребез ﷺ Аллаһны искә алынмый торган утырышлардан вә җыеннардан читләшергә вә сакланырга кушты.

**2)** Аллаһны искә алмый сөйләнгән күп сүз, йөрәкләрне вә бәгырьләрне катыра.

**3)** Кем дә кем бер җыенда яки мәҗлестә булып Аллаһны искә алмаса һәм расүлебезгә дә салават әйтмәсә, ул кешеләр үзләрен Аллаһның газабына дучар итәләр.

**4)** Аллаһны искә алу, мәҗлесләрне вә утырышларны хушландыра һәм йөрәк-күңелләрне тынычландыра.

## Телне саклау хакында

•وَلا تَقْفُ مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ عِلْمٌ إِنَّ السَّمْعَ وَالْبَصَرَ وَالْفُؤَادَ
كُلُّ أُولَئِكَ كَانَ عَنْهُ مَسْئُولا• الإسراء: ٣٦

Мәгънәсе: **«Гыйлемең булмаган нәрсәне вә белмәгәнне сөйләмә, әйтмә. Хакыйкатьтә ишетү, күрү һәм йөрәк — һәммәсе дә Кыямәт көнендә соралыр (ишетмәгән нәрсәне — ишеттем димә, күрмәгән нәрсәне — күрдем димә, белмәгән нәрсәне — беләм димә, чөнки болар өчен соралачаксың)».** (Ибен Кәсир һәм Багауи тәфсирләре)

•مَا يَلْفِظُ مِنْ قَوْلٍ إِلا لَدَيْهِ رَقِيبٌ عَتِيدٌ• ق: ١٨

Мәгънәсе: **«Кеше нинди генә сүз сөйләмәсен, аның сөйләгән һәрбер сүзенә, шунда ук күзәтеп торучы фәрештә булыр».**

عن سهل بن سعدٍ رضي الله عنه قال: قال رسول الله ﷺ : «مَنْ يَضْمَن لي مَا بَيْنَ

لَحْيَيْهِ وما بَيْنَ رِجْلَيْهِ أَضْمَن له الجَنَّة» [ متفقٌ عليه ]

Мәгънәсе: Сәһл бин Сәгъдтән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем казналыклары һәм аяклары арасында булган нәрсәсе[4] өчен җаваплылыкны ала икән, ул кеше өчен мин аның Җәннәткә керүе турында җаваплылыкны үз өстемә алырмын».***

عَنْ أبي موسى رَضِي الله عَنْهُ قال: قلتُ يا رسول الله أيُّ المُسْلِمِين أفْضَل؟ قالَ: «مَنْ سَلِمَ المُسْلِمونَ مِنْ لِسَانِه ويَدِه» [ متفقٌ عليه ]

Мәгънәсе: Әбү Муса ﵁ әйтте: «Бервакыт мин сорадым: «Әй Аллаһның расүле, мөселманнарның кайсысы иң яхшысы?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем башка мөселманнарга теле һәм куллары белән зарар китерми».***

عن عقبة بن عامر ﵁ قَالَ: قُلْتُ يَا رسول اللهِ مَا النَّجَاةُ؟ قَالَ: «أَمْسِكْ عَلَيْكَ لِسَانَكَ وَلْيَسَعْكَ بَيْتُكَ وابْكِ عَلَى خَطِيئَتِكَ» [ أخرجه الترمذي وقال: حديثٌ حسنٌ ]

Мәгънәсе: Гукъбә бине Гамир ﵁ әйтте: «Бервакыт мин сорадым: «Йә расүл Аллаһ, кешене нәрсә котылуга китерә ала?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Телеңне тый[5], өеңне синең өчен җитәрлек киң сана[6], һәм гөнаһларыңнан үкенеп ела».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Тел, кешене бик зур афәтләргә һәм хәрамнәргә китерергә мөмкин. Шуңа да расүлебез ﷺ телне тыярга, яки яхшы сүзләр генә сөйләргә кушты.

**Файдалар:**

**1)** Гөнаһлы сүзләр сөйләү — Җәһәннәмгә керүнең сәбәбе, ә яхшы сүзләр генә сөйләү — Җәннәткә керүнең сәбәбе.

**2)** Күп кешеләр файдасыз сүзләр сөйләп хаталана.

**3)** Мөселманның дине камил булуыннан — башкаларга сүз тидермәве.

4 Тел һәм җенес әгъзасы

5 Син әйткәннәр сиңа каршы булмасын, ягъни, сиңа дөньяда да, ахирәттә дә файда китерә торган һәм зарар итә алмаганны гына сөйлә

6 Ягъни, сине өеңдә тота торган, Аллаһка гыйбадәттә бул

**4)** Аллаһ риза булган сүзләр — яхшы сүзләр, Аллаһны ачуландыра торган сүзләр — кабахәт сүзләр.

## 🕮 Пәйгамбәребезгә итагатьлек хакында

•فَلا وَرَبِّكَ لا يُؤْمِنُونَ حَتَّى يُحَكِّمُوكَ فِيمَا شَجَرَ بَيْنَهُمْ ثُمَّ لا يَجِدُوا فِي أَنْفُسِهِمْ حَرَجًا مِمَّا قَضَيْتَ وَيُسَلِّمُوا تَسْلِيمًا• النساء: ٦٥

Мәгънәсе: **«Раббың исеме белән ант итеп әйтәм! Мөселманнар үзара бәхәсләшкән эшләре турысында синнән (Мөхәммәд ﷺ) хөкем иттермичә, иманлы була алмаслар. Алар синең хөкемеңә күңелләрендә шик калдырмаслар һәм синең хөкемеңә чын күңелдән риза булып буйсынырлар».**

•وَمَا كَانَ لِمُؤْمِنٍ وَلا مُؤْمِنَةٍ إِذَا قَضَى اللَّهُ وَرَسُولُهُ أَمْرًا أَنْ يَكُونَ لَهُمُ الْخِيَرَةُ مِنْ أَمْرِهِمْ وَمَنْ يَعْصِ اللهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ ضَلَّ ضَلالاً مُبِينًا• الأحزاب: ٣٦

Мәгънәсе: **«Аллаһ вә Аның расүле бернәрсә хакында хөкем итсәләр, бернинди мөэмин иргә вә мөэминә хатынга бу хөкемне читкә куеп үзләре теләгәнне ихтыяр итәргә ярамас, бәлки, Аллаһ вә расүлнең әмерләренә буйсыну фарыз буладыр. Әгәр берәү Аллаһ вә расүлнең әмерен тотмыйча нәфесе теләгәнчә эш кылса, яки динсез кешеләргә ияреп эш кылса, тәхкыйк ул кеше ачыктан-ачык адашты».**

•إِنَّمَا كَانَ قَوْلَ الْمُؤْمِنِينَ إِذَا دُعُوا إِلَى اللهِ وَرَسُولِهِ لِيَحْكُمَ بَيْنَهُمْ أَنْ يَقُولُوا سَمِعْنَا وَأَطَعْنَا وَأُولَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ• النور: ٥١

Мәгънәсе: **«Хак мөэминнәрнең сүзләре шул булды, әгәр араларында хөкем итмәк өчен Аллаһка вә Аның расүленә чакырылсалар: «Ишеттек вә итагать иттек», — дип әйтерләр. Әнә шундый әдәпле хак мөэминнәр мәңгелек бәхеткә ирешүчеләр».**

•فَلْيَحْذَرِ الَّذِينَ يُخَالِفُونَ عَنْ أَمْرِهِ أَنْ تُصِيبَهُمْ فِتْنَةٌ أَوْ يُصِيبَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ• النور

Мәгънәсе: **«Пәйгамбәрнең әмерләренә каршылык күрсәткән кешеләр, кәфер булып үлүдән, яки, дөньяда аларга бәла-каза килүдән һәм ахирәттә рәнҗетүче газаб булудан саклансыннар!».**

عن أَبِي هريرة رضي الله عنه قالَ: قال رسول الله ﷺ: «كلُّ أُمَّتي يَدْخُلُونَ الجَنَّةَ إلاَّ مَنْ أَبَى، قِيلَ: وَمنْ يَأْبَى يا رَسولَ الله؟ قال: مَنْ أَطَاعَنِي دَخَلَ الجَنَّةَ وَمَنْ عَصَانِي فَقَدْ أبَى» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Минем өммәтемнең барсы да Җәннәткә керер, иллә мәгәр баш тартучылар гына кермәс».*** Сорадылар: «Әй Аллаһның расүле, ә кем баш тартыр?». Ул: ***«Миңа буйсынучы Җәннәткә керә, ә миңа буйсынмаучы баш тарта»,*** — дип җавап бирде».

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Башка кешеләрнең сүзләренә караганда пәйгамбәребезнең ﷺ сүзен өстен кую һәм аңа буйсыну, динебез нигезенең икенче асылы булып тора һәм бу шәһәдәт кәлимәсенең икенче өлешенең мәгънәсен үзенә тәшкил итә. Чөнки динебез ике асылга нигезләнгән: Аллаһтан башкага гыйбадәт кылмаска һәм Аның расүленә итагать итәргә. Кешедә шушы ике асыл булмыйча, ул Җәһәннәмнән котыла алмый һәм Җәннәткә дә ирешә алмый.

**Файдалар:**

**1)** Пәйгамбәребезгә буйсынып, аның сүзен башка кешеләр сүзенә карата өстен кую тиешле.

**2)** Пәйгамбәребезгә буйсыну Җәннәткә керүнең сәбәбе.

**3)** Пәйгамбәребезгә буйсынмау һәм аның кушканнарына каршы бару, фетнәгә вә газапка дучар булуның сәбәбе.

**4)** Расүлебезнең юлында булып кына кеше бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешә ала.

## 🕮 Тәүбә һәм аның фазыйләтләре хакында

•وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَا الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ• النور: ٣١

Мәгънәсе: **«Ий, мөэминнәр, һәммәләрегез дә Аллаһка тәүбә итегез, шаять дөнья вә ахирәттә бәхетле булырсыз».**

•يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللَّهِ تَوْبَةً نَصُوحًا• التحريم: ٨

Мәгънәсе: **«Ий мөэминнәр! Аллаһка ихлас тәүбә белән тәүбә итегез!».**

عَن الأَغَرِّ بْنِ يَسَارِ المُزَنِيِّ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قال: قالَ رسولُ الله ﷺ : «يا أَيُّها النَّاسُ تُوبُوا إلى اللهِ وَاسْتَغْفِرُوه فَإِنِّي أَتُوبُ في الْيَوم مِائَةَ مَرَّةٍ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әл-Әгарр бин Йәсәрдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әй кешеләр! Аллаһка тәүбә итегез һәм Аңардан ярлыкау сорагыз! Дөреслектә, мин көнгә йөз мәртәбә тәүбә итәм».***

عَنْ أَنَس بْنِ مَالِكٍ الأنصارِيِّ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسولُ اللهِ ﷺ : «لَلَّهُ أَفْرَحُ بِتَوْبَةِ عَبْدِهِ مِنْ أَحَدِكُمْ سَقَطَ عَلَى بَعِيرِهِ وَقَدْ أَضَلَّهُ في أَرْضٍ فَلَاةٍ» [ متفقٌ عليه ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә колының тәүбәсе өчен, сезнең берегез сахрада дөясендә барганда егылып төшеп, ул дөя аның барча ризыклары вә сулары белән качканнан соң, шул югалган дөясен көтмәгәндә тапканга шатланган кебек, аннан да ныграк шатлана».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Тәүбә, Аллаһ тәгаләгә иң сөйкемле гамәлләрнең берсе булып тора һәм ул кешенең бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешүенең бер сәбәбе. Аллаһ тәгаләнең рәхмәте киң, шуңа да мөэминнәргә тәүбә белән әмер итте һәм аңа чакырды.

Барча гөнаһлардан да тәүбә итү тиешле. Тәүбәнең биш шарты бар: 1) Тәүбәне Аллаһ ризалыгы өчен ихлас күңелдән кылырга тиеш; 2) Кеше мондый гөнаһны кылудан туктарга

һәм баш тартырга тиеш; 3) Кеше кылган гөнаһы өчен үкенергә тиеш; 4) Киләчәктә бу гөнаһны беркайчан да кылмаска катгый карар кабул итәргә тиеш; 5) Тәүбә кабул була торган вакытта тәүбә итәргә тиеш (Кыямәтнең галәмәте булган кояш көнбатыштан чыкканчыга кадәр, яки кешенең әҗәле бугазына җиткәнчегә кадәр).

**Файдалар:**

**1)** Аллаһ тәгаләгә һәрвакытта да тәүбә итү тиешле.

**2)** Тәүбә, кешенең бәхетле булуына бер сәбәп булып тора һәм Аллаһ тәгалә бәндәнең тәүбәсенә шатлана.

**3)** Барча гөнаһлардан да тәүбә итү кирәк.

**4)** Аллаһның рәхмәте киң һәм Ул барча тәүбәчеләрнең дә тәүбәсен кабул итә.

## 🕮 Иманның нигезләре хакында

•لَيْسَ الْبِرَّ أَنْ تُوَلُّوا وُجُوهَكُمْ قِبَلَ الْمَشْرِقِ وَالْمَغْرِبِ وَلَكِنَّ الْبِرَّ مَنْ آمَنَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ وَالْمَلَائِكَةِ وَالْكِتَابِ وَالنَّبِيِّينَ• البقرة: ١٧٧

Мәгънәсе: **«Кояш чыга торган якка һәм кояш бата торган якка йөзләрегезне юнәлдерү, Аллаһ хозурында изгелек түгелдер. Ләкин, изгелек шундадыр, кем Аллаһка, ахирәт көненә, фәрештәләргә, китапларга һәм пәйгамбәрләргә иман китерде һәм ...».**

عن عمر بن الخطاب رضي الله عنه قَالَ: بَيْنَما نَحْنُ جُلُوسٌ عِنْدَ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم ذَاتَ يَوم، إذْ طَلَعَ عَلَينا رَجُلٌ شَديدُ بَياضِ الثِّيابِ، شَديدُ سَوَادِ الشَّعْرِ، لا يُرَى عَلَيهِ أثَرُ السَّفَرِ، وَلا يَعْرِفُهُ مِنَّا أَحَدٌ، حَتَّى جَلَسَ إِلَى النَّبيّ صلى الله عليه وسلم، فَأَسْنَدَ رُكْبَتَيهِ إِلَى رُكْبَتيهِ، وَوَضعَ كَفَّيهِ عَلَى فَخِذَيهِ، وَقالَ: يَا مُحَمَّدُ، أَخْبِرْني عَنِ الإِسلامِ، فَقَالَ رَسُولُ الله صلى الله عليه وسلم: «الإِسْلامُ: أَنْ تَشْهَدَ أَنْ لَا إِلَهَ إِلاَّ الله وأَنَّ مُحَمَّداً رسولُ الله، وتُقِيمَ الصَّلاةَ، وَتُؤتِيَ الزَّكَاةَ، وَتَصومَ رَمَضَانَ، وَتَحُجَّ البَيتَ إن اسْتَطَعْتَ إِلَيْهِ سَبيلاً». قَالَ: صَدَقْتَ. فَعَجِبْنَا لَهُ يَسْأَلُهُ وَيُصَدِّقُهُ!

قَالَ: فَأَخْبِرنِي عَنِ الإِيمَانِ. قَالَ: «أَنْ تُؤمِنَ بِاللهِ، وَمَلائِكَتِهِ، وَكُتُبِهِ، وَرُسُلِهِ، وَاليَوْم الآخِرِ، وتُؤْمِنَ بِالقَدَرِ خَيرِهِ وَشَرِّهِ». قَالَ: صَدقت. قَالَ: فَأَخْبِرنِي عَنِ الإِحْسَانِ. قَالَ: «أَنْ تَعْبُدَ اللهَ كَأَنَّكَ تَرَاهُ فإِنْ لَمْ تَكُنْ تَرَاهُ فَإِنَّهُ يَرَاكَ». قَالَ: فَأَخْبِرنِي عَنِ السَّاعَةِ. قَالَ: «مَا المَسْؤُولُ عَنْهَا بِأَعْلَمَ مِنَ السَّائِلِ». قَالَ: فأخبِرنِي عَنْ أَمَارَاتِهَا. قَالَ: «أَنْ تَلِدَ الأَمَةُ رَبَّتَهَا، وأَنْ تَرَى الحُفَاةَ العُرَاةَ العَالَةَ رِعَاءَ الشَّاءِ يَتَطَاوَلُونَ فِي البُنْيَانِ». ثُمَّ انْطَلَقَ فَلَبِثْتُ مَلِيًّا، ثُمَّ قَالَ: «يَا عُمَرُ أَتَدْرِي مَنِ السَّائِلُ؟» قُلْتُ: اللهُ وَرَسُولُهُ أَعْلَمُ، قَالَ: «فَإِنَّهُ جِبْرِيلُ أَتَاكُمْ يُعَلِّمُكُمْ أَمْرَ دِينِكُمْ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Гомәр бин әл-Хәттаб ؓ әйтте: «Бервакыт без пәйгамбәребез ﷺ янында булганда, көтмәгәндә безнең янга ап-ак киемнән, кап-кара чәчле бер кеше килде. Аның тышкы кыяфәтенә карап юлчы дип әйтеп булмый иде һәм аны безнең арадан берәү дә танымады. Ул пәйгамбәребез ﷺ янына килеп, тезләрен аның тезләренә тидереп утырды, кулларын үзенең аякларына куйды һәм әйтте: «Әй Мөхәммәд, миңа Ислам турында сөйлә». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ислам ул — Аллаһтан башка иләһ юк һәм Мөхәммәд Аллаһның расүле, — дип шәһәдәт бирү, намаз уку, зәкәт түләү, Рамазан аенда ураза тоту һәм әгәр хәлеңнән килсә, Кәгъбәгә хаҗ кылуыңнан гыйбарәт».*** Бу кеше: «Син дөрес әйттең», — диде, ә без аның пәйгамбәргә сораулар бирүенә һәм аның сүзләренең хаклыгын раславына гаҗәпләндек. Аннан ул: «Ә хәзер миңа иман турында хәбәр ит», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ : ***«Иман ул — Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Аның Китапларына, Аның пәйгамбәрләренә, Кыямәт көненә, һәм шулай ук тәкъдирнең яхшысы да, начары да билгеләнгән булуына иман китерүеңнән гыйбарәт»,*** — диде, һәм бу кеше тагын: «Син дөрес әйттең», — диде. Аннан ул: «Миңа ихсан турында хәбәр ит», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ : ***«Ихсан ул — син Аллаһны күрмәсәң дә, Аны күргән кебек гыйбадәт кылуың, чөнки, хакыйкатьтә, Ул сине күрә»,*** — диде. Аннан ул: «Ә хәзер миңа Кыямәт турында хәбәр ит», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аның турында соралучы, сораучыдан артыгын белми».*** Ул кеше: «Алай булгач, миңа аның галәмәтләре турында сөйлә», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кыямәтнең якынлашуын аңлатучы билгесе шул:***

***Кәнизәк үзенең хуҗасын тудырыр һәм яланаяклы, ялангач тәнле сарык көтүчеләренең биек йортлар төзүдә бер-берсе белән ярышуларын күрерсең».*** Ә аннан соң бу кеше китте, бераз вакыт үткәч пәйгамбәребез ﷺ миннән: ***«Әй Гомәр, бу сорауларны бирүченең кем икәнен беләсеңме?»,*** — дип сорады. Мин: «Аллаһ һәм Аның расүле моны яхшырак беләләр», — дидем. Шунда ул: ***«Дөреслектә, бу — Җибрил, сезне динегезгә өйрәтү өчен килде»,*** — диде».

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Һәрнәрсәнең нигезе булган кебек, иманның да нигезләре бар һәм нигезләрсез иман дөрес булмый. Җибрил عليه السلام пәйгамбәребездән ﷺ шушы нигезләр хакында сорап, өммәтебезне динебезнең нигезләренә өйрәтте. Безнең өчен динебезне өйрәнү, гыйлем алу бик тә мөһим булып тора, чөнки гыйлемсезлек, кешене адашуга китерә.

**Файдалар:**

**1)** Иманның алты нигезе бар.

**2)** Кем дә кем иманның бер генә нигезен булса да инкяр итә икән, ул кеше кәфер була.

**3)** Гыйлем мәҗлесләрендә утыруның зур фазыйләтләре бар.

**4)** Җибрил белән пәйгамбәребезнең сөйләшүләрендә, гыйлем алучыларга бик күп тәрбия бар.

**5)** Гыйлем иясе белмәгән нәрсәсенә «белмим» – дип җавап бирергә тиеш.

**6)** Иман ул тел белән әйтү, йөрәк белән тәсдыйкълау һәм гамәл итү.

## 🕮 Тәүхиднең фазыйләте хакында

•وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنْسَ إِلا لِيَعْبُدُونِ• الذاريات: ٥٦

Мәгънәсе: **«Мин, җеннәр белән кешеләрне иллә мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым».**

•وَلَقَدْ بَعَثْنَا فِي كُلِّ أُمَّةٍ رَسُولا أَنِ اعْبُدُوا اللَّهَ وَاجْتَنِبُوا الطَّاغُوتَ• النحل: ٣٦

Мәгънәсе: **«Өммәтләрнең һәрберсенә, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылып, тагуттан (Аллаһтан башкага гыйбадәт кылудан) саклансыннар өчен расүлләр җибәрдек».**

عَنْ جَابِرُ بْنُ عَبْدِ اللَّهِ قَالَ: قَالَ رَسُول اللَّه ﷺ : «مَنْ لَقِيَ اللَّهَ لاَ يُشْرِكُ بِهِ شَيْئًا دَخَلَ الْجَنَّةَ وَمَنْ لَقِيَهُ يُشْرِكُ بِهِ دَخَلَ النَّارِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһтан رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем Аллаһка ширек кылмыйча Аны очрата икән (Кыямәт көнендә), ул Җәннәткә керә, ә кем Аңа ширек кылып очрата икән, Җәһәннәм утына керә».***

عن معاذ بن جبل رضي الله عنه قَالَ: كُنْتُ رِدْفَ النَّبِيِّ ﷺ عَلَى حِمَارٍ فَقَالَ: «يَا مُعَاذُ، هَلْ تَدْرِي مَا حَقُّ اللهِ عَلَى عِبَادِهِ؟ وَمَا حَقُّ الْعِبَادِ عَلَى اللهِ؟» قُلْتُ: اللهُ وَرَسُولُهُ أَعْلَمُ، قَالَ: «فإِنَّ حَقَّ اللهِ عَلَى الْعِبَادِ أَنْ يَعْبُدُوهُ، وَلاَ يُشْرِكُوا بِهِ شَيئاً، وَحَقَّ الْعِبَادِ عَلَى اللهِ أَنْ لاَ يُعَذِّبَ مَنْ لا يُشْرِكُ بِهِ شَيئا». فَقُلْتُ: يَا رَسُولَ اللهِ، أَفَلا أُبَشِّرُ النَّاسَ؟ قَالَ: «لاَ تُبَشِّرْهُمْ فَيَتَّكِلُوا» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Мүгаз бин Җәбәл رضي الله عنه әйтте: «Бервакыт мин пәйгамбәребез ﷺ артында ишәккә атланып барганда, ул миннән: ***«Әй Мүгаз, Аллаһның коллары Аның нинди хакын үтәргә тиеш булуы һәм алар Аллаһтан нәрсә көтәргә хаклы булулары турында сиңа билгелеме?»,*** — дип сорады. Мин: «Аллаһ һәм Аның Илчесе бу хакта яхшырак беләләр», — дидем. Шунда ул: ***«Дөреслектә, Аллаһның коллары үтәргә тиешле Аллаһның хакы — алар бары тик бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга тиеш, коллар исә, Аллаһтан башка бернәрсәгә дә гыйбадәт кылмасалар, Аллаһ аларны җәзага дучар итмәс дип өметләнергә ха-***

***клылар»,*** — диде. Мин: «Әй Аллаһның Илчесе, мин бу хәбәр белән кешеләрне шатландыра аламмы?», — дип сорадым. Ул: ***«Аларны шатландырма, чөнки алар бары тик шуңа гына таянырлар!»,*** — диде».

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Тәүхид, итагатьнең нигезләреннән булып тора. Чөнки ул — Аллаһны гыйбадәттә бер кылып, Аннан башкага табынуларны инкяр итү була. Аллаһ тәгалә җеннәрне вә кешеләрне Үзенә генә гыйбадәт кылыр өчен халык кылды һәм шуның өчен генә пәйгамбәрләр җибәрде. Кем тәүхидне тормышына ашыра икән, Аллаһ аңа Җәннәт вәгъдә итте.

**Файдалар:**

**1)** Тәүхид, кешенең Җәннәткә керүенә шарт булып тора.

**2)** Кешеләрнең вә җеннәрнең бу дөньяда бар булуының максаты да тәүхидтә.

**3)** Тәүхид Җәһәннәм утыннан саклану чарасы.

## Ширек һәм аннан саклану хакында

•إِنَّ الشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ• لقمان: ١٣

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһка ширек кылу бик олуг золымдыр».**

•إِنَّ اللَّهَ لا يَغْفِرُ أَنْ يُشْرَكَ بِهِ وَيَغْفِرُ مَا دُونَ ذَٰلِكَ لِمَنْ يَشَاءُ
وَمَنْ يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدِ افْتَرَى إِثْمًا عَظِيمًا• النساء: ٤٨

Мәгънәсе: **«Аллаһ Үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итми, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны Үзе теләгән кешегә гафу итә. Берәү Аллаһка кемнедер, нәрсәнедер тиңдәш кылса, дөреслектә, ул Аллаһка олы ялганны ифтира кылган буладыр».**

•وَلَقَدْ أُوحِيَ إِلَيْكَ وَإِلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِكَ لَئِنْ أَشْرَكْتَ لَيَحْبَطَنَّ عَمَلُكَ وَلَتَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ• الزمر: ٦٥

Мәгънәсе: **«Сиңа һәм синнән әүвәлге пәйгамбәрләргә вәхий ителде, әгәр Аллаһка бернәрсәне тиңдәш итсәгез, әлбәттә, гамәлләрегез батыл булыр вә үзегез дә хәсрәттә булырсыз».**

عَنْ جَابِرُ بْنُ عَبْدِ اللهِ قَالَ: قَالَ رَسُولَ اللهِ ﷺ : «مَنْ لَقِىَ اللهَ لاَ يُشْرِكُ بِهِ شَيْئًا دَخَلَ الْجَنَّةَ وَمَنْ لَقِيَهُ يُشْرِكُ بِهِ دَخَلَ النَّارِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһтан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем Аллаһка ширек кылмыйча Аны очрата икән[7] — ул Җәннәткә керә, ә кем Аңа ширек кылып очрата икән — Җәһәннәм утына керә».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه عن النبيِّ ﷺ قَالَ: «اجْتَنِبُوا السَّبْعَ المُوبِقَاتِ» قالُوا: يَا رَسُولَ اللهِ وَمَا هُنَّ؟ قَالَ: «الشِّرْكُ باللهِ والسِّحْرُ وَقَتْلُ النَّفْسِ الَّتي حَرَّمَ اللهُ إِلاَّ بالحَقِّ وأكلُ الرِّبَا وأَكْلُ مَالِ اليَتِيمِ والتَّوَلِّي يَوْمَ الزَّحْفِ وقَذْفُ المُحْصَنَاتِ المُؤْمِنَاتِ الغَافِلاَتِ» [ متفق عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кешене һәлак итүче җиде зур гөнаһтан сакланыгыз!».*** Сорадылар: «Йә расүл Аллаһ, нинди гөнаһлар ул?». Ул әйтте: ***«Аллаһка ширек кылу, сихер, хаксызга кеше үтерү, рибачылык, ятимнең малын ашау, җиһәд мәйданыннан качу, һәм саф әхлаклы вә фәхешлектән пакь мөэминәләрне зина кылуда гаепләү».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Аллаһка гына хас булган нәрсәләрдә Аңа кемне дә булса тиңләү — ширек дип атала. Ширек, иң зур вә иң кабахәт гөнаһлардан булып тора. Кем дә булса ширек кылган килеш үлсә, Аллаһ тәгалә аны ярлыкамый, бәлки ул кеше, Аллаһка карата иң зур җинаятьне кылганы өчен, мәңгелек Җәһәннәм утында кала. Аллаһ сакласын.

---

7 Кыямәт көнендә

**Файдалар:**

**1)** Ширек иң зур гөнаһ.

**2)** Әгәр дә берәү ширек кыла икән, ул Аллаһка тәүбә итеп Исламга кайтырга тиеш.

**3)** Кем ширек кылган килеш үлсә, аның барча изге гамәлләре дә батыл булып юкка чыга.

**4)** Ширек кылган кеше Җәһәннәм утында мәңге кала.

## Риядан саклану хакында

عن أَبِي هريرة رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ رسولَ الله صلى الله عليه و سلم يقولُ: «إِنَّ أولَ النَّاسِ يُقْضَى يومَ القِيَامَةِ عَلَيْهِ رَجُلٌ اسْتُشْهِدَ فَأُتِيَ بِهِ، فَعَرَّفَهُ نِعْمَتَهُ فَعَرَفَهَا قَالَ: فَمَا عَمِلْتَ فِيهَا؟ قَالَ: قَاتَلْتُ فِيكَ حَتَّى اسْتُشْهِدْتُ قَالَ: كَذَبْتَ وَلَكِنَّكَ قَاتَلْتَ لأَنْ يُقَالَ: جَرِيءٌ فَقَدْ قِيلَ ثُمَّ أُمِرَ بِهِ فَسُحِبَ عَلَى وَجْهِهِ حَتَّى أُلْقِيَ فِي النَّارِ، وَرَجُلٌ تَعَلَّمَ العِلْمَ وَعَلَّمَهُ وَقَرَأَ القُرآنَ فَأُتِيَ بِهِ فَعَرَّفَهُ نِعَمَهُ فَعَرَفَهَا قَالَ: فَمَا عَمِلْتَ فِيهَا؟ قَالَ: تَعَلَّمْتُ العِلْمَ وَعَلَّمْتُهُ وَقَرَأْتُ فِيكَ القُرآنَ قَالَ: كَذَبْتَ وَلَكِنَّكَ تَعَلَّمْتَ لِيُقَالَ: عَالِمٌ وَقَرَأْتَ القُرْآنَ لِيُقَالَ: هُوَ قَارِئٌ، فَقَدْ قِيلَ ثُمَّ أُمِرَ بِهِ فَسُحِبَ عَلَى وَجْهِهِ حَتَّى أُلْقِيَ فِي النَّارِ، وَرَجُلٌ وَسَّعَ اللهُ عَلَيْهِ وَأَعْطَاهُ مِنْ أَصْنَافِ المَالِ فَأُتِيَ بِهِ فَعَرَّفَهُ نِعَمَهُ فَعَرَفَهَا قَالَ: فَمَا عَمِلْتَ فِيهَا؟ قَالَ: مَا تَرَكْتُ مِنْ سَبِيلٍ تُحِبُّ أَنْ يُنْفَقَ فِيهَا إِلاَّ أَنْفَقْتُ فِيهَا لَكَ قَالَ: كَذَبْتَ وَلَكِنَّكَ فَعَلْتَ لِيُقَالَ: جَوَادٌ فَقَدْ قِيلَ ثُمَّ أُمِرَ بِهِ فَسُحِبَ عَلَى وَجْهِهِ حَتَّى أُلْقِيَ فِي النَّارِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Дөреслектә, Кыямәт көнне хөкем ителүче беренче кеше булып җиһәдтә һәлак булган кеше булыр. Аны китерерләр, һәм Аллаһ аңа нигъмәтләре турында искә төшерер һәм ул аларны таныр, ә аннары Аллаһ сорар: «Бу нигъмәтләргә шөкер итү йөзеннән син нәрсә кылдың?». Ул: «Мин Синең ризалыгың өчен, һәлак булганга кадәр сугыштым!» — дип җавап бирер. Аллаһ әйтер: «Син ялганлыйсың, чөнки син, башкалар синең хакта: «Бу батыр кеше!», — дип әйтсеннәр өчен генә***

***сугыштың, һәм алар шулай әйттеләр дә!». Аннан соң бу кешегә карата тиешле әмер бирелер, һәм аны йөзтүбән өстерәп Җәһәннәмгә ыргытырлар. Аннары белем алган, аны башкаларга өйрәткән һәм Коръән укыган кешене китерерләр, һәм Аллаһ аңа нигъмәтләре турында искә төшерер, һәм ул аларны таныр, ә аннан соң Аллаһ сорар: «Бу нигъмәтләргә шөкер итү йөзеннән син нәрсә кылдың?». Ул: «Мин Синең ризалыгың өчен белем алдым, аны башкаларга өйрәттем һәм Коръән укыдым», — дип әйтер. Аллаһ әйтер: «Син ялганлыйсың, чөнки син, башкалар синең хакта: «Бу кеше галим!», — дип әйтсеннәр өчен генә белем алдың, һәм Коръәнне (кешеләр): «Ул Карый!», — дип әйтсеннәр өчен генә укыдың, һәм алар шулай әйттеләр дә!». Аннан соң бу кешегә карата тиешле әмер бирелер, һәм аны йөзтүбән өстерәп Җәһәннәмгә ыргытырлар. Ә аннан соң, Аллаһ киң ризык һәм төрле байлыклар биргән кешене китерерләр, һәм Аллаһ аңа нигъмәтләре турында искә төшерер, ул аларны таныр, һәм Аллаһ сорар: «Бу нигъмәтләргә шөкер итү йөзеннән син нәрсә кылдың?». Ул җавап бирер: «Мин ул байлыкны, акчаларны Синең ризалыгың өчен, Син яраткан урыннарга садака итеп таратудан туктамадым һәм бер генә дә мөмкин булган форсатны калдырмадым». Аллаһ әйтер: «Син ялганлыйсың, чөнки син, башкалар синең хакта: «Бу кеше юмарт», — дип әйтсеннәр өчен генә кылдың һәм алар шулай әйтә иделәр!». Аннан соң бу кешегә туры килә торган әмер бирелер, һәм аны йөзтүбән өстерәп Җәһәннәмгә ыргытырлар».***

عَنْ أبي سَعِيدٍ الْخُدْرِي رَضِي الله عَنْهُ قَالَ: خَرَجَ عَلَيْنَا رَسُولُ الله صَلَّى الله عَلَيْهِ و سَلّم وَنَحْنُ نَتَذاكَرُ الْمَسيحَ الدَّجَّال فقَال: «أَلاَ أُخْبِرُكُم بِمَا هُوَ أَخْوَفُ عَلَيْكُم عِنْدِي مِنْ الْمَسيح الدَّجَّا؟» فَقُلْنا: بَلى يا رَسولَ الله، فَقَال: «الشِّرْكُ الْخَفِيُّ، أَنْ يَقُومَ الْرَجُل يُصَلِّي فَيُزَيِّنُ صَلاتَهُ لِمَا يَرَى مِنْ نَظَرِ رَجُل» [ أخرجه ابن ماجه، قال الشيخ الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд әл-Худрий ﵁ әйтте: «Бервакыт без Дәҗҗәл турында сөйләшеп торганда, безнең яныбызга

пәйгамбәребез ﷺ чыкты да болай дип әйтте: ***«Сезгә, сезнең өчен Дәҗҗәлдән дә куркынычрак нәрсә белән хәбәр биримме?».*** Без: «Әйе, йә расүл Аллаһ», — дидек. Шуннан соң ул: ***«Яшерен, күренми торган ширек. Берәү намаз укырга басса, башка кеше аны күреп торганда намазын матурлап укый».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Рия ул — гыйбадәтне кешеләр күрсен өчен кылу яки матурлау. Пәйгамбәребез ﷺ бу гамәлдән сак булырга кушты, чөнки ул ширеккә юл ача. Рия кешеләргә изгелек, яхшы гамәл булып күренә, башкаларга аның ширек икәнлеге, ул намазны кешеләр өчен укыганлыгы күренми, шуңа да яшерен ширек дип атала.

**Файдалар:**

1) Пәйгамбәребезнең ﷺ сахәбәләр өчен риядан куркуы, башкалар өчен артыграк кисәтү булып тора.

2) Изге-салих кеше дә үзенең рияга керүен сизмичә дә калырга мөмкин.

3) Рия белән кылынган гамәл кабул булмый.

4) Рия кылучыларны бик тә аяныч хәл көтә.

## Күз тиюдән һәм башка явызлыклардан саклану өчен төймәләр вә бөтиләр тагуның ярамаганлыгы хакында

•قُلْ أَفَرَأَيْتُمْ مَا تَدْعُونَ مِنْ دُونِ اللَّهِ إِنْ أَرَادَنِيَ اللَّهُ بِضُرٍّ هَلْ هُنَّ كَاشِفَاتُ ضُرِّهِ أَوْ أَرَادَنِي بِرَحْمَةٍ هَلْ هُنَّ مُمْسِكَاتُ رَحْمَتِهِ قُلْ حَسْبِيَ اللَّهُ عَلَيْهِ يَتَوَكَّلُ الْمُتَوَكِّلُونَ• الزمر: ٣٨

Мәгънәсе: **«Әйт: «Әгәр Аллаһ тәгалә миңа бер зарар ирештерергә теләсә, сезнең Аллаһтан башка гыйбадәт кыла торган сыннарыгыз, шул зарарны миннән җибәрә алырлармы? Яки Аллаһ миңа рәхмәт итәргә теләсә, ул рәхмәтне миңа җибәрмичә тотып калырга сезнең сыннарыгызның көче җитәрме?». Әйт: «Миңа һәр эштә ярдәм бирергә, вә мине сакларга, Аллаһ җитәдер, хак тәвәккәл итүчеләр, әлбәттә, Аллаһка тәвәккәл итәрләр».**

عَنْ عُقْبَةَ بْنِ عَامِرٍ الْجُهَنِيِّ قال: قال رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «مَنْ عَلَّقَ تَمِيمَةً فَقَدْ أَشْرَكَ» [ أخرجه أحمد، وصححه الألباني ]

Мәгънәсе: Гукьбә бин Гамир әл-Җүһәнийдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем тәмимә[8] такса, ул Аллаһка ширек кылды».***

عن عبد الله بن عُكَيْم قال: قال النَّبي صَلَّى الله عَلَيْهِ وسَلَّم: «مَنْ تَعَلَّق شَيْئاً وُكِلَ إِلَيْهِ» [ أخرجه الترمذي، و حسنه الأرناؤوط و الألباني ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гукәймнән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем саклый дип бирәр нәрсә такса, шул әйбергә йөкләнер».***

### Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:

Күз тию, сихер һәм башка бозыклыклардан саклану өчен тагыла торган бөти кебек нәрсәләр, ширеккә китерә. Аллаһ тәгаләнең теләгеннән башка, Адәм баласына һичнәрсә зыян да, файда да китерә алмый, шуңа да кеше барча нәрсәдә дә

8 Күз тиюдән, сихердән һәм башка явызлыклардан саклый дип тага торган нәрсәләр

бер Аллаһка гына сыенырга тиеш. Кем инде Аллаһтан башка нәрсәгә сыенса, ышанса, ул кеше ширек кылган була.

**Файдалар:**

**1)** Кем дә кем бөтиләр зыяннан саклый яки файда китерә дип уйласа, ул кеше зур ширек кылган була. Ә инде ул бөтиләр файда китерүдә яки зыян итүдә сәбәп кенә булып тора дип уйласа, ул кеше кечкенә ширек кылган була.

**2)** Бернинди бөти дә тагырга ярамый, хәтта ул Коръән аятьләреннән булса да.

**3)** Шушы ук хөкемгә, саклау өчен дип машиналарга төрле нәрсәләр элеп кую да керә.

## 🕮 Күрәзәчеләргә, сихерчеләргә һәм башка төрле шарлатаннарга баруның хәрамлыгы хакында

•قُلْ لا يَعْلَمُ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضِ الْغَيْبَ إِلا اللَّهُ• النمل: ٦٥

Мәгънәсе: **«Әйт: «Күкләрдә вә җирдә булган затларның һичберсе дә яшерен нәрсәләрне белмәсләр, иллә мәгәр Аллаһ Үзе генә белә».**

عَنْ صَفِيَّةَ عَنْ بَعْضِ أَزْوَاجِ النَّبِيِّ ﷺ عَنِ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَنْ أَتَى عَرَّافًا فَسَأَلَهُ عَنْ شَيْءٍ لَمْ تُقْبَلْ لَهُ صَلاَةٌ أَرْبَعِينَ لَيْلَةً» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: **«Кем дә кем күрәзәчегә барып нәрсә дә булса сорый икән, аның намазы кырык төн (яки кырык көн) буена кабул булмый».**

عن عائشة رضي الله عنها قالت: سأَلَ رَسُولَ اللهِ صلى الله عليه وسلم أُنَاسٌ عَنِ الكُهَّانِ فَقَالَ: «لَيْسُوا بِشَيءٍ» فَقَالُوا: يا رَسُولَ اللهِ إِنَّهُمْ يُحَدِّثُونَنَا أَحْيَاناً بِشَيءٍ فَيَكُونُ حَقًّا؟ فقالَ رَسُولُ اللهِ صلى الله عليه وسلم: «تِلْكَ الكَلِمَةُ مِنَ الحَقِّ يَخْطَفُهَا الجِنِّيُّ فَيَقُرُّهَا فِي أُذُنِ وَلِيِّهِ فَيَخْلِطُونَ مَعَهَا مِئَةَ كَذْبَةٍ» [ متفق عليه ]

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: «Бервакыт кешеләр пәйгамбәребездән ﷺ күрәзәчеләр турында сорадылар, расүлебез моңа: **«Аларның сөйләгән сүзләрендә һичнәрсә дә юк»,** — дип җавап бирде. Алар әйтеләр: «Әй Аллаһның расүле! Ләкин кайбер вакытта алар безгә нәрсә дә булса әйтәләр һәм ул дөрес булып чыга?!». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: **«Ул — дөрес булып чыга торган сүзне, җен тиз генә урлый, ә аннан соң дустының колагына сала, ә алар аңа йөз ялган сүз өстиләр».**

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Яшеренне белү — бер Аллаһка гына хас, аны фәрештәләр дә, пәйгамбәрләр дә белмиләр. Кем дә кем яшеренне беләм дип күрәзәчелек итә икән, ул — кәфер, ялганчы вә шәйтаннарның дусларыннан булган бер зат була, ә Аллаһ тәгалә безгә шәйтанны ачык дошман итеп алырга кушты. Шуңа да, үзен мөселман дип санаган кешегә күрәзәчеләргә барырга, алардан нәрсәне булса да сорарга катгый рәвештә тыела. Кем инде «күрәзәчеләр Аллаһка хас булган яшерен гыйлемне белә» — дип ышанса, ул кеше Коръәнне һәм пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтен ялган кылып, Исламнан чыгып китә. Аллаһ сакласын!

**Файдалар:**

**1)** Мөселман кешесенә, күрәзәчеләрдән нәрсә булса да сорау хәрам.

**2)** Күрәзәчеләр берәр сүзне дөрес әйтсәләр дә, аңа йөз ялган сүз өстиләр.

**3)** Күрәзәчелек хөкеменә шулай ук йолдызнамәләр[9], фал ачу, кәрт белән яки кулдан багу һәм шушыларга охшаш башка нәрсәләр дә керә.

9 Гороскоп

## Тәвәккәллек хакында

•وَمَنْ يَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ فَهُوَ حَسْبُهُ• الطلاق: ٣

Мәгънәсе: **«Кем Аллаһка тәвәккәл итсә, бу аңа җитәдер».**

•وَعَلَى اللَّهِ فَلْيَتَوَكَّلِ الْمُؤْمِنُونَ• التغابن: ١٣

Мәгънәсе: **«Мөэминнәр Аллаһка тәвәккәл итсеннәр!».**

عن أبي هريرةَ رضي اللهِ عنه عن النَّبيّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «يَدْخُلُ الجَنَّةَ أَقْوامٌ أَفْئِدَتُهُمْ مِثْلُ أَفْئِدَةِ الطَّيرِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү һүрайрадан رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Тәвәккәллектә йөрәкләре кошларныкы кебек булган кешеләр, Җәннәткә керерләр».***

عن عُمَرَ رضيِ الله عنه قَالَ: سمعتُ رَسُولَ الله صلى الله عليه وسلم يقولُ: «لَوْ أَنَّكُمْ تَتَوَكَّلُونَ عَلَى اللهِ حَقَّ تَوَكُّلِهِ لَرَزَقَكُمْ كَمَا يَرْزُقُ الطَّيْرَ تَغْدُو خِمَاصاً وَتَرُوحُ بِطَاناً» [ أخرجه الترمذي ]

Мәгънәсе: Гомәр бин әл-Хәттабтан رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә сез Аллаһка тиешлечә тәвәккәл итсәгез, Ул һичшиксез, сезне кошларны ризыкландырган кебек ризыкландырыр иде. Иртән буш карыннары белән очып китәләр, ә көн ахырында карыннарын тутырып кайталар».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Тәвәккәллек, йөрәк гыйбадәтләренең иң хәерлесе, чөнки ул йөрәкнең Аллаһка гына бирелүен һәм нәрсә генә эшләсәң дә, шәригать буенча сәбәпләрен кылып, барча хәлебездә дә Аңа тапшырылуны аңлата. Шуңа да Аллаһ тәгалә тәвәккәл кылучыларны мактап, әҗер-саваплар вәгъдә итте.

**Файдалар:**

**1)** Тәвәккәллек — иң күркәм гыйбадәтләрнең берсе.

**2)** Ризык таләп итүдә Аллаһка таяну һәм сәбәпләрен кылу, кешедә тәвәккәллекнең дөрес булуын күрсәтә.

**3)** Җирдәге вә күкләрдәге барча мәхлукатларны да Аллаһ ризыкландыра.

## 🕮 Сәламләшү хакында

•يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آَمَنُوا لا تَدْخُلُوا بُيُوتًا غَيْرَ بُيُوتِكُمْ حَتَّى تَسْتَأْنِسُوا وَتُسَلِّمُوا عَلَى أَهْلِهَا• النور: ٢٧

Мәгънәсе: **«Ий мөэминнәр! Чит кешеләрнең өйләренә рөхсәт алмыйча һәм өйдә булган кешеләргә сәлам бирмичә кермәгез!».**

عن عبد اللهِ بن عمرو بنِ العاص رضي الله عنهما: أَنَّ رَجُلاً سَأَلَ رسول الله ﷺ : أيُّ الإسلام خَيْرٌ؟ قَالَ: «تُطْعِمُ الطَّعَامَ وَتَقْرَأُ السَّلاَمَ عَلَى مَنْ عَرَفْتَ وَمَنْ لَمْ تَعْرِفْ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр ﵁ әйтте: «Бервакыт бер кеше пәйгамбәребездән ﷺ : «Исламда нәрсә иң яхшы булып санала?» — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ : ***«Кешеләрне ашатуың һәм үзең белгәннәргә дә, белмәгәннәргә дә (мөселманнарга) сәлам бирүең»,*** — диде.

عن أَبي هريرة رضي الله عنه، قَالَ: قَالَ رسول الله ﷺ : «لاَ تَدْخُلُوا الجَنَّةَ حَتَّى تُؤمِنُوا وَلاَ تُؤْمِنُوا حَتَّى تَحَابُّوا أوَلاَ أدُلُّكُمْ عَلَى شَيْءٍ إِذَا فَعَلْتُمُوهُ تَحَابَبْتُمْ؟ أفْشُوا السَّلاَمَ بَيْنَكُمْ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иман китермичә сез Җәннәткә керә алмассыз, ә инде бер-берегезне яратканга кадәр иманлы булмассыз. Сезгә бер-берегезне яратуга китерә торган нәрсәне әйтергәме? Арагызда сәламне таратыгыз!».***

عن عِمْرَان بنِ الحصين رضِي الله عنهما ، قَالَ: جَاءَ رَجُلٌ إِلَى النَّبيِّ صلى الله عليه وسلم فَقَالَ: السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ فَرَدَّ عَلَيْهِ ثُمَّ جَلَسَ فَقَالَ النبيُّ صلى الله عليه وسلم:

«عَشْرٌ» ثُمَّ جَاءَ آخَرُ فَقَالَ: السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللهِ فَرَدَّ عَلَيْهِ فَجَلَسَ فَقَالَ: «عِشْرُونَ» ثُمَّ جَاءَ آخَرُ فَقَالَ: السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللهِ وَبَرَكَاتُهُ فَرَدَّ عَلَيْهِ فَجَلَسَ فَقَالَ: «ثَلاَثُونَ» [ أخرجه أَبُو داود والترمذي ]

Мәгънәсе: Гыймран бин Хусайн ﷺ әйтте: «Бер кеше пәйгамбәребез ﷺ янына килде дә: «Әссәләмү галәйкүм!», — дип әйтте, һәм пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, шуннан соң ул утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : ***«Ун»,*** — диде. Аннан соң икенче кеше килде дә: «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһ!», — дип әйтте. Пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, аннан соң ул утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : ***«Егерме»,*** — диде. Аннан соң өченче кеше килде һәм: «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!», — дип әйтте, һәм пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, шуннан соң теге утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : ***«Утыз»,*** — диде».

عن البراء رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «مَا مِنْ مُسْلِمَينِ يَلْتَقِيَانِ فَيَتَصَافَحَانِ إِلاَّ غُفِرَ لَهُمَا قَبْلَ أَنْ يَفْتَرِقَا» [ أخرجه أَبُو داود ]

Мәгънәсе: Әл-Бәраәдән ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ике мөселман очрашканда бер-берсенең кулларын кысышып күрешсәләр, алар аерылып киткәнчегә кадәр үк гөнаһлары ярлыканыр».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Аллаһ тәгалә сәламне мөселманнарның бер-берсенә карата күркәм гадәтләреннән кылды. Мондый күркәм сәламләшү Исламнан башка бер диндә дә юк. Мөселман сәламләшкәндә бер-берсенә тынычлык, Аллаһның ﷻ рәхмәтен вә бәрәкәтен тели, һәм бу бер-береңә карата мәхәббәт уята, шуңа да расүлебез ﷺ үзара сәламләшүне Җәннәткә керүнең сәбәбе диде. Пәйгамбәребез ﷺ шәригатьтә сәламнең тәртибен аңлатты һәм безгә шәригатебездә күрсәтелгәнчә генә сәламләшергә кирәк, ә инде татарларда билгеле булган «исәнмесез?» ягъни «үлмәдегезмени әле?» — дигән кебек, яки «саумысыз?» ягъни «чирләмәдегезмени әле?» — дигән кебек мәгънәдәге сүзләрдән читләшергә кирәк.

**Файдалар:**

**1)** Сәламләшүнең фазыйләте бик зур.

**2)** Сәламләшү ул мөселманнарның үзара мәхәббәтенә сәбәп, ә мәхәббәт Җәннәткә керүгә сәбәп.

**3)** Мөселманнарның белгәннәренә дә, белмәгәннәренә дә сәлам бирергә кирәк.

**4)** Мөселман сөннәт буенча «Әссәләмү галәйкүм!», — дип сәламли, ә инде арттырып әйтсә херлерәк һәм саваплырак була.

**5)** Кул кысышып күрешү гөнаһларның ярлыкавына сәбәп булып тора.

## 🕮 Бәдрәфтә хаҗәтләрне үтәү әдәбеннән

**Бәдрәфкә кергәндә һәм чыккач укыла торган догалар:**

عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ رضي الله عنه قَالَ: كَانَ النَّبِيُّ صلى الله عليه وسلم إِذَا دَخَلَ الْخَلاَءَ قَالَ: «اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْخُبُثِ وَالْخَبَائِثِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ бәдрәфкә кергәндә болай дип әйтә иде: ***«Йә Аллаһ! Мин Сиңа ир һәм хатын-кыз җенесеннән булган җеннәрдән сыенам».***

عَنْ عَائِشَةَ رضى الله عنها قَالَتْ: كَانَ النَّبِىُّ صلى الله عليه وسلم إِذَا خَرَجَ مِنَ الْخَلاءِ قَالَ: «غُفْرَانَكَ» [ أخرجه أبو داود و الترمذي ]

Мәгънәсе: Гаишә р.г. әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ бәдрәфтән чыккач: ***«(Әй Аллаһ!) Ярлыкавыңны сорыйм»,*** — дип әйтә иде».

عن أبي قتادة رضي الله عنه أن النبيّ صلى الله عليه وسلم قال: «إذا بَالَ أَحَدُكُمْ فَلاَ يَأخُذَنَّ ذَكَرَهُ بِيَمِينِهِ، وَلاَ يَسْتَنْجِ بِيَمِينِهِ، وَلاَ يَتَنَفَّسْ فِي الإِنَاءِ» [ متفق عليه ]

Мәгънәсе: Әбү Катәдәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кайсыгыз булса да бәвел кылса, һичбер очракта да җенси әгъзаларына уң кулы белән тотынмасын һәм уң кулы***

***белән истинҗә кылмасын! Шулай ук эчкәндә савыт өстенә суламасын!».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Исламда тормышның барча яклары да каралган. Булсын ул кечкенә мәсьәләләр яки зур мәсьәләләр, аларның һәммәсенә дә мөселманга бу дөньяда да, ахирәттә дә файда китерә торган хөкемнәр вә әдәпләр куелган. Шушы тормыш заруратларыннан булган мәсьәлә — бәдрәфтә хаҗәт үтәү мәсьәләсе. Пәйгамбәребез ﷺ бу гамәлгә карата әдәпләр вә вәҗибләр күрсәтеп калдырды, мөселманнар инде ул әдәпләрне үтәргә тырышырга тиешләр. Мәсәлән, бәдрәфкә кергәндә шәйтаннардан һәм аларның явызлыкларыннан сакланып Аллаһка сыену тиешле, ә инде аннан чыккач Аллаһтан ярлыкауны сорарга кирәк. Бәдрәфтән чыккач пәйгамбәребезнең ﷺ ошбу доганы укуын гыйлем әһелләре ике мәгънә белән аңлаттылар: 1) Расүлебез ﷺ Аллаһ тәгаләне барча хәлендә дә зикер итә иде, ә бәдрәфтә зикердән тыела иде, шуңа да ошбу зикер итмәгән вакыт өчен Аллаһтан ярлыкау сорый иде. 2) Аллаһ тәгаләнең кешегә биргән ашау, эчү һ.б., хәтта бәдрәфтә хаҗәтен үтәү нигъмәтенә дә Адәм баласы тиешлечә шөкранә итә алмый, шуңа да расүлебез ﷺ ярлыкау сорый иде. Аллаһу әгъләм.

**Файдалар:**

**1)** Мөселман бәдрәфкә кергәндә дә, аннан чыккач та дога укырга тиешле.

**2)** Хаҗәтләрне үтәгәндә кешеләр күрмәслек җиргә ераклашырга кирәк.

**3)** Уң кул белән истинҗа кылырга да, җенес әгъзасын тотарга да ярамый.

## 🕮 Таһәратнең фазыйләтләре хакында

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَرضي الله عنه عَنِ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «لاَ يَقْبَلُ اللَّهُ صَلاَةَ أَحَدِكُمْ إِذَا أَحْدَثَ حَتَّى يَتَوَضَّأَ» [ متفق عليه ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә берегезнең дә намазын таһәратсез кабул итми».***

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رضي الله عنه-قَالَ: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم «إِنَّ أُمَّتِى يُدْعَوْنَ يَوْمَ الْقِيَامَةِ غُرًّا مُحَجَّلِينَ مِنْ آثَارِ الْوُضُوءِ» [ متفق عليه ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, Кыямәт көнендә минем өммәтем таһәрат эзләре аркасында маңгайларыннан һәм аяккулларыннан нур сибеп торучы булып чакырылырлар».***

عن عثمان بن عفان رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله صلى الله عليه وسلم: «من تَوَضَّأَ فَأَحْسَنَ الوُضُوءَ خَرَجَتْ خَطَايَاهُ مِنْ جَسَدِهِ حَتَّى تَخْرُج مِنْ تَحْتِ أَظْفَارِهِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Госман бин Гаффаннан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем тиешенчә таһәрат алса, аның тәненнән гөнаһлары китәр, хәтта тырнак асларында да калмас».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه: أَنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «إِذَا تَوَضَّأَ العَبْدُ المُسْلِمُ - أَوِ المُؤْمِنُ - فَغَسَلَ وَجْهَهُ خَرَجَ مِنْ وَجْهِهِ كُلُّ خَطِيئَةٍ نَظَرَ إِلَيْهَا بعَيْنَيْهِ مَعَ المَاءِ أَوْ مَعَ آخِرِ قَطْرِ المَاءِ فَإِذَا غَسَلَ يَدَيْهِ خَرَجَ مِنْ يَدَيْهِ كُلُّ خَطِيئَةٍ كَانَ بَطَشَتْهَا يَدَاهُ مَعَ المَاءِ أَو مَعَ آخِرِ قَطْرِ المَاءِ فَإذا غَسَلَ رِجْلَيْهِ خَرَجَتْ كُلُّ خَطِيئَةٍ مَشَتْهَا رِجْلاَهُ مَعَ المَاءِ أَو مَعَ آخِرِ قَطْرِ المَاءِ حَتَّى يَخْرُجَ نَقِيَّاً مِنَ الذُّنُوبِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһның колы булган мөселман яки мөэмин таһәрат алса, битен юганда су белән бергә (яки соңгы тамчы су белән бергә) битеннән күзләре белән караган барлык гөнаһлары да юыла; кулларын юганда, су белән бергә (яки соңгы тамчы су белән бергә) куллары белән кылган***

***барлык гөнаһлары да юыла; аякларын юганда, су белән бергә (яки соңгы тамчы су белән бергә) алар белән атлап юнәлгән барлык гөнаһлары да юыла, хәтта ул гөнаһлардан пакь булганга кадәр».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Мөселман, дөнья мәшәкатьләреннән аерылып, Аллаһ каршына намазга басканда зиһене белән гыйбадәттә икәнлеген белү — намазның җәүһәрләреннән булып тора. Таһәрат үзе гыйбадәт санала, шуңа карамастан ул, намаз һәм башка гыйбадәтләрнең ачкычы да булып тора. Мөселман таһәрат алуда бик тә игътибарлы булырга тиеш, чөнки таһәратсез намаз кабул булмый.

**Файдалар:**

**1)** Таһәрат намазның дөреслегенә шарт булып тора.

**2)** Таһәрат гөнаһларның ярлыкавына сәбәп.

**3)** Кыямәт көнендә бу өммәт, йөзләреннән һәм тәннәреннән нур белән билгеле булырлар.

## 🕮 Намазның фазыйләтләре хакында

عَنْ ابْنِ عُمَرَ ﵁ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ : «بُنِيَ الإِسْلامُ عَلَى خَمْسٍ: شَهَادَةِ أَنْ لا إِلَهَ إِلا اللَّهُ وَأَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللهِ وَإِقَامِ الصَّلاةِ وَإِيتَاءِ الزَّكَاةِ و حَجِّ الْبَيْتِ وَصَوْمِ رَمَضَانَ» [ متفق عليه ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ислам биш нигезгә төзелгән: Хакыйкатьтә, Аллаһтан башка илаһ юк һәм Мөхәммәд ﷺ Аның расүле, — дип шәһәдәт кылу, намазны торгызу, зәкәт бирү, Кәгъбәгә хаҗ кылу һәм Рамазанда ураза тоту».***

عن أبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: قال رَسُول اللهِ صلى الله عليه وسلم: «إِنَّ أَوَّلَ مَا يُحَاسَبُ بِهِ العَبْدُ يَوْمَ القِيَامَةِ مِنْ عَمَلِهِ صَلاَتُهُ فَإِنْ صَلَحَتْ فَقَدْ أَفْلَحَ وأَنْجَحَ وَإِنْ فَسَدَتْ فَقَدْ خَابَ وَخَسِرَ فَإِنِ انْتَقَصَ مِنْ فَرِيضَتِهِ شَيْئاً قَالَ الرَّبُ عز وجل: انْظُرُوا هَلْ لِعَبدي من تطوِّع، فَيُكَمَّلُ مِنْهَا مَا انْتَقَصَ مِنَ الفَرِيضَةِ؟ ثُمَّ تَكُونُ سَائِرُ أَعْمَالِهِ عَلَى هَذَا» [ أخرجه التِّرمِذِيُّ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, Кыямәт көнендә кеше иң беренче булып намазлары өчен хисап кылыначак. Әгәр дә намазлары яхшы вә дөрес булса — ул уңышка ирешәчәк, ә әгәр намазлары бозык булса — ул уңышсызлыкка очраячак һәм хәсрәттә булачак. Әгәр аның фарызларын үтәүдә җитешсезлекләр табылса, Аллаһ тәгалә: «Карагыз, аның нәфел намазлары бармы? Шулар белән фарызындагы җитешсезлекләре камилләштерелер», — дип әйтер, ә аннан соң аның барлык калган гамәлләре белән дә шулай ук эшләнер».***

عن بُرَيْدَة رضي الله عنه عن النبيِّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «العَهْدُ الَّذِي بَيْنَنَا وَبَيْنَهُمْ الصَّلاَةُ فَمَنْ تَرَكَهَا فَقَدْ كَفَرَ» [ أخرجه التِّرمِذِيُّ ]

Мәгънәсе: Бүрайдәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Безнең һәм алар арасындагы килешүнең нигезендә намаз тора, ә кем аны ташласа — көферлек кыла».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Намаз Ислам диненең икенче нигезе һәм Аллаһка иң сөйкемле вә иң хәерле гамәлләрдән. Намазның әһәмияте зур булганга күрә, Кыямәт көнендә мөселман иң беренче булып шуның өчен соралачак. Намазның төзеклеге вә тиешлечә үтәлүе — уңышка һәм бәхеткә ирешү сәбәбе, ә инде намазга битараф булу — Кыямәт көнендә хәсрәткә вә кайгыга сәбәп.

**Файдалар:**

**1)** Намаз Исламның икенче нигезе.

**2)** Намаз кешене көферлектән аерып мөселман икәнлеген күрсәтә.

**3)** Кыямәт көнендә иң беренче булып намаз өчен хисап булачак.

## 🕮 Азанның фазыйләтләре хакында

عن معاوية رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ رسول الله صلى الله عليه وسلم يقولُ: «المُؤَذِّنُونَ أَطْوَلُ النَّاسِ أَعْنَاقاً يَوْمَ القِيَامَةِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Мугавия ﵁ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Кыямәт көнендә мәәзиннәр иң озын муенлы кешеләр булырлар».***

عن أَبي سَعيد الخدريَّ رضي الله عنه أنه سمع رَسول الله صلى الله عليه وسلم يقوَل: «إنَّهُ لا يَسْمَعُ مَدَى صَوْتِ المُؤذِّنِ جِنٌّ وَلاَ إنْسٌ وَلاَ شَيْءٌ إلاَّ شَهِدَ لَهُ يَومَ القِيَامَةِ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, кем генә мәәзиннең тавышын ишетсә, булсын ул җен яки кеше яки теләсә нинди башка мәхлук, алар аңа Кыямәт көнендә шәһидлек кылыр».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله صلى الله عليه وسلم: «إِذَا نُودِيَ بِالصَّلاَةِ أَدْبَرَ الشَّيْطَانُ وَلَهُ ضُرَاطٌ حَتَّى لاَ يَسْمَعَ التَّأْذِينَ فَإِذَا قُضِيَ النِّدَاءُ أَقْبَلَ حَتَّي إِذَا ثُوِّبَ للصَّلاةِ أَدْبَرَ حَتَّى إِذا قُضِيَ التَّثْوِيبُ أَقْبَلَ حَتَّي يَخْطِرَ بَيْنَ المَرْءِ وَنَفْسِهِ يَقُولُ: اذكُرْ كَذَا واذكر كَذَا - لِمَا لَمْ يَذكر مِنْ قَبْلُ - حَتَّى يَظَلَّ الرَّجُلُ مَا يَدْرِي كَمْ صَلَّى» [ متفق عليه ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Намазга азан әйтелсә, шәйтан бу азанны ишетмәс өчен, арт ягыннан тавыш белән җил чыгара-чыгара кача, ә азан тәмамлангач, ул яңадан килә. Намазның башлануы турында камәт әйтелгәч, ул тагын кача, ә камәт тәмамлангач, кеше белән аның нәфесе (йөрәге) арасына басып: «Шуның турында һәм моның турын-***

***да искә төшер», — дип, кеше намазга кадәр уйларга да теләмәгән нәрсәләрен аңа искә төшерер өчен, яңадан килә. Хәтта кеше ничә ракәгать намаз укыганын онытсын өчен, ул шулай эшли».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Азан Ислам диненең горурлыгын күрсәтә торган ачык галәмәтләреннән һәм күркәм гыйбадәтләрдән. Аллаһ тәгалә бу гамәлгә карата бик тә зур әҗер-саваплар билгеләде. Кыямәт көнендә кешеләр гамәлләренә күрә тирләренә баткан вакытта, мөәзиннәр иң озын муенлы булып ошбу җәзадан котылырлар. Шулай ук, аларның азанын ишеткән барча мәхлукатлар, Кыямәт көнендә алар өчен шәһидлек кылырлар.

**Файдалар:**

**1)** Азанның фазыйләте бик тә зур һәм аны кычкырып әйтергә тырышырга кирәк.

**2)** Мөәзиннәр Кыямәт көнендә озын муенлы булып барсына да күренеп торырлар.

**3)** Аларның азанын ишеткән барча нәрсә дә алар өчен шәһидлек кылыр.

## 🕮 Азан ишеткәндә әйтелә торган сүзләр

عن أَبي سعيد الخدري رضي الله عنه: أنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «إِذَا سَمِعْتُمُ النِّدَاءَ فَقُولُوا كَمَا يَقُولُ المُؤذِّنُ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Азан ишетсәгез, мөәзин әйткәннәрне кабатлагыз».***

عن معاوية رضي الله عنه أَنَّهُ قَالَ: «لَمَّا قَالَ حَيَّ عَلَى الصَّلاَةِ قَالَ: لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللهِ وَقَالَ: هَكَذَا سَمِعْنَا نَبِيَّكُمْ ﷺ يَقُولُ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Мугавиядән ﵁: «Мөәзин: «حَىَّ عَلَى الصَّلاَةِ» — дип әйткәч, ул: «لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللهِ» — диде, һәм: «Без пәйгамбәребезнең ﷺ шулай дип әйткәнен ишеттек», — диде».

عن جابر رضي الله عنه أنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَنْ قَالَ حِيْنَ يَسْمَعُ النِّدَاءَ: اللَّهُمَّ رَبَّ هذِهِ الدَّعْوَةِ التَّامَّةِ وَالصَّلاَةِ القَائِمَةِ آتِ مُحَمَّداً الوَسِيلَةَ وَالفَضِيلَةَ وَابْعَثْهُ مَقَاماً مَحْمُوداً الَّذِي وَعَدْتَهُ، حَلَّتْ لَهُ شَفَاعَتِي يَوْمَ القِيَامَةِ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Җәбирдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем азан сүзләрен ишеткәндә: «Әй Аллаһ, бу камил чакыруның һәм бу үтәлә торган намазның Раббысы! Мөхәммәдкә ﷺ Җәннәттә иң югары дәрәҗә вә абруй бир һәм аны Син вәгъдә иткән мактаулы урынга юнәлт!», — дип әйтсә, ул кешегә Кыямәт көнендә минем шәфәгатем булачак».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Шәригатебездә азан ишеткән кешегә кагылышлы хөкемнәр бар. Кем намазга чакыру азанын ишетә икән, ул мөәзиннең артыннан кабатларга һәм соңыннан пәйгамбәребезгә салават әйтеп вә Аллаһ тәгаләдән аңа югары дәрәҗәләр сорап дога кылырга тиеш. Моны эшләгән кешене бик зур әҗер-саваплар көтә.

**Файдалар:**

**1)** Мөәзин артыннан кабатлап бару бик тә зур әҗер-савапка ия.

**2)** Мөәзин: «حَىَّ عَلَى الصَّلاَةِ» — дип әйткәч, кабатлап баручы: «لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللهِ» — дип әйтү тиешле.

**3)** Азан әйтелеп беткәч, хәдистә килгән доганы укырга кирәк.

## 🕮 Йорттан чыкканда укыла торган догалар

عن أنس رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولِ الله ﷺ : «مَنْ قَالَ - يَعْنِي: إِذَا خَرَجَ مِنْ بَيتِهِ: بِسمِ اللهِ تَوَكَّلْتُ عَلَى اللهِ وَلا حَول وَلا قُوَّةَ إلاَّ باللهِ، يُقالُ لَهُ: هُدِيتَ وَكُفِيتَ وَوُقِيتَ وَتَنَحَّى عَنْهُ الشَّيطَانُ فيقول - يعني: الشيطان لِشيطان آخر: كَيفَ لَكَ بِرجلٍ قَدْ هُدِيَ وَكُفِيَ وَوُقِيَ؟!» [ أخرجه أبو داود و الترمذي، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әнәстән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем өеннән чыкканда: «Аллаһ исеме белән, Аллаһка тәвәккәллим һәм Аллаһтан башка берәүдән дә көч-куәт юк», — дип әйтүчегә: «Син туры юлдан баручы, тынычсызлык китерә торган нәрсәләрдән котылучы һәм барча явызлыклардан саклanучы», — дип әйтелер, һәм шәйтан аннан ераклашыр, вә ул икенче шәйтанга: «Син туры юлга юнәлтелгән, котылган һәм сакланган кешедән теләгеңә ничек ирешә аласың!?», — дип әйтер».***

عن أمِّ سَلَمَةَ رضي الله عنها أَنَّ النَّبيّ صلى الله عليه وسلم كَانَ إِذَا خَرَجَ مِنْ بَيتِهِ قَالَ: «بِسْمِ اللهِ تَوَكَّلتُ عَلَى اللهِ اللَّهُمَّ إِنِّي أعُوذُ بكَ أنْ أضِلَّ أوْ أُضَلَّ، أوْ أزِلَّ أوْ أُزَلَّ أوْ أظْلِمَ أوْ أُظْلَمَ أوْ أجْهَلَ أوْ يُجْهَلَ عَلَيَّ» [ أخرجه أبو داود و الترمذي و ابن ماجه و النسائي، صحيح ]

Мәгънәсе: Үммү Сәләмә радый Аллаһу ганһә әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ йортыннан чыкканда болай дип әйтә иде: ***«Бисмиллəһ, Аллаһка тәвәккәллим. Йә Аллаһ! Дөреслектә, мин адашудан яки мине башкалар адаштыруыннан, үзем хата җибәрүдән яки мине хаталанырга мәҗбүр итүдән, үзем башкаларга золым кылудан яки миңа золым кылуларыннан, мин башкаларга зыян вә зарар китерә торган җәһилләр гамәленнән яки башкаларның миңа зыян вә зарар китерә торган җәһилләр гамәленнән Синə сыенам».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Йорттан чыкканда укыла торган аерым догалар вә зикерләр бар. Пәйгамбәребез ﷺ бу хакта үзенең өммәтенә җиткереп калдырды. Мөселман кешесе расүлебезгә охшарга тырышып, ул өйрәткән вә кушканнарны үтәргә омтылса, аңа бик тә зур саваплар була һәм шәйтанның явызлыкларыннан саклана, иншәАллаһ.

**Файдалар:**

**1)** Йорттан чыкканда хәдисләрдә килгән зикер вә догаларны әйтү кирәкле санала.

**2)** Ул зикерләрне әйткән мөселманны Аллаһ тәгалә шәйтанның явызлыкларыннан саклый.

**3)** Зикернең фазыйләте вә файдалары бик зур.

## 🕮 Сәфәр әдәпләреннән (1)

عن كعب بن مالك رضي الله عنه: «أَنَّ النبيَّ صلى الله عليه وسلم خَرَجَ في غَزْوَةِ تَبُوكَ يَوْمَ الخَمِيس وَكَانَ يُحِبُّ أَنْ يَخْرُجَ يَوْمَ الْخَميسِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Кәгъб бин Мәлик رضي الله عنه әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ Тәбүк сугышына пәнҗешәмбе чыкты, һәм гомумән, сәфәргә пәнҗешәмбе көннәрен чыгарга ярата иде».***

عن ابن عمرَ رضي اللهُ عنهما قَالَ: قَالَ رسولُ الله ﷺ : «لَوْ أَنَّ النَّاسَ يَعْلَمُونَ مِنَ الوَحْدَةِ مَا أَعْلَمُ، مَا سَارَ رَاكبٌ بِلَيْلٍ وَحْدَهُ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр кешеләр ялгыз сәфәр кылу турында миңа билгеле булган нәрсәләрне белсәләр, бер җайдак[10] та төнлә белән берүзе юлга чыкмас иде».***

عنِ عمرو بن شُعَيْب عن أبيه عنِ جَدهِ رضي الله عنه قَالَ: قَالِ رسولُ الله ﷺ : «الرَّاكِبُ شَيْطَانٌ وَالرَّاكِبَانِ شَيْطَانَانِ وَالثَّلاَثَةُ رَكْبٌ» [ أخرجه أبُو داود والترمذي ]

10 Атлы мөсафир

Мәгънәсе: Гамр бин Шүгайб әтисеннән, бабасыннан ﷺ хәбәр итүенчә: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бер җайдак — шәйтан, ике җайдак — ике шәйтан, ә өч җайдак — кәрван».***

عن أَبِي سعيد وأبي هُريرة رضي الله تَعَالَى عنهما قالا: قَالَ رسولُ الله ﷺ : «إِذَا خَرَجَ ثَلاَثَةٌ في سَفَرٍ فَلْيُؤَمِّرُوا أَحَدَهُمْ» [ أخرجه أَبُو داود ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд һәм Әбү Һурайра ﷺ сүзләреннән риваять ителә: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр өч кеше юлга чыксалар, араларыннан берсен әмир итеп билгеләсеннәр».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه عن رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «إِذَا لَقِيَ أَحَدُكُمْ أَخَاهُ فَلْيُسَلِّمْ عَلَيْهِ فَإِنْ حَالَتْ بَيْنَهُمَا شَجَرَةٌ أَوْ جِدَارٌ أَوْ حَجَرٌ ثُمَّ لَقِيَهُ فَلْيُسَلِّمْ عَلَيْهِ» [ أخرجه أَبُو داود ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сездән кем булса да кардәшен очратса, аңа сәлам бирсен, әгәр аларны бер-берсеннән агач, дивар яки таш аерса, аннан соң янә аның белән очрашкач, аңа сәлам бирсен».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Сәфәрнең, пәйгамбәребез ﷺ күрсәткән сөннәтләре вә әдәпләре бар. Расүлебез ﷺ пәнҗешәмбе көнне сәфәргә чыгарга ярата иде. Шулай ук сәфәргә ялгыз гына чыгудан кисәтеп, юлдаш белән чыгарга өндәде һәм сәфәр вакытында араларында низаг булмасын өчен әмир билгеләргә кушты.

**Файдалар:**

**1)** Сәфәргә чыгарга атнаның пәнҗешәмбе көне яхшырак.

**2)** Ялгыз гына сәфәргә чыгарга ярамый.

**3)** Сәфәргә чыкканда арадан бер кешене әмир итеп билгеләргә кирәк.

**4)** Мөселманнар бергә барганда, аларны агач яки шуңа охшаш нәрсә аерса, очрашкач янә сәламләшергә кирәк.

## Сәфәр әдәпләреннән (2)

عن ابن عمر رضي الله عنهما : أَنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم كَانَ إِذَا اسْتَوَى عَلَى بَعِيرِهِ خَارِجاً إِلَى سَفَرٍ كَبَّرَ ثَلاثاً ثُمَّ قَالَ: «سُبْحَانَ الَّذِي سَخَّرَ لَنَا هَذَا وَمَا كُنَّا لَهُ مُقْرِنِينَ وَإِنَّا إِلَى رَبِّنَا لَمُنْقَلِبُونَ اللَّهمَّ إنا نسألكَ في سفرنا هذا البرّ والتَّقوى ومنَ العملِ ما ترضى اللَّهُمَّ هَوِّنْ عَلَيْنَا سفرَنَا هَذَا وَاطْوِ عَنَّا بُعْدَهُ اللَّهُمَّ أَنْتَ الصَّاحِبُ في السَّفَرِ والخَلِيفَةُ في الأَهْلِ اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ وَعْثَاءِ السَّفَرِ وَكَآبَةِ المَنْظَرِ وَسُوءِ المُنْقَلَبِ في المالِ وَالأَهْلِ وَالوَلَدِ» وَإِذَا رَجَعَ قَالَهُنَّ وَزَادَ فِيهِنَّ: «آيِبُونَ تَائِبُونَ عَابِدُونَ لِرَبِّنَا حَامِدُونَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﵄: «Пәйгамбәребез ﷺ юлга чыкканда, үзенең дөясенә атланганда, өч тапкыр: ***«Аллаһу әкбәр!»,*** — дип тәкбир әйтә иде, ә аннан соң: ***«Безгә моны буйсындырган Затка мактау булсын, бу безнең көчебездән килми, һәм, дөреслектә, без Раббыбызга кайтачакбыз! Әй Аллаһ! Дөреслектә, без Синнән бу сәфәребездә изгелек һәм тәкъвалык, шулай ук Син риза булырлык гамәлләрне үтәүне сорыйбыз! Әй Аллаһ! Бу сәфәребезне безнең өчен җиңeләйт һәм аның ераклыгын безнең өчен кыскарт! Әй Аллаһ! Син бу сәфәрдә юлдаш һәм гаиләнең хәлифе. Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин сәфәрнең авырлыкларыннан, үземнең төшен¬келеккә бирелүемнән, мал, гаилә һәм бала белән була ала торган барлык начарлыктан Сиңа сыенам!»,*** — дип әйтә иде. Кайткач, югарыда әйткәнне кабатлый иде һәм ошбу сүзләрне өсти иде: ***«Без кайтабыз, тәүбә итәбез, гыйбадәт кылабыз һәм Раббыбызны мактыйбыз!».***

**Югарыга менгәндә тәкбир әйтү һәм түбәнгә төшкәндә тәсбих әйтү кирәклеге турында:**

عن جابر ﵁ قَالَ: «كُنَّا إِذَا صَعِدْنَا كَبَّرْنَا وَإِذَا نَزَلْنَا سَبَّحْنَا» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Җәбир ﵁ әйтте: ***«Әгәр югарыга таба күтәрелсәк «Аллаһу әкбәр», — дип тәкбир әйтә идек,***

***ә инде түбәнгә таба төшкәндә «СүбхәнАллаһ», — дип тәсбих әйтә идек».***

**Сәфәрдә вакытта, нинди дә булса өйдә туктала торган кешегә нәрсә әйтергә кирәклеге турында:**

عن خولة بنتِ حَكِيم رضي الله عنها قالت: سَمِعْتُ رسولَ اللهِ صلى الله عليه وسلم، يَقُولُ: «مَنْ نَزَلَ مَنْزِلاً ثُمَّ قَالَ: أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ، لَمْ يَضُرَّهُ شَيْءٌ حَتَّى يَرْتَحِلَ مِنْ مَنْزِلِهِ ذَلِكَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Хаулә бинт Хәким радый Аллаһу ганһә әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: «Әгәр кеше нинди дә булса өйдә тукталса һәм: ***«Аллаһның камил сүзләренә[11], Ул бар кылган нәрсәләрнең явызлыгыннан сыенам!»,***

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ

***— дип әйтсә, бу өйдән киткәнгә кадәр, аңа бернәрсә дә зарар итмәс».***

عن كعب بن مالِكٍ رضي الله عنه: «أَنَّ رسولَ الله صلى الله عليه وسلم كَانَ إِذَا قَدِمَ مِنْ سَفَرٍ بَدَأَ بِالْمَسْجِدِ فَرَكَعَ فِيهِ رَكْعَتَيْنِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Кәгъб бин Мәлик ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ сәфәрдән кайтса, иң әүвәле мәчеткә кереп ике ракәгать намаз укый иде».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Мөсафир кеше игътибар итәргә тиеш булган сәфәр кылуның аерым догалары вә зикерләре бар. Мәсәлән; атка, машинага, очакка, кәрванга[12] һәм башка нәрсәгә утырганда укыла торган догалар; кайтып яки барып җиткәч укыла торган догалар; шулай ук югарыга күтәрелгәндә Аллаһны бөекләү, ә түбәнгә төшкәндә Аны пакьләп тәсбих кылу пәйгамбәребезнең ﷺ һәм сахәбәләрнең сөннәтеннән булып тора; кем дә кем берәр йортка яки кунакханәгә ял итәргә туктаса, Аллаһка сыенып дога кылырга кирәклеген расүлебез ﷺ өйрәтеп калдырды; шулай ук

11 Кәүния һәм шәрыгыя сүзләр керә

12 Бер-бер артлы тезелгән арбалар. Урысча "поезд", – диелә

сәфәрдән кайткач, мөселманга иң әүвәле мәчеткә кереп ике ракәгать намаз укуы күркәм вә яхшы санала.

**Файдалар:**

**1)** Сәфәргә чыкканда һәм сәфәрдән кайткач билгеле булган зикер-догаларны уку сөннәт санала.

**2)** Югарыга күтәрелгәндә тәкбир һәм түбәнгә төшкәндә тәсбих әйтү сөннәт санала.

**3)** Аллаһка сыену кешене барча зарарлардан да саклый.

**4)** Сәфәрдән кайткач иң әүвәле мәчеткә кереп ике ракәгать намаз уку сөннәт булып тора.

## Кәферләргә охшарга ярамаганлык хакында

عن عبد الله بن عمرو رضي الله عنهما أن رسول الله صلى الله عليه وسلم قال: «لَيْسَ مِنَّا مَنْ تَشَبَّهَ بِغَيْرِنَا» [ أخرجه الترمذي، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамрдан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Башка диндәгеләргә охшарга тырышкан кеше бездән түгел».***

عن ابن عمر رضي الله عنهما قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «مَنْ تَشَبَّهَ بِقَوْمٍ فَهُوَ مِنْهُمْ» [ أخرجه أبو داود، تحقيق الألباني: حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем башка кавемгә охшарга тырышса, ул шулардан».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Мөселман кешесенең шәхсыяте башкалардан аерылып торырга тиеш. Чөнки тышкы як белән кәферләргә охшарга тырышу, кешенең эчендә булганын чагылдыра. Шуңа да пәйгамбәребез ﷺ безне кәферләргә, динсезләргә һәм мөшрикләргә охшарга тырышудан бик каты кисәтте.

**Файдалар:**

**1)** Мөселман булмаганнарга охшарга тырышу хәрам.

**2)** Кәферләргә охшарга тырышу зур гөнаһлардан, чөнки аларга охшарга тырышу, аларның диннәренә якынайта.

**3)** Кәферләргә охшау киемдә дә, гадәтләрдә дә һәм башка нәрсәләрдә дә чагылырга мөмкин.

## Кыямәт көнендә кеше үзенең яратканы белән бергә була

عَنْ أَنَس بنِ مَالِكٍ رَضِيَ الله عَنْهُ أنَّ أَعْرَابِياً قَالَ لِرَسُولِ اللهِ صلى الله عليه و سلم: مَتَى السَّاعَةُ؟ قَالَ لَهُ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهِ عَلَيْهِ وَ سَلَّم: «مَا أَعْدَدْتَ لَها؟» قَالَ: حُبُّ اللهِ وَرَسولِه قَال: «أنْتَ مَعَ مَنْ أَحْبَبْتَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик رضي الله عنه әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде дә: «Кайчан Кыямәт көне?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Син Кыямәт көненә нәрсә әзерләдең?»,*** — диде. Теге кеше: «Аллаһка һәм Аның расүленә мәхәббәт әзерләдем», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: **«Син Кыямәт көнендә үзеңнең яраткан кешең белән буласың»,** — диде».

عن عبد الله بنِ مسعود رضي الله عنه قَالَ: جاء رِجلٌ إلى رَسُولِ الله صلى الله عليه وسلم فَقَالَ: يَا رَسُول الله كَيْفَ تَقُولُ في رَجُلِ أَحَبَّ قَوْماً وَلَمْ يَلْحَقْ بِهِمْ؟ فَقَالَ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم: «المَرْءُ مَعَ مَنْ أَحَبَّ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгуд رضي الله عنه әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде дә: «Йә расүл Аллаһ! Әгәр дә бер кеше башка бер төркемне яратса, ләкин аларга әле кушылмаса, бу кеше хакында нәрсә әйтәсең?», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Кеше Кыямәт көнендә үзенең яратканы белән булыр»,*** — диде».

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Аллаһ ризалыгы өчен мәхәббәт һәм Аның ризалыгы өчен нәфрәт — иманның иң югары бәйләнеше. Мөэмин башка мөэминнәргә карата мәхәббәтле һәм кәферләргә карата нәфрәтле булырга тиеш, чөнки бу мәхәббәт һәм нәфрәт, мөэминне Аллаһка якынайта торган дингә керә. Шуңа да кеше бу дөньяда кемне яраткан һәм кемгә карата мәхәббәт белдергән булса, Кыямәт көнендә шуның белән бергә кубарыла.

**Файдалар:**

**1)** Изге кешеләрне ярату — Җәннәттә алар белән бергә булуга сәбәп.

**2)** Кәферләрне һәм фасикъларны яратудан һәм аларга теләктәшлек белдерүдән сакланырга кирәк.

**3)** Кем нинди кешеләрне яратса, ул Кыямәт көнендә алар белән бергә була.

## Эт һәм сурәт хакында

عن أبي طلحة رضي الله عنه أنَّ رسُولَ اللهِ صلى الله عليه وسلم قال: «لاَ تَدْخُلُ المَلاَئِكَةُ بَيْتاً فيهِ كَلْبٌ وَلاَ صُورَةٌ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Талхәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Эт яки сурәт булган йортка фәрештәләр керми».***

عن عبد الله بن مسعودٍ رضي الله عنه قال: سمعتُ رسولَ اللهِ ﷺ يقولُ: «إنَّ أشَدَّ النَّاسِ عَذَاباً يَومَ القِيَامَةِ المُصَوِّرُونَ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгуд ﵁ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Сурәт ясаучылар Кыямәт көнендә иң каты газапка дучар булучылар».***

عن أبي هريرة رضي الله عنه قال: قال رسول الله ﷺ «مَنْ اتَّخَذَ كَلْباً إلا كَلْبَ

مَاشِيَةٍ أَوْ صَيْدٍ أَوْ زَرْعٍ انْتُقِصَ مِنْ أَجْرِه كُلَّ يَوْمٍ قِيرَاطٌ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Этне ау өчен дә, җир һәм терлекне саклар өчен дә тотмаган кешенең савабы көн саен бер кыйратка[13] кимételә».***

عَنِ عبد الله بْنِ الْمُغَفَّلِ أَنّ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «إِذَا وَلَغَ الْكَلْبُ فِى الإِنَاءِ فَاغْسِلُوهُ سَبْعَ مَرَّاتٍ وَعَفِّرُوهُ الثَّامِنَةَ بِالتُّرَابِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мүгаффәлдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр эт савыт-сабадан яласа, аны җиде тапкыр юыгыз һәм сигезенчесендә ком белән сөртегез!».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Җан ияләрен сурәтләү зур гөнаһлардан санала һәм сурәт төшерүчеләр Кыямәт көнендә бик каты газапка тарттырылалар. Шулай ук шәригатебез этләрне бер төрле хаҗәтсез асрарга катгый рәвештә тыйды, чөнки этләрдә кеше вә җәмгыять өчен сәламәтлеккә дә, савапка да зарар бар һәм сурәт вә эт булган йортка фәрештәләр керми. Шуның өчен дә мөселман кешесе Аллаһның һәм Аның расүленең әмерләрен үтәргә тырышып, бу нәрсәләрдән катгый рәвештә читләшергә тиеш.

**Файдалар:**

**1)** Сурәт ясау хәрам һәм зур гөнаһлардан.

**2)** Сурәт ясаучыларны Кыямәт көнендә бик каты газап көтә.

**3)** Ау, җир һәм тереклекне саклау өчен тотылган этләрдән башка, бер төрле этне дә асрарга ярамый.

**4)** Кем шәригатебездә рөхсәт ителгән этләрдән башка этләрне асрый икән, аның көн саен әҗер-савабы кими.

**5)** Эт ялаган урыннар нәҗескә керә, шуңа да ул нәрсәләрне җиде тапкыр юып, сигезенчесен ком белән сөртергә кирәк.

**6)** Сурәт һәм эт булган йортка фәрештәләр керми.

13 Ягъни, изге гамәлләреннән бер өлеше

## 🕮 Йокы әдәпләреннән

عن البراءِ بنِ عازبٍ رضي الله عنهما قالَ: قَالَ لي رسولُ الله ﷺ : «إذَا أَتَيتَ مَضْجعَكَ فتوَضَّأ وَضُوءكَ لِلصَّلاةِ ثُمَّ اضْطَجِعْ عَلَى شِقِّكَ الأيْمَنِ وَقُلْ: اللَّهُمَّ أَسْلَمْتُ نَفْسِي إِلَيْكَ وَوَجَّهْتُ وَجْهِي إِلَيْكَ وَفَوضْتُ أَمْرِي إليكَ وأَلْجأتُ ظَهرِي إِلَيْك، رَغْبَةً وَرهْبَةً إليكَ لا مَلْجأَ وَلاَ مَنْجَا مِنْكَ إلاَّ إليكَ آمَنْتُ بِكِتابِكَ الَّذِي أَنْزَلْتَ وَبِنَبِيِّكَ الَّذِي أَرْسَلْتَ فإنْ مِتَّ مِتَّ عَلَى الفِطْرَةِ وَاجْعَلْهُنَّ آخِرَ مَا تَقُولُ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әл-Бәра бин Газибтән ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ миңа әйтте: ***«Ятакка ятарга теләгәч (йоклар алдыннан), намаз таһәрате ал, ә аннан соң уң ягыңа ят һәм әйт: «Әй Аллаһ! Синнән әҗер өмет итеп һәм дә газабыңнан куркып мин Сиңа буйсындым, гамәлемне Сиңа тапшырдым. Синнән качу һәм котылу юк, иллә мәгәр Сиңа гына сыенабыз! Мин Синең иңдергән Китабыңа, Син җибәргән пәйгамбәреңә иман китердем». Әгәр дә син бу төндә үлсәң, фитрый халәтеңдә (Аллаһка иманлы булып) үләрсең. Шуңа күрә дә бу сүзләр, синең бу көнне әйткән иң соңгы сүзләрең булсыннар!».***

عن حُذَيْفَةَ رضي الله عنه قَالَ: كَانَ النَّبِيُّ صلى الله عليه وسلم إِذَا أَخَذَ مَضْجَعَهُ مِنَ اللَّيْلِ وَضَعَ يَدَهُ تَحت خَدِّهِ ثُمَّ يَقُولُ: «اللَّهُمَّ بِاسْمِكَ أَمُوتُ وَأَحْيَا» وَإِذَا اسْتَيْقَظ قَالَ: «الْحَمْدُ للهِ الَّذِي أَحْيَانَا بَعْدَمَا أَمَاتَنَا وَإِلَيْهِ النُّشُورُ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Хузәйфә ﷺ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ төнлә белән ятакка ятканда (уң) кулын (уң) яңагы астына куя иде һәм: ***«Йә Аллаһ! Мин Синең исемең белән үләм һәм терелəм»,*** — дип әйтә иде. Ә инде уянгач: ***«Безне үлеләндергәннән соң терекләндерүче Аллаһка барча мактаулар булсын һәм кубарылудан соң Аңа кайту!»,*** — дия иде».

عن أبي هريرة رضي الله عنه قال: رَأَى رَسُولُ اللهِ ﷺ رَجُلاً مُضطَجِعاً عَلى بَطْنِهِ فقال: «إنَّ هَذِهِ ضَجْعَةٌ لا يُحِبُّها الله» [ أخرجه الترمذي، تحقيق الألباني: حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﷺ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ бер кешенең эченә (корсагына) ятканын күреп: ***«Хакыйкатьтә,***

***Аллаһ тәгалә болай ятуны сөйми»,*** — диде». Ибен Мәҗәһтә (3724) килгән риваятьтә: ***«Хакыйкатьтә, бу (эчкә яту) Җәһәннәм әһелләренең ятуы»,*** — диде.

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Пәйгамбәребез ﷺ йокы әдәпләрен үзенең хәдисләрендә бәян итте. Ошбу әдәпләрдән: таһәратле булу, йоклар алдыннан һәм уянгач зикер вә догалар уку, ятакка ятканда расүлебез күрсәткәнчә уң якка яту һәм эчкә (корсакка) ятмау.

## 🕮 Аллаһ ризалыгы өчен бер-береңне ярату хакында

عن أَبِي هريرة رضي الله عنه عن النَّبيّ ﷺ قَالَ: «سَبْعَةٌ يُظِلُّهُمُ اللهُ في ظِلِّهِ يَوْمَ لاَ ظِلَّ إلاَّ ظِلُّهُ: إمَامٌ عَادِلٌ، وَشَابٌّ نَشَأ في عِبَادَةِ الله، وَرَجُلٌ قَلْبُهُ مُعَلَّقٌ بالمَسَاجِدِ، وَرَجُلاَنِ تَحَابّا في اللهِ اجْتَمَعَا عَلَيهِ وتَفَرَّقَا عَلَيهِ، وَرَجُلٌ دَعَتْهُ امْرَأةٌ ذَاتُ حُسْنٍ وَجَمَالٍ فَقَالَ: إنِّي أخَافُ الله، وَرَجُلٌ تَصَدَّقَ بِصَدَقَةٍ فَأخْفَاهَا حَتَّى لاَ تَعْلَمَ شِمَالُهُ مَا تُنْفِقُ يَمِينُهُ، وَرَجُلٌ ذَكَرَ الله خَالِياً فَفَاضَتْ عَيْنَاهُ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бернинди күләгә дә булмаган көнне[14] Аллаһ тәгалә җиде төрле кешене (гареш) күләгәсенә алыр: Гадел имамны; Аллаһка гыйбадәт кылып үскән яшь егетне; Йөрәге белән мәчетләргә бәйләнгән кешене; Аллаһ ризалыгы өчен бер-берсен яратучы һәм (бары тик) Аның ризалыгы өчен генә очрашкан һәм аерылышкан ике кешене; Абруйлы һәм матур хатын-кыз (аны теләп үз янына) чакырганда, ул: «Дөреслектә, мин Аллаһтан куркам!», — дип әйткән ир-атны; Садаканы биргәндә, сул кулы уң кулының күпме биргәнен белмичә, яшерен биргән кешене; Шулай ук берүзе генә булганда, Аллаһ тәгаләне зикер итеп күзләре яшь белән тулучыны».***

14 Ягъни, Кыямәт көнендә

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم: «إنّ الله تَعَالى يقول يَوْمَ القِيَامَةِ: أيْنَ المُتَحَابُّونَ بِجَلالِي؟ اليَوْمَ أظِلُّهُمْ فِي ظِلِّي يَوْمَ لاَ ظِلَّ إلاَّ ظِلِّي» [ رواه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә Кыямәт көнендә әйтер: «Минем олуглыгым өчен бер-берсен яратучылар кайда? Бүген Минем күләгәмнән башка күләгә юк, Мин аларны Үзем күләгәлим».***

عن مُعَاذُ بْنُ جَبَل رضي الله عنه قال: فَإِنِّى سَمِعْتُ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ يَقُولُ: «قَالَ اللَّهُ تَبَارَكَ وَتَعَالَى: وَجَبَتْ مَحَبَّتِى لِلْمُتَحَابِّينَ فِىَّ وَالْمُتَجَالِسِينَ فِىَّ وَالْمُتَزَاوِرِينَ فِىَّ وَالْمُتَبَاذِلِينَ فِىَّ» [ حديث صحيح رواه مالك في «الموطأ» بإسناده الصحيح ]

Мәгънәсе: Мүгаз бин Җәбәл ﵁ әйтте: «Хакыйкатьтә, мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Аллаһ тәгалә әйтте: Минем ризалыгым өчен бер-берсен яратучыларга, Минем ризалыгым өчен бер-берсе белән очрашып утыручыларга, Минем ризалыгым өчен бер-берсен зиярат итүчеләргә (бер-берсенә барышып йөрүчеләргә) һәм Минем ризалыгым өчен үзләрен кызганмыйча бер-берсенә ярдәм итүчеләргә, һичшиксез Минем мәхәббәтем булыр!».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه عن النَّبيِّ صلى الله عليه وسلم قال: «أنَّ رَجُلاً زَارَ أَخاً لَهُ في قَرِيَةٍ أُخْرَى، فَأرْصَدَ الله تَعَالَى عَلَى مَدْرَجَتِهِ مَلَكاً، فَلَمَّا أتَى عَلَيهِ قَالَ: أيْنَ تُرِيدُ؟ قَالَ: أُرِيدُ أخاً لي في هذِهِ القَرْيَةِ، قَالَ: هَلْ لَكَ عَلَيهِ مِنْ نِعْمَة تَرُبُّهَا عَلَيهِ؟ قَالَ: لا، غَيْرَ أنّي أحْبَبْتُهُ في الله تَعَالَى، قَالَ: فإنِّي رَسُول الله إلَيْكَ بأنَّ الله قَدْ أحَبَّكَ كَمَا أحْبَبْتَهُ فِيهِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бервакыт бер кеше икенче авылда яшәүче үзенең кардәшен зиярат итәргә юлга чыкты, ә Аллаһ тәгалә фәрештәгә аны бара торган юлында көтеп торырга әмер итте. Бу кеше аның янына җиткәч, фәрештә: «Син кая барасың?», — дип сорады. Ул: «Мин бу авылда яшәүче кардәшемне зиярат итәргә телим», — дип җавап бирде. Фәрештә: «Бәлки син аңа нинди дә булса***

***изгелек кылгансың, ә хәзер шуның файдасын алырга омтыласың?», — диде. Бу кеше: «Юк, дөреслектә, мин аны Аллаһ ризалыгы өчен яратам», — дип җавап бирде. Шунда фәрештә: «Дөреслектә, мин сиңа Аллаһ тарафыннан җибәрелдем, син бу кешене Аллаһ ризалыгы өчен ничек яраткан булсаң, Аллаһ та сине шулай ук ярата», — диде».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Мөселманны Аллаһка итагатьле булганы өчен яратуың — Аллаһ ризалыгы өчен мәхәббәт була. Кешенең Аллаһка итагате арткан саен, ул кешегә карата мәхәббәт тә арта. Бу мәхәббәт иң күркәм гамәлләрдән, чөнки ул байлык та, урын да өчен түгел, бәлки ихластан Аллаһ ризалыгы өчен генә була. Бу төр кешене Аллаһ тәгалә ярата һәм Кыямәт көнендә гареш күләгәсенә ала.

**Файдалар:**

**1)** Аллаһ ризалыгы өчен мәхәббәтнең фазыйләте һәм савабы зур.

**2)** Мөселманнарны Аллаһ ризалыгы өчен яраткан кеше Аллаһның мәхәббәтенә лаек була.

## Чакырган җиргә бару хакында

عن أَبي هريرة رضي الله عنه أنَّ رَسُولِ الله ﷺ قَالَ: «حَقُّ المُسْلِمِ عَلَى المُسْلِمِ خَمْسٌ: رَدُّ السَّلامِ، وَعِيَادَةُ المَريض، وَاتِّبَاعُ الجَنَائِزِ، وَإجَابَةُ الدَّعْوَة، وتَشْميتُ العَاطِسِ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан (رضي الله عنه): Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөселманның башка мөселман каршында биш төрле бурычы бар: Сәламгә җавап кайтару, авыруны зиярат***

***итү (хәлен белү), җеназада катнашу, чакырган җиргә бару һәм төчкерүчегә изгелек теләү[15]».***

عِن ابن عمر رضِيِ الله عنه قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «إذا دُعِيَ أَحَدُكُم إلى الوَلِيمَة فلْيَأْتِهَا» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез аш мәҗлесенә чакырылса, барсын!».***

عن أبي هريرة رضِي الله عنه أنه كان يقول: «بِئسَ الطَّعامُ طَعَامُ الْوَلِيمَة يُدْعَى إلَيْهِ الأَغْنِياءُ وَيُتْرَكُ الْمَسَاكِينُ فَمَنْ لَمْ يَأْتِ الدَّعْوَةَ فَقَدْ عَصَى الله وَرَسُولَه» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайра ﷺ әйтә торган иде: ***«Байлар гына чакырылып, фәкыйрьләр чакырылмаган аш мәҗлесләрендәге ризык — иң начар ризык булып санала. Кем дә кем чакырылган җиргә бармый икән, ул Аллаһка һәм Аның расүленә мәгъсыять итте[16]».***

عن جابر رضِي الله عنه قال: قالِ رسول الله صلِى الله عليه و سلم: «إذا دُعِيَ أَحَدُكُم إلى طَعَامٍ فَلْيُجِب فِإنْ شَاءَ طَعِمَ وَإنْ شَاءَ تَرَكَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбирдән ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез аш мәҗлесенә чакырылса — барсын, теләсә — ашасын, теләмәсә — ашамасын».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Пәйгамбәребез ﷺ чакырган җиргә барырга әмер итте һәм бу гамәл мөселманның башка мөселман каршында булган бурычларыннан, чөнки монда мөселманнарның араларын ныгытуга бәйләнгән зур сәбәпләр ята. Ә кем инде чакыруны сәбәпсез кабул итмәсә, ул Аллаһка һәм Аның расүленә карата гөнаһ кылган була, Аллаһ сакласын.

**Файдалар:**

**1)** Чакырылган җиргә бару тиешле.

15 Әгәр дә төчкерүче «әлхәмдүлилләһ» — дисә, аңа «йәрхәмүкаллаһ» — дип әйтү

16 Буйсынмады

**2)** Бу — мөселманның башка мөселман алдында булган бурычларыннан.

**3)** Чакырылган мәҗлескә баручыны ашарга мәҗбүр итәргә ярамый.

## 🕮 Керергә рөхсәт сорау әдәпләреннән

•يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لا تَدْخُلُوا بُيُوتًا غَيْرَ بُيُوتِكُمْ حَتَّى تَسْتَأْنِسُوا وَتُسَلِّمُوا عَلَى أَهْلِهَا• النور: ٢٧

Мәгънәсе: **«Ий мөэминнәр! Чит кешеләрнең өйләренә рөхсәт сорамыйча һәм йорт әһелләренә сәлам бирмичә кермәгез».**

•وَإِذَا بَلَغَ الأَطْفَالُ مِنْكُمُ الْحُلُمَ فَلْيَسْتَأْذِنُوا كَمَا اسْتَأْذَنَ الَّذِينَ مِنْ قَبْلِهِمْ• النور: ٥٩

Мәгънәсе: **«Әгәр балаларыгыз бәлигъ булсалар, әүвәлге бәләгатькә ирешкәннәрегез рөхсәт сораганнары кебек, ул балаларыгыз да сезнең яныгызга һәрвакыт рөхсәт сорап керсеннәр».**

عن جابرِ رضي الله عنه قَالَ: «أتَيْتُ النبيَّ صلى الله عليه وسلمِ فَدَقَقْتُ البَابَ فَقَالَ: «مَنْ هَذَا؟» فَقُلْتُ: أَنَا فقَالَ: «أنَا أنَا» كَأَنَّهُ كَرِهَهَا» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһ ﵁ әйтте: «Мин пәйгамбәребез ﷺ янына килдем дә, аның ишеген шакыдым, ул: ***«Кем бар?»,*** — дип сорады, мин аңа: «Мин», — дидем. Шуннан соң ул: ***«Мин, мин!»,*** — дип ачуланган кебек әйтте».

عن سهلِ بنِ سعدٍ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله صلى الله عليه وسلم: «إنَّمَا جُعِلَ الاسْتِئذَانُ مِنْ أجْلِ البَصَرِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Сәһл бин Сәгъдтән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Керергә рөхсәт сорау, инсафсыз карашлар аркасында әмер ителде».***

عن كِلْدَةَ بنِ الحَنْبل ﵁ قَالَ: أتَيْتُ النبيَّ ﷺ فَدَخَلْتُ عَلَيْهِ وَلَمْ أُسَلِّمْ، فَقَالَ النَّبيُّ ﷺ: «ارْجِعْ فَقُلْ: السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ أأدْخُل؟» [ أخرجه الترمذي وقال: حديث حسن ]

Мәгънәсе: Килдә бин әл-Хәнбәл رضي الله عنه әйтте: «Бервакыт мин пәйгамбәребез ﷺ янына килдем дә, сәлам бирмичә кердем, шуннан соң ул миңа: ***«Яңадан әйләнеп кил һәм: «Әссәләмү галәйкүм, миңа керергә мөмкинме?», — дип әйт», —*** диде».

عن أبي موسى الأشعاري رضي الله عنه قال: قَالَ لي رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه
وسلم: «إِذَا اسْتَأْذَنَ أَحَدُكُمْ ثَلَاثًا فَلَمْ يُؤْذَنْ لَهُ فَلْيَرْجِعْ»[ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Муса әл-Әшгарийдән رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез керергә өч тапкыр рөхсәт сорап та аңа рөхсәт ителмәсә, кире китсен!».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Кешеләрнең гаурәтләрен һәм намусларын саклау йөзеннән шәригатебез чит кешеләр йортына кергәндә рөхсәт сорап керүне билгеләде. Өч тапкыр ишекне шакып та, яки керергә рөхсәт сорап та дәшмәсәләр, башка шакымыйча кире борылып китәргә кирәк.

**Файдалар:**

**1)** Чит йортка кергәнче рөхсәт сорарга кирәк.

**2)** Әгәр дә ишек шакучыдан “син кем” — дип соралса, ул: “мин инде” яки “ач әйдә” — дигән кебек сүзләрсез генә, үзенең исемен әйтергә тиешле.

**3)** Ишек шакып рөхсәт сорау өч тапкыр гына була. Рөхсәт ителсә керә, ителмәсә кире китә.

## Шәйтанның мөселманнар арасына фетнә салуыннан саклану хакында

•وَقُلْ لِعِبَادِي يَقُولُوا الَّتِي هِيَ أَحْسَنُ إِنَّ الشَّيْطَانَ يَنْزَغُ بَيْنَهُمْ
إِنَّ الشَّيْطَانَ كَانَ لِلْإِنْسَانِ عَدُوًّا مُبِينًا• الإسراء: ٥٣

Мәгънәсе: **«Минем колларыма әйт, бер-берсе белән яхшы сүзләр белән генә сөйләшсеннәр! Әгәр дә алар шулай эшләмәсәләр, шәйтан аларның арасына ызгыш вә талаш салыр. Хакыйкатьтә, шәйтан кешеләргә ачык дошман булды».**

عن جابر رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ رسول الله ﷺ يقولُ: «إِنَّ الشَّيْطَانَ قَدْ يَئِسَ أَنْ يَعْبُدَهُ المُصَلُّونَ فِي جَزِيرَةِ العَرَبِ، وَلَكِنْ في التَّحْرِيشِ بَيْنَهُمْ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһ ﵁ әйтте: «Хакыйкатьтә, мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Хакыйкатьтә, шәйтан, Гарәбстанда намаз кылучылар аңа (шәйтанга) гыйбадәт кылудан өметен өзде, әмма ул һаман да, алар арасында ызгыш таратып булыр, дип өметләнә».***

عَنْ جَابِرٍ رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ النَّبِيَّ ﷺ يَقُولُ: «إِنَّ عَرْشَ إِبْلِيسَ عَلَى الْبَحْرِ فَيَبْعَثُ سَرَايَاهُ فَيَفْتِنُونَ النَّاسَ فَأَعْظَمُهُمْ عِنْدَهُ أَعْظَمُهُمْ فِتْنَةً» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһ ﵁ әйтте: «Хакыйкатьтә, мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Хакыйкатьтә, иблиснең гареше диңгездә, ул шуннан үзенең гакәрләрен кешеләр арасына фетнә салырга җибәрә, һәм иблискә аларның иң якыны — иң күп фетнә ясаганы».***

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ مَسْعُودٍ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ : «مَا مِنْكُمْ مِنْ أَحَدٍ إِلاَّ وَقَدْ وُكِّلَ بِهِ قَرِينُهُ مِنَ الْجِنِّ». قَالُوا وَإِيَّاكَ يَا رَسُولَ اللَّهِ؟ قَالَ: «وَإِيَّاىَ، إِلاَّ أَنَّ اللَّهَ أَعَانَنِى عَلَيْهِ فَأَسْلَمَ (فَأَسْلَمُ) فَلاَ يَأْمُرُنِى إِلاَّ بِخَيْرٍ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгудтан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сезнең һәрберегезгә җен юлдашы беркетелде».*** Сорадылар: «Сиңадамы йә расүл Аллаһ?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әйе, миңа да, иллә мәгәр Аллаһ тәгалә миңа ул җенгә карата ярдәм бирде һәм ул буйсынып мине яхшылыкка гына өнди».*** (Икенче риваятьтә (فَأَسْلَمُ...) дип укылды: ***«мин аның явызлыгыннан иминмен һәм ул мине яхшылыкка гына өнди».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Шәйтанның кешеләргә дошманлыгы хакында һәм аның явызлыкларыннан вә мәкерләреннән сакланырга кушып, Аллаһ тәгалә Коръәндә хәбәр итте. Иблиснең иң яраткан гамәлләреннән, мөселманнар арасына фетнә салу, шуңа да мөселман һәрвакыт уяу булып, башка кардәшләренә ягымлы сүзләр генә сөйләргә тиеш.

**Файдалар:**

**1)** Иблис мөэминнәргә ачык дошман.

**2)** Мөселманнар арасында фетнә чыкса, аны Аллаһның Коръәненә вә пәйгамбәребезнең сөннәтенә кайтып хәл итү тиешле.

**3)** Фетнәләр шәйтанның яраткан гамәле.

## Сабырлык хакында

•إِنَّمَا يُوَفَّى الصَّابِرُونَ أَجْرَهُمْ بِغَيْرِ حِسَابٍ• الزمر: ١٠

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, сабыр итүчеләргә хисапсыз әҗер-саваплар бирелер»**.

•وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ• البقرة: ١٥٥

Мәгънәсе: **«Сабырларны шатландыр».**

عن عطَاء بن أبي رَباحِ قَالَ: قَالَ لي ابنُ عَباس رضي اللهُ عنهما: «ألاَ أُريكَ امْرَأةً مِنْ أَهْلِ الجَنَّةِ؟ فَقُلْتُ: بَلَى، قَالَ: هذِهِ المَرْأةُ السَّوداءُ أتتِ النَّبيَّ صلى الله عليه وسلم فَقَالَتْ: إنّي أُصْرَعُ وإنِّي أتَكَشَّفُ، فادْعُ الله تَعَالَى لِي، قَالَ: «إنْ شئْتِ صَبَرتِ وَلَكِ الجَنَّةُ وَإنْ شئْتِ دَعَوتُ الله تَعَالَى أنْ يُعَافِيكِ» فَقَالَتْ: أصْبِرُ، فَقَالَتْ: إنِّي أتَكَشَّفُ فَادعُ الله أنْ لا أَتَكَشَّف، فَدَعَا لَهَا» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Гата бин Әбү Рабәх ﵁ әйтте: «Бервакыт ибен Габбас ﵁ миңа: «Сиңа Җәннәт әһелләреннән булган хатынны күрсәтергәме?», — диде. Мин: «Әйе», — дидем. Ул: «Мәнә

бу кара тәнле хатын үз вакытында пәйгамбәребезгә ﷺ килеп: «Минем егылу өянәгем бар һәм (шул сәбәпле) минем гаурәтем ачыла. Син Аллаһ тәгаләгә минем өчен дога кыл», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа җавап биреп: ***«Теләсәң сабыр ит, моның өчен сиңа Җәннәт булыр, ә инде теләсәң, мин синең терелүеңне сорап Аллаһка дога кылам»,*** — диде. Ул пәйгамбәребезгә ﷺ : «Мин сабыр итәрмен», — диде, ә соңыннан: «Дөреслектә, минем гаурәтем ачыла, Аллаһтан гаурәтем ачылмауны сора», — дип өстәде, һәм пәйгамбәребез ﷺ аның гаурәтен ачылмавын сорап Аллаһка дога кылды».

عن صهيبِ بنِ سنانٍ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسولُ الله ﷺ : «عَجَباً لأمْرِ المُؤمنِ إِنَّ أمْرَهُ كُلَّهُ لَهُ خيرٌ وليسَ ذلِكَ لأَحَدٍ إلاَّ للمُؤْمِن: إنْ أَصابَتْهُ سَرَّاءُ شَكَرَ فَكَانَ خيراً لَهُ، وإنْ أصَابَتْهُ ضرَاءُ صَبرَ فَكانَ خَيْراً لَهُ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Суһәйб бин Синәннән رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ни гаҗәеп мөэминнең халәте! Дөреслектә, аның барча халәте дә аның өчен хәерле һәм бу мөэминнән башка беркемгә дә бирелмәде: әгәр аны бер нәрсә шатландырса, ул Аллаһка шөкер итә һәм бу аның өчен хәерле була; әгәр аңа бәла ирешсә, ул сабырлык күрсәтә һәм бу да аның өчен хәерле була».***

عَنِ ابْنِ عُمَرَ رَضِي الله عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلي الله عليه وسلم: «الْمُؤْمِنُ الَّذِى يُخَالِطُ النَّاسَ وَيَصْبِرُ عَلَى أَذَاهُمْ أَعْظَمُ أَجْرًا مِنَ الْمُؤْمِنِ الَّذِى لاَ يُخَالِطُ النَّاسَ وَلاَ يَصْبِرُ عَلَى أَذَاهُمْ» [ أخرجه ابن ماجه، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кешеләр белән аралашмыйча һәм аларның интектерүләренә дә сабыр итмәүче мөэмин-мөселманга караганда, кешеләр белән аралашып һәм аларның интектерүләренә сабыр итүче мөэмин күпкә әҗер-саваплырак».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Динебездә сабырлыкның урыны зур, чөнки динебез тулысы белән сабырлыкка бәйләнгән: 1) Аллаһ тәгаләгә итагать итүдә сабырлык. 2) Хәрамнардан саклануда сабырлык. 3) Аллаһның

билгеләгән тәкъдиренә сабырлык. Сабыр итүче барча яклап та табышта, чөнки ул Аллаһка итагать итеп әҗер-савапка ирешә.

**Файдалар:**

**1)** Динебездә сабырлыкның фазыйләте зур.

**2)** Сабырлык Җәннәткә ирешүгә сәбәп.

**3)** Сабырларны хисапсыз саваплар көтә.

## Авырулар һәм чирләр — гөнаһларга ярлыкау

عن أبي هريرةَ رضيَ الله عنه عنِ النَّبيِّ ﷺ قَالَ: «مَا يُصيبُ المُسْلِمَ مِنْ نَصَبٍ وَلاَ وَصَبٍ وَلاَ هَمٍّ وَلاَ حَزَنٍ وَلاَ أذىً وَلاَ غَمٍّ حَتَّى الشَّوكَةُ يُشَاكُهَا إلاَّ كَفَّرَ اللهُ بِهَا مِنْ خَطَايَاهُ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөселман нәрсәгә генә дучар булмасын — арумы яки чирме, борчылумы яки кайгымы, хәлсезлекме яки авыр кайгымы[17], хәтта чәнечкеле үләннең (кечкенә) энәсе яки шырпысы кадалумы, болар өчен Аллаһ, һичшиксез, аның гөнаһларын ярлыкый».***

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بن مسعود رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ قال: أَتَيْتُ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فِي مَرَضِهِ وَهُوَ يُوعَكُ وَعْكًا شَدِيدًا وَقُلْتُ: إِنَّكَ لَتُوعَكُ وَعْكًا شَدِيدًا، إِنَّ ذَاكَ بِأَنَّ لَكَ أَجْرَيْنِ؟ قَالَ: «أَجَلْ، مَا مِنْ مُسْلِمٍ يُصِيبُهُ أَذًى إِلا حَاتَّ اللَّهُ عَنْهُ خَطَايَاهُ كَمَا تَحَاتُّ وَرَقُ الشَّجَرِ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгуд ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ авырган вакытта мин аның янына кердем, аның тәне ут кебек кызу иде һәм аннан: «Синең тәнең бик тә нык кызу, башкаларга караганда сиңа икеләтә әҗер булган өченме бу?»,

17 Кешегә олы кайгы килсә, яки кайгы артып вә көчәеп торса, ул һуштан яза

— дип сорадым. Пәйгамбәребез ﷺ : ***«Әйе, мөселман нинди генә авырлык күрмәсен, Аллаһ тәгалә аның гөнаһларын, агач яфраклары коелган кебек кояр (ярлыкар)»,*** — диде.

عن جابرِ بنِ عبد الله رضي الله عنه: أنَّ رسُولَ اللهِ ﷺ دخلَ على أُمِّ السَّائِبِ أو أُمِّ المُسَيِّبِ فَقَالَ: «مَا لَكِ يَا أُمَّ السَّائِبِ - أو يَا أُمَّ المُسَيَّبِ - تُزَفْزِفِينَ؟» قَالَتْ: الحُمَّى لاَ بَارَكَ اللهُ فِيهَا! فَقَالَ: «لاَ تَسُبِّي الحُمَّى فَإنَّهَا تُذْهِبُ خَطَايَا بَنِي آدَمَ كَمَا يُذْهِبُ الكِيْرُ خَبَثَ الحَدِيدِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһ ﷺ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ Үммү әс-Сәәиб /яки Үммү әл-Мүсәййәб/ янына кереп, (аннан) сорады: ***«Ни өчен син калтырыйсың, йә Үммү әс-Сәәиб /яки Үммү әл-Мүсәййәб/?».*** Ул әйтте: «Бизгәк сәбәпле, Аллаһның бәрәкәте юк анда!». Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Бизгәкне сүкмә, чөнки, дөреслектә, ул Адәм балаларының гөнаһларын, тимерченең күреге тимернең касмагын[18] бетергән кебек бетерә!»,*** — диде.

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Аллаһның бәндәләргә булган рәхмәтеннән, мөселман кешесе бу дөньяда нинди генә авырлыкка яки чиргә дучар булмасын, әгәр дә сабырлык күрсәтә икән, Аллаһ тәгалә аның гөнаһларын гафу итә. Мөселманга бу Аллаһтан нигъмәт.

**Файдалар:**

**1)** Авыруларга һәм авырлыкларга сабыр булырга кирәк.

**2)** Аллаһның рәхмәте киң һәм сабырларны зур саваплар көтә.

18 Шлак

## 🕮 Аллаһтан курку хакында

•وَلِمَنْ خَافَ مَقَامَ رَبِّهِ جَنَّتَانِ• الرحمن: ٤٦

Мәгънәсе: **«Раббысы алдына басып хөкем ителүдән курыккан мөэмингә оҗмахта ике бакча әзерләнгән».**

•وَأَمَّا مَنْ خَافَ مَقَامَ رَبِّهِ وَنَهَى النَّفْسَ عَنِ الْهَوَى ۞
فَإِنَّ الْجَنَّةَ هِيَ الْمَأْوَى••• النازعات: ٤٠-٤١

Мәгънәсе: **«Әмма берәү Аллаһ алдына басып хөкем ителүдән курыкса, вә үзенең нәфесен хәвәскә бирелүдән тыйса, әлбәттә, аның урыны Җәннәт».**

عن أَبِي هريرة رضي الله عنه عن النَّبيّ ﷺ قَالَ: «سَبْعَةٌ يُظِلُّهُمُ اللهُ في ظِلِّهِ يَوْمَ لاَ ظِلَّ إلاَّ ظِلُّهُ: إمَامٌ عَادِلٌ، وَشَابٌّ نَشَأ في عِبَادَةِ الله، وَرَجُلٌ قَلْبُهُ مُعَلَّقٌ بالمَسَاجِدِ، وَرَجُلاَنِ تَحَابَّا في اللهِ اجْتَمَعَا عَلَيهِ وتَفَرَّقَا عَلَيهِ، وَرَجُلٌ دَعَتْهُ امْرَأةٌ ذَاتُ حُسْنٍ وَجَمَالٍ فَقَالَ: إنِّي أخَافُ الله، وَرَجُلٌ تَصَدَّقَ بِصَدَقَةٍ فَأَخْفَاهَا حَتَّى لاَ تَعْلَمَ شِمَالُهُ مَا تُنْفِقُ يَمِينُهُ، وَرَجُلٌ ذَكَرَ الله خَالِياً فَفَاضَتْ عَيْنَاهُ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бер төрле күләгә дә булмаган көнне (ягъни, Кыямәт көнендә) Аллаһ тәгалә җиде төрле кешене (гареш) күләгәсенә алыр: Гадел имамны; Аллаһка гыйбадәт кылып үскән яшь егетне; Йөрәге белән мәчетләргә бәйләнгән кешене; Аллаһ ризалыгы өчен бер-берсен яратучы һәм бары тик Аның ризалыгы өчен генә очрашкан һәм аерылышкан ике кешене; Абруйлы һәм матур хатын-кыз (аны теләп үз янына) чакырганда, ул: «Дөреслектә, мин Аллаһтан куркам!», — дип әйткән ир-атны; Садаканы биргәндә, сул кулы уң кулының күпме биргәнен белмичә, яшерен биргән кешене; Шулай ук берүзе генә булганда, Аллаһ тәгаләне зикер иткәндә күзләре яшь белән тулучыны».***

عن ابن عباس رضي الله عنهما قَالَ: سَمِعْتُ رسولَ اللهِ صلى الله عليه وسلم يقول: «عَيْنَانِ لاَ تَمسُّهُمَا النَّارُ: عَيْنٌ بَكَتْ مِنْ خَشْيَةِ اللهِ، وَعَيْنٌ بَاتَتْ تَحْرُسُ في سَبيلِ اللهِ» [ أخرجه الترمذي و له شواهد، صحيح لغيره ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас رضي الله عنه әйтте: «Хакыйкатьтә, мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Ике төрле күзгә Җәһәннәм уты кагылмаячак: Аллаһтан куркып елаган күзгә һәм Аллаһ юлында төнне сакта торып үткәргән күзгә».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Аллаһтан курку, йөрәкнең зур гыйбадәтләреннән санала һәм ул ихлас мөэминдә генә чагыла. Шуның өчен дә аның фазыйләте дә, савабы да зур. Дөрес һәм мактала торган курку, Аллаһка итагатьне арттыра һәм хәрамнардан ераклаштыра.

**Файдалар:**

**1)** Аллаһтан куркуның фазыйләте зур.

**2)** Аллаһтан курку — хәрамнардан вә гөнаһлардан ераклаштыра.

**3)** Аллаһтан курку — Җәннәткә керергә сәбәп.

## 🕮 Монафикъларның сыйфатлары

•إِنَّ الْمُنَافِقِينَ يُخَادِعُونَ اللَّهَ وَهُوَ خَادِعُهُمْ وَإِذَا قَامُوا إِلَى الصَّلاةِ قَامُوا
كُسَالَى يُرَاءُونَ النَّاسَ وَلا يَذْكُرُونَ اللَّهَ إِلا قَلِيلا• النساء: ١٤٢

Мәгънәсе: **«Әлбәттә, монафикълар Аллаһны алдыйбыз дип уйлыйлар, ләкин Аллаһ исә аларны алдаучыдыр. Әгәр монафикълар намазга торсалар — ялкауланып кына, кешеләр күрсен дип кенә торалар, һәм Аллаһны бик аз гына зикер итәләр».**

عن عبد الله بن عمرو بن العاص رضي الله عنهما أَنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «أَرْبَعٌ مَنْ كُنَّ فِيهِ كَانَ مُنَافِقاً خَالِصاً، وَمَنْ كَانَتْ فِيهِ خَصْلَةٌ مِنْهُنَّ كَانَتْ فِيهِ خَصْلَةٌ مِنَ النِّفَاقِ حَتَّى يَدَعَهَا: إِذَا اؤْتُمِنَ خَانَ، وَإِذَا حَدَّثَ كَذَبَ، وَإِذَا عَاهَدَ غَدَرَ، وَإِذَا خَاصَمَ فَجَرَ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дүрт төрле сыйфатка ия булган кеше чын монафикъ була, ә ул сыйфатларның берсе булганы, аннан котылганга кадәр, нифакъ (икейөзлелек) сыйфаты белән билгеле була: Әманәткә хыянәт итә, сөйләгәндә ялганлый, килешүне боза һәм кем белән булса да низаглашканда хаклыктан читләшә (ялган антлар һәм ялган гаепләүләр кыла)».***

عن أبي هريرة رضي الله عنه أنَّ رَسُول اللهِ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «لَيْسَ صَلاَةٌ أَثْقَلَ عَلَى المُنَافِقِينَ مِنْ صَلاَةِ الفَجْرِ وَالعِشَاءِ، وَلَوْ يَعْلَمُونَ مَا فِيهِمَا لأَتَوْهُمَا وَلَوْ حَبْواً» [ متفقٌ عَليهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Монафикълар өчен иртәнге һәм ястү намазларыннан да авыррак намаз юк, әгәр дә алар бу ике намаз өчен нинди савап көткәнен белсәләр, һичшиксез, мәчеткә мүкәләп (мүкәйләп, шуышып) булса да килерләр иде».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Монафикъларның сыйфатлары күп. Аллаһ тәгалә Коръәндә һәм пәйгамбәребез ﷺ хәдисләрендә өммәтебезгә бу сыйфатлардан сакланырга кушты, чөнки бу кабахәт сыйфатлар, һәм бу сыйфатлар мөселманны диннән ерагайта. Шул сыйфатлардан: Әманәткә хыянәт, ялганлау, килешүгә хыянәт, ялган антлар, ялган гаепләүләр, иртәнге һәм ястү намазларына авырлык белән тору. Мөселман кешесе бу сыйфатларны белергә һәм сакланырга тиеш.

**Файдалар:**

**1)** Әманәткә хыянәт, ялганлау, килешүгә хыянәт, ялган антлар, ялган гаепләүләр, иртәнге һәм ястү намазларына авырлык белән тору — монафикълар сыйфатыннан.

**2)** Шулай ук Аллаһны аз зикер итү нифакълык сыйфаты.

**3)** Мөселман бу сыйфатлардан сакланырга тиеш.

## 🕮 Дуслар һәм иптәшләр сайлау хакында

•الأخِلاءُ يَوْمَئِذٍ بَعْضُهُمْ لِبَعْضٍ عَدُوٌّ إِلا الْمُتَّقِينَ• الزخرف: ٦٧

Мәгънәсе: **«Дөньяда вакытта Аллаһ ризалыгыннан башка бер-берсенә дус булган кешеләр, Кыямәт көнне бер-берсенә дошман булырлар, мәгәр дөньяда Аллаһ ризалыгы өчен дус булган тәкъва мөэминнәр генә, ахирәттә дус булырлар».**

عن أَبي موسى الأشعري رضي الله عنه أن النبي ﷺ قَالَ: «إِنَّمَا مَثَلُ الجَلِيسِ الصَّالِحِ وَجَلِيسِ السُّوءِ كَحَامِلِ المِسْكِ وَنَافِخِ الْكِيرِ، فَحَامِلُ الْمِسْكِ إِمَّا أَنْ يُحْذِيَكَ وَإِمَّا أَنْ تَبْتَاعَ مِنْهُ وَإِمَّا أَنْ تجِدَ مِنْهُ رِيحاً طَيِّبَةً، وَنَافِخُ الكِيرِ إِمَّا أَنْ يُحْرِقَ ثِيَابَكَ وَإِمَّا أَنْ تجِدَ مِنْهُ رِيحاً خَبيثة» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Муса әл-Әшгарийдан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, яхшы дус белән яман дус, хушбуй сатучы белән тимерче күреген өрдерүче кебек. Хушбуй сатучыга килгәндә, ул яки үзенең хушбуеннан сиңа бүләк итә, яки син аңардан бу хушбуйны сиңа сатуны сорыйсың, яки инде син аңардан килгән хуш исне тоясың. Күрек өрдерүчегә килгәндә, ул яки синең киемеңне яндыра, яки син аңардан килгән начар исне тоясың».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه أن النَّبيّ ﷺ قَالَ: «الرَّجُلُ عَلَى دِينِ خَلِيلِهِ فَلْيَنْظُرْ أَحَدُكُمْ مَنْ يُخَالِلُ» [ أخرجه أبُو داود والترمذي، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кеше үзенең якын дусты тоткан динне тота, сезнең һәркайсыгыз кем белән дуслашырга җыенуына игътибар итсен!».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Дуслар һәм иптәшләр кешегә бик тә зур йогынты ясый. Күп вакытта кеше үзенең дусларының яхшы яки начар холыкларын ала. Шуңа да расүлебез ﷺ яхшы гына дусларны иптәш итеп алырга өндәде һәм аларны хушбуй сатучыга охшатты, ә инде начар дусларны күрек өрдерүчегә охшатып, алардан

бары тик начар сыйфатларны гына алырга мөмкинлеген бәян итте.

**Файдалар:**

**1)** Кем дә кем дуслыгын Аллаһ ризалыгы өчен кылмаса, аның бу дуслыгы Кыямәт көнендә дошманлыкка әйләнер.

**2)** Иманлы вә яхшы дусларны сайларга кирәк.

**3)** Иптәш үзенең дустына бик тә зур йогынты ясый.

## Ачуны тыю хакында һәм ачуланганда нәрсә әйтергә кирәклеге турында

عنِ أبي هريرةَ رضي الله عنه أنَّ رَجُلاً قَالَ للنبي صلى الله عليه وسلم: أوصِني، قَال: «لا تَغْضَبْ»، فرَدَّدَ مِراراً، قَال: «لاَ تَغْضَبْ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде дә: «Миңа нәсыйхәт бир!», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ : ***«Ачуланма!»,*** — диде. Бу кеше сүзләрен тагын берничә тапкыр кабатлады, ләкин расүлебез аның һәр кабатлавында: ***«Ачуланма»,*** — диде».

عنِ أبي هريرةَ رضي الله عنه أنّ رسولَ الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «لَيْسَ الشَّدِيدُ بالصُّرَعَةِ إنَّمَا الشَدِيدُ الَّذِي يَملكُ نَفْسَهُ عِنْدَ الغَضَبِ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кешеләрне күп җиңүче көчле түгел, ләкин ачуланганда үзен кулга ала белүче көчле».***

عَنْ أَبِى ذَرٍّ رِضيِ الله عنه أنَّ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «إذَا غَضِبَ أَحَدُكُمْ وَهُوَ قَائِمٌ فَلْيَجْلِسْ فَإِنْ ذَهَبَ عَنْهُ الْغَضَبُ وَإِلاَّ فَلْيَضْطَجِعْ» [ أَخرجه أبو داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Зәррдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез ачуланса һәм ул басып тора торган булса — утырсын, алай да ачуы басылмаса — ятсын!».***

عَنْ سُلَيْمَانَ بْنُ صُرَدٍ قَالَ: اسْتَبَّ رَجُلاَنِ عِنْدَ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم وَنَحْنُ عِنْدَهُ جُلُوسٌ وَأَحَدُهُمَا يَسُبُّ صَاحِبَهُ مُغْضَبًا قَدِ احْمَرَّ وَجْهُهُ فَقَالَ النَّبِيُّ صلى الله عليه وسلم: «إِنِّى لأَعْلَمُ كَلِمَةً لَوْ قَالَهَا لَذَهَبَ عَنْهُ مَا يَجِدُ لَوْ قَالَ: أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Сөләймән бин Сурад ﷺ әйтте: «Бервакыт без пәйгамбәребез ﷺ янында утырганда ике кеше үзара талаша башладылар һәм аларның берсенең икенчесенә ачудан хәтта йөзе кызарып чыкты. Шунда пәйгамбәребез ﷺ болай диде: ***«Дөреслектә, мин шундый сүзләрне беләм, әгәр дә ул аларны әйтсә, һичшиксез тынычланыр иде: «Ләгънәт кылынган шәйтаннан Аллаһка сыгынам», /әгүзү билләһи минәш-шәйтанир-ражим/».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Ачулану — кешене гөнаһка илтә торган шәйтанның йогынтысыннан булган кабахәт сыйфатлардан. Шуңа да расүлебез ﷺ бу сыйфаттан сакланырга кушты һәм дә аның юлын өйрәтте.

**Файдалар:**

**1)** Пәйгамбәребез ﷺ ачудан тыелырга кушып һәм дә ачуланган вакытта үзен кулга ала белгән кешене мактап васыять кылды.

**2)** Ачуланган кеше басып тора торган булса, пәйгамбәребез ﷺ аңа утырырга кушты, ә инде алай да тынычланмаса ятарга боерды.

**3)** Шулай ук расүлебез ﷺ ачуланган кешегә, шәйтанның явызлыгыннан Аллаһка сыгынырга кушты.

## 🕮 Уң тарафның өстенлеге хакында

عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْها قَالَتْ: «كَانَ النَّبِيُّ صلى الله عليه وسلم يُعْجِبُهُ التَّيَمُّنُ فِى تَنَعُّلِهِ وَتَرَجُّلِهِ وَطُهُورِهِ وَفِى شَأْنِهِ كُلِّهِ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ аяк киемен кигәндә дә, чәчен тараганда да, таһәрат алганда да, яки бөтен эштә дә, уң яктан башлауны яхшырак күрә иде».***

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ الله عَنْهُ أَنَّ رسول الله صلي الله عليه وسلم قَالَ: «إِذَا انْتَعَلَ أَحَدُكُمْ فَلْيَبْدَأْ بِالْيُمْنَى، وَإِذَا نَزَعَ فَلْيَبْدأْ بِالشِّمَالِ، لِتَكُنْ اليُمْنَى أَوَّلَهُمَا تُنْعَلُ وَآخِرُهُمَا تُنْزَعُ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Берәрегез аяк киемен кисә, уңнан башласын, ә инде салганда сулдан башласын, хәтта кигәндә уң аяк беренче киеп ахырдан салсын өчен».***

عن أنس رضي الله عنه أنَّ رسول الله ﷺ أُتِيَ بِلَبَنٍ قَدْ شِيبَ بماءٍ وَعَنْ يَمِينِهِ أَعْرَابِيٌّ وَعَنْ يَسَارِهِ أَبُو بَكْرٍ رضي الله عنه فَشَرِبَ ثُمَّ أَعْطَى الأَعْرابيَّ وقال: «الأيْمَنَ فالأيْمَنَ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әнәс ﷺ әйтте: «Бервакыт пәйгамбәребезгә ﷺ су белән кушылган сөт китерделәр, аның уң ягында бер сахра кешесе, ә сул ягында Әбү Бәкер ﷺ иде. Пәйгамбәребез ﷺ үзе эчте дә, аннан соң савытны бу сахра кешесенә бирде һәм: ***«Уң якта булучының өстенлекле хакы бар»,*** — диде».

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Уң яктан башлау, пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтенә бик тә игътибарлы булуны күрсәтә һәм ул Ислам әһелләренең горурлану билгесе булып тора. Шулай ук пәйгамбәребезчә уң тарафтан эшләргә ярату, шәйтанга каршы килүне аңлата, чөнки ул гамәлләрендә сул якны сайлый.

**Файдалар:**

**1)** Хөрмәтле вә ихтирамлы эшләрдә уң якны өстенрәк күю хәерле санала.

**2)** Өс киеме, аяк киеме кигәндә, биргәндә һәм алганда, ашаганда һәм эчкәндә, мисвәк кулланганда, тырнак кискәндә, мыек кыскартканда, чәч алганда, мәчеткә кергәндә, таһәрат алганда, бәдрәфтән чыкканда һ.б. уң як белән эшләү хәерле. Ә инде мәчеттән чыкканда, киемнәрне вә аяк киемнәрен салганда, бәдрәфкә кергәндә һәм истинҗа кылгандагы кебек гамәлләрдә сул як белән эшләү хәерле.

**3)** Мәҗлесләрдә утырганда башта уң як тарафка бирү хәерле.

## 🕮 Каберләрне зиярат кылу хакында

عن بُرَيْدَةَ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله صلى الله عليه وسلم: «كُنْتُ نَهَيْتُكُمْ عن زِيَارَةِ القُبُورِ فَزُوروها» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Бүрайдәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әүвәл мин сезне каберләрне зиярат итүдән тыйган идем, ләкин хәзер аларны зиярат итегез!».*** Тирмизидә килгән риваятьтә: ***«Хакыйкатьтә, ул сезгә ахирәтне искә төшерә»,*** — дип өстәлде.

عن عنه رضِيِ الله عنه قَالَ: كَانَ النبيُّ صلى الله عليه وسلم يُعَلِّمُهُمْ إذا خَرَجُوا إِلَى المَقَابِرِ أنْ يَقُولَ قَائِلُهُمْ: «السَّلَامُ عَلَيْكُمْ أهلَ الدِّيَارِ مِنَ المُؤْمِنِينَ وَالمُسلمينَ وَإِنَّا إِنْ شَاءَ اللهُ بِكُمْ للاَحِقون أَسْأَلُ الله لَنَا وَلَكُمُ العَافِيَةَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Бүрайдә ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ каберләргә килгәндә ошбу сүзләрне әйтергә кирәклеген аларга өйрәтте: ***«Сәлам сезгә монда ятучы мөэминнәр һәм мөселманнар! Дөреслектә, әгәр Аллаһ теләсә, без дә сезгә кушылырбыз, Аллаһтан безгә дә һәм сезгә дә иминлек сорыйм!».***

عن أَبي مَرْثَدٍ كَنَّازِ بْنِ الحُصَيْنِ رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ رسُولَ اللهِ صلى الله عليه و سلم يقولُ: «لاَ تُصَلُّوا إِلَى القُبُورِ وَلاَ تَجْلِسُوا عَلَيْهَا» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Мәрсәд Кәннәз бин әл-Хусайн ﵁ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Каберләргә карап намаз укымагыз һәм аларга утырмагыз!».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «لأَنْ يَجْلِسَ أَحَدُكُمْ عَلَى جَمْرَةٍ فَتُحْرِقَ ثِيَابَهُ فَتَخْلُصَ إِلَى جِلْدِهِ خَيْرٌ لَهُ مِنْ أَنْ يَجْلِسَ عَلَى قَبْرٍ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, сезнең өчен, киемне яндырып тиргә кадәр үтеп керә торган утлы күмергә утыру, кабергә утырудан хәерлерәк булыр!».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Каберләрне зиярат итү, пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтеннән. Ул үзе дә зиярат кылды һәм өммәтенә дә боерды. Хакыйкатьтә, гакылы тулы булган кеше каберлеккә барса, мәңгелек кайтасы урынын күреп һәм үзенең бу дөньяда вакытлыча гына тормыш иткәнен белеп, уйлана башлый. Шуңа да расүлебез ﷺ «каберлекләргә зиярат итү, ахирәтне искә төшерә», — дип бәянләде.

**Файдалар:**

**1)** Каберлекләрне зиярат кылу хәерле гамәл булып тора һәм кешегә ахирәтне искә төшерә.

**2)** Каберлеккә кергәндә, хәдистә бәян ителгәнчә сәлам бирү, сөннәт гамәл санала.

**3)** Каберләргә таба юнәлеп намаз укырга ярамый (хәрам).

**4)** Каберләргә утырырга ярамый.

## 🕮 Хәмернең хәрамлыгы хакында

•يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالأَنْصَابُ وَالأَزْلامُ رِجْسٌ مِنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ• المائدة: ٩٠

Мәгънәсе: ***«Ий, мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләр, отыш уеннары, сыннар (потлар), шулай ук багучылык вә күрәзәлек, һәммәсе дә шәйтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер. Бу нәҗес эшләрдән сакланыгыз! Шаять котылырсыз вә уңышка ирешерсез».***

عَنْ جَابِرٍ رضي الله عنه أن رَسُول اللَّهِ ﷺ قَالَ: «كُلُّ مُسْكِرٍ حَرَامٌ إِنَّ عَلَى اللَّهِ عَزَّ وَجَلَّ عَهْدًا لِمَنْ يَشْرَبُ الْمُسْكِرَ أَنْ يَسْقِيَهُ مِنْ طِينَةِ الْخَبَالِ». قَالُوا: يَا رَسُول اللَّهِ وَمَا طِينَةُ الْخَبَالِ؟ قَالَ: «عَرَقُ أَهْلِ النَّارِ أَوْ عُصَارَةُ أَهْلِ النَّارِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһтан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Барча исерткеч тә — хәрам, һәм кем дә кем исерткеч эчә икән, Аллаһ тәгалә ул кешене “тыйнатуль-хабәәл”дән эчерер».*** Сорадылар: «Йә расүл Аллаһ! Нәрсә ул “тыйнатуль-хабәәл”?» — дип. Пәйгамбәребез ﷺ аларга җавап итеп: ***«Җәһәннәм әһелләренең тирләре яки алардан агып чыккан эреннәр һәм каннар»,*** — диде.

عَنْ طَارِق بْن سُوَيْدٍ رضي الله عنه أَنَّهُ سَأَلَ النَّبِىَّ ﷺ عَنِ الْخَمْرِ فَنَهَاه فَقَالَ: إِنَّمَا أَصْنَعُهَا لِلدَّوَاءِ؟، فَقَالَ: «إِنَّهُ لَيْسَ بِدَوَاءٍ وَلَكِنَّهُ دَاءٌ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Тарикъ бин Сүәйд ﵁ пәйгамбәребездән ﷺ хәмер турында сорагач, расүлебез ﷺ аны тыйды. Шуннан соң Тарикъ бин Сүәйд ﵁ : «Мин бит аны дәва өчен генә ясыйм?» — дигәч, пәйгамбәребез ﷺ: ***«Хакыйкатьтә, ул дәва түгел, ә авыру»,*** — диде.

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عُمَرَ رضي الله عنهما قال: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «مَنْ شَرِبَ الْخَمْرَ لَمْ يَقْبَلِ اللَّهُ لَهُ صَلاَةً أَرْبَعِينَ صَبَاحًا فَإِنْ تَابَ تَابَ اللَّهُ عَلَيْهِ فَإِنْ عَادَ لَمْ يَقْبَلِ اللَّهُ لَهُ صَلاَةً أَرْبَعِينَ صَبَاحًا فَإِنْ تَابَ تَابَ اللَّهُ عَلَيْهِ فَإِنْ عَادَ لَمْ يَقْبَلِ اللَّهُ لَهُ صَلاَةً أَرْبَعِينَ صَبَاحًا فَإِنْ تَابَ تَابَ اللَّهُ عَلَيْهِ فَإِنْ عَادَ الرَّابِعَةَ لَمْ يَقْبَلِ اللَّهُ لَهُ صَلاَةً أَرْبَعِينَ صَبَاحًا فَإِنْ تَابَ لَمْ يَتُبِ اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَقَاهُ مِنْ نَهْرِ الْخَبَالِ» [ أخرجه الترمذي، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хамер эчкән кешенең намазын Аллаһ тәгалә кырык көн кабул итми, әгәр дә ул тәүбә итсә, Аллаһ аның тәүбәсен кабул итә. Ул кеше икенче тапкыр хамер эчсә, Аллаһ аның намазын тагын кырык көн кабул итми, әгәр тәүбә итсә, тәүбәсен кабул итә. Шулай ук өченче тапкыр хамер эчсә, Аллаһ тәгалә аның намазын кырык көн кабул итми, әгәр тәүбә итсә, тәүбәсен кабул итә. Дүртенче тапкыр хамер эчсә, Аллаһ тәгалә аның намазын кырык көн кабул итми, ә инде тәүбә итсә, тәүбәсен дә кабул итми һәм ул кешене "әл-Хабәәл"[19] елгасыннан эчертә».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Хамер, барча явызлыкларның да анасы булып тора һәм аны эчү зур гөнаһларга керә. Аллаһ тәгалә Коръәндә һәм расүлебез ﷺ үзенең хәдисләрендә аның хәрамлыгы вә эчүчене каты җәза көткәнлеге хакында бәян иттеләр.

**Файдалар:**

**1)** Хамер эчү хәрам.

**2)** Хамер эчүчене каты газап көтә.

**3)** Хамер ул дәва түгел, ә киресенчә авыру гына.

## 🕮 Бәхәсләрдән читләшү хакында

عَنْ أَبِي أُمَامَةَ ﵁ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «مَا ضَلَّ قَوْمٌ بَعْدَ هُدًى كَانُوا عَلَيْهِ إِلاَّ أُوتُوا الْجَدَلَ». ثُمَّ تَلاَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم هَذِهِ الآيَةَ: •مَا ضَرَبُوهُ لَكَ إِلاَّ جَدَلاً بَلْ هُمْ قَوْمٌ خَصِمُونَ• [الزخرف: ٥٨] [أخرجه الترمذي، حديث حسن]

19 Җәһәннәм әһелләреннән агып чыккан эрен, кан һәм башка пычраклар

Мәгънәсе: Әбү Үмәмәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Һидәятьтә булганнан соң бер кавем дә адашмады, иллә мәгәр бәхәсләшүчеләр генә».*** Шуннан соң ул ошбу аятьләрне укыды: **«Алар бу чагыштыруны сиңа мәгәр синең илә бәхәсләшү өчен генә китерделәр. Алар бәхәсләшүче кавемдер».**

عَنْ عَائِشَةَ رضى الله عنها قَالَتْ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «إِنَّ أَبْغَضَ الرِّجَالِ إِلَى اللَّهِ الأَلَدُّ الْخَصِمُ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһәдән: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә каршында иң нәфрәтле кешеләр — бәхәсләшергә яратучылардыр».***

عن أَبي أُمَامَةَ الباهِلِيِّ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله صلى الله عليه وسلم: «أنَا زَعِيمٌ ببَيتٍ في ربَضِ الجَنَّةِ لِمَنْ تَرَكَ المِرَاءَ وَإِنْ كَانَ مُحِقًّا، وَببَيْتٍ في وَسَطِ الجَنَّةِ لِمَنْ تَرَكَ الكَذِبَ وَإِنْ كَانَ مَازِحاً، وَبِبَيْتٍ في أعلَى الجَنَّةِ لِمَنْ حَسُنَ خُلُقُهُ» [ أخرجه أَبُو داود، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Үмәмәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бәхәсләшүче хәтта хаклы булса да бәхәстән баш тартканы өчен, мин аны Җәннәт тирәсендәге йорт белән ышандырам. Шаяртып кына да ялган сөйләмәүчене, Җәннәтнең уртасындагы йорт белән ышандырам. Күркәм әхлаклы кешене, Җәннәтнең югары өлкәсендәге йорт белән ышандырам».***

عن جابر رضي الله عنه أَنَّ رسولَ الله ﷺ قَالَ: «إنَّ مِنْ أَحَبِّكُمْ إليَّ وَأقْرَبِكُمْ مِنِّي مَجْلِساً يَوْمَ القِيَامَةِ أَحَاسِنَكُم أَخْلاَقاً وَإنَّ أَبْغَضَكُمْ إلَيَّ وَأَبْعَدَكُمْ مِنِّي يَوْمَ القِيَامَةِ الثَّرْثَارُونَ وَالمُتَشَدِّقُونَ وَالمُتَفَيْهِقُونَ» قالوا: يَا رسول الله قَدْ عَلِمْنَا الثَّرْثَارُونَ وَالمُتَشَدِّقُونَ فمَا المُتَفَيْهِقُونَ؟ قَالَ: «المُتَكَبِّرُونَ» [ أخرحه الترمذي، صحيح ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһтан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, минем өчен иң сөеклеләр һәм Кыямәт көнендә миңа бөтенесеннән дә якынрак булучылар — сезнең иң күркәм әхлаклыларыгыз. Ә минем өчен иң нәфрәтлеләр һәм Кыямәт көнендә миннән иң еракта булучылар — күп сөйләүчеләр, үзенең оста теллелеген күрсәтергә тырышып мактанучылар, саф-***

***сата сатучылар».*** Әйттеләр: «Әй Аллаһның Илчесе, без «күп сөйләүчеләрнең», «мактанчыкларның» кемнәр икәнен беләбез, ләкин «сафсата сатучылар» кемнәр алар?» — диделәр. Ул: ***«Тәкәбберләр»,*** — диде.

***«Күп сөйләүчеләр»*** — ул гадәти булмаган рәвештә күп сөйләүче. ***«Мактанчыклар»*** — үзенең оста теллелеген күрсәтергә тырышып, сөйләме белән кешеләрне ялкытучы. ***«Сафсата сатучылар»*** — авызын сөйләме белән тутыручы, арттырып сөйли һәм тәкәбберлегеннән, олылануга омтылуыннан һәм башкалардан үзенең өстенлеген күрсәтү теләгеннән аз кулланылучы сүзләрне куллана.

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Батыл вә ялган белән бәхәсләшү — мөселманнар арасына фетнә, низаг сала торган һәм вакытны бушка уздыра торган телнең афәтләреннән. Шуңа да расүлебез ﷺ бәхәсләшүдән кисәтте һәм мондый гамәлдән читләшкән кешене зур савап көткәнлеген, вә Кыяматтә аның белән янәшә булуын вәгъдә итте.

**Файдалар:**

**1)** Бәхәсләшүдән читләшергә кирәк.

**2)** Бәхәсләшү мөселманнар арасында таркаулыкка китерә.

**3)** Кыямәт көнендә күп сөйләүчеләр, сүзләре белән мактанучылар һәм сафсата сатучылар, пәйгамбәребездән читләшкән булырлар һәм аның нәфрәтенә ирешерләр.

## 🕮 Ялган сөйләүнең хәрамлыгы һәм аннан саклану хакында

•إِنَّمَا يَفْتَرِي الْكَذِبَ الَّذِينَ لا يُؤْمِنُونَ بِآيَاتِ اللَّهِ وَأُولَئِكَ هُمُ الْكَاذِبُونَ• النحل١٠٥

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, ялганны Аллаһ тәгаләнең аятьләренә иман китермәгән кешеләр уйлап чыгаралар, һәм алар — ялганчылардыр».**

عن ابن مسعود رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسولُ اللهِ ﷺ : «إِنَّ الصِّدْقَ يَهْدِي إِلَى البِرِّ وإِنَّ البِرَّ يَهْدِي إِلَى الجَنَّةِ وإِنَّ الرَّجُلَ لَيَصْدُقُ حَتَّى يُكْتَبَ عِنْدَ اللهِ صِدِّيقاً وَإِنَّ الكَذِبَ يَهْدِي إِلَى الفُجُورِ وإِنَّ الفُجُورَ يَهْدِي إِلَى النَّارِ وإِنَّ الرَّجُلَ لَيَكْذِبُ حَتَّى يُكْتَبَ عِنْدَ اللهِ كَذَّاباً» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Ибен Мәсгудтан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, туры сүз — изгелеккә илтә, ә изгелек — Җәннәткә китерә, һәм дөреслектә, әгәр дә кеше һәрвакыт дөресен сөйләсә, ул Аллаһның хозурында иң туры сүзне сөйләүче кеше булып языла. Дөреслектә, ялган — гөнаһка илтә, ә гөнаһ — Җәһәннәмгә китерә, һәм дөреслектә, әгәр дә кеше һәрвакыт ялганласа, Аллаһның хозурында ул иң ялганчы кеше булып языла».***

عن عبدِ الله بن عمرو بن العاص رضي الله عنهما أَنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «أَرْبَعٌ مَنْ كُنَّ فِيهِ كَانَ مُنَافِقاً خَالِصاً وَمَنْ كَانَتْ فِيهِ خَصْلَةٌ مِنْهُنَّ كَانَتْ فِيهِ خَصْلَةٌ مِنَ النِّفَاقِ حَتَّى يَدَعَهَا: إِذَا اؤْتُمِنَ خَانَ وَإِذَا حَدَّثَ كَذَبَ وَإِذَا عَاهَدَ غَدَرَ وَإِذَا خَاصَمَ فَجَرَ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﵄: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дүрт төрле сыйфатка ия булган кеше чын монафикъ була, ә ул сыйфатларның берсе булганы, аннан котылганга кадәр, нифакъ (икейөзлелек) сыйфаты белән билгеле була: Әманәткә хыянәт итә, сөйләгәндә ялганлый, килешүне боза һәм кем белән булса да низаглашканда хаклыктан читләшә (ялган антлар һәм ялган гаепләүләр кыла)».***

عن سَمُرَةَ بنِ جُنْدُبٍ رضي الله عنه قَالَ: كَانَ رَسُولُ اللهِ صلى الله عليه وسلم مِمَّا يُكْثِرُ أَنْ يَقُولَ لأَصْحَابِهِ: «هَلْ رَأَى أَحَدٌ مِنْكُمْ مِنْ رُؤْيَا؟» فَيَقُصُّ عَلَيْهِ مَنْ شَاءَ اللهُ أَنْ يَقُصَّ وإِنَّهُ قَالَ لَنا ذات غَدَاةٍ: «إِنَّهُ أَتَانِيَ اللَّيْلَةَ آتِيَانِ وإِنَّهُمَا قَالا لِي: انْطَلِقْ وإِنِّي انْطَلَقْتُ مَعَهُمَا ... (حتى قال) فَأَتَيْنَا عَلَى رَجُلٍ مُسْتَلْقٍ لِقَفَاهُ وَإِذَا آخَرُ قَائِمٌ عَلَيْهِ بِكَلُّوبٍ مِنْ حَديدٍ وَإِذَا هُوَ يَأْتِي أَحَدَ شِقَّيْ وَجْهِهِ فَيُشَرْشِرُ شِدْقَهُ إِلَى قَفَاهُ ومِنْخَرَهُ

إِلَى قَفَاهُ وعَيْنَهُ إِلَى قَفَاهُ ثُمَّ يَتَحَوَّلُ إِلَى الجانب الآخَرِ فَيَفْعَلُ بِهِ مِثْلَ مَا فَعَلَ بالجَانِبِ الأَوَّلِ فَمَا يَفْرَغُ مِنْ ذَلِكَ الجانبِ حَتَّى يَصِحَّ ذَلِكَ الجانبُ كما كَانَ ثُمَّ يَعُودُ عَلَيْهِ فَيَفْعَلُ مِثْلَ مَا فَعَلَ فِي المرَّةِ الأُوْلَى» قَالَ: «قُلْتُ سُبْحَانَ اللهِ! مَا هذانِ؟ ... قالا: فإنَّهُ الرَّجُلُ يَغْدُو مِنْ بَيْتِهِ فَيَكْذِبُ الكِذْبَةَ تَبْلُغُ الآفاقَ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Сәмура бин Җүндүб ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ сахәбәләреннән еш кына: ***«Кайсыгыз булса да берәр төш күрдеме?»,*** — дип сорый иде, һәм аңа кем дә булса, Аллаһ теләгәнне, үзенең төшеннән сөйли иде. Ә бервакыт иртән ул аларга әйтте: «Дөреслектә, бүген төнлә минем яныма икәү килеп: «Киттек», — диделәр. Мин алар белән киттем ... без чалкан ятучы кеше янына килдек, аның өстендә тимер ыргак тоткан башка берәү тора иде, ул ыргакны чалкан ятучының авызының читенә бер яктан кертеп баш артына кадәр өзгәли иде, шулай ук борынына кертеп баш артына кадәр өзгәли иде һәм күзенә кертеп баш артына кадәр өзгәли иде, аннан соң (битнең) икенче ягына күчә иде, һәм беренчесе белән кылганны кыла иде, һәм бер ягын (өзгәләп) бетергәнче үк, икенче ягы (яңадан) элеккеге кебек үк була иде, ә аннан соң ул аңа тагын кайтып, шулай ук эшли иде». Пәйгамбәребез ﷺ дәвам итеп әйтте: ***«Мин әйттем: «Сүбхәналлаһ! Бу икәү кемнәр?» ... юлдашларым әйттеләр: Ул кеше иртән үк йортыннан чыгу белән, тирә-якка ялган тарата иде ... ».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Ялганлау монафикълар сыйфаты һәм ул расүлебезгә иң нәфрәтле сыйфат иде. Ялганчылык — кешене гөнаһка, ә гөнаһ — Җәһәннәм утына илтә һәм ул кеше Аллаһ хозурында үтә ялганчы дип языла. Шулай ук пәйгамбәребез ﷺ кешеләр арасында ялган таратучыны бик каты җәза көткәнлеге хакында кисәтеп узды.

**Файдалар:**

**1)** Ялганчылык, ул монафикълар сыйфаты.

**2)** Ялганчылык гөнаһка илтә.

3) Ялганчылык Җәһәннәмгә керүнең сәбәбе.
4) Ялганчыларны Кыямәт көнендә бик каты газап көтә.

## 🕮 Күркәм холык хакында

•وَإِنَّكَ لَعَلَى خُلُقٍ عَظِيمٍ• القلم: ٤

Мәгънәсе: **«Тәхкыйк, син күркәм холыктасың».**

•لَقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ• الأحزاب: ٢١

Мәгънәсе: **«Тәхкыйк, Аллаһ расүлендә сезгә күркәм мисал вә үрнәк бар».**

عن أنس ﵁ قال: «كَانَ رسولُ الله ﷺ أحْسَنَ النَّاس خُلُقاً» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әнәс ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ кешеләрнең иң күркәм холыклысы иде».***

عن عبد الله بن عمرو بنِ العاص رضي الله عنهما قَالَ: لَمْ يكن رسولُ الله ﷺ فَاحِشاً وَلاَ مُتَفَحِّشاً وكان يَقُولُ: «إنَّ مِنْ خِيَارِكُمْ أحْسَنَكُمْ أخْلاَقاً» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гас ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ беркайчан да әдәпсез дә, оятсыз да булмады һәм ул: ***«Дөреслектә, сезнең иң яхшыларыгыз — иң күркәм әхлаклыларыгыз»,*** — дип әйтә иде».

عن أَبي الدرداءِ رضي الله عنه أن النبي ﷺ قَالَ: «مَا شَيْءٌ أَثْقَلُ فِى مِيزَانِ الْمُؤْمِنِ يَوْمَ الْقِيَامَةِ مِنْ خُلُقٍ حَسَنٍ وَإِنَّ اللَّهَ لَيَبْغَضُ الْفَاحِشَ الْبَذِىءَ» [ أخرجه الترمذي، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Дәрдәдән ﵁ риваять ителүенчә: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кыямәт көнендә мөэминнәрнең үлчәүләрендә күркәм әхлактан да авыррак бернәрсә дә булмас. Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә әдәпсез вә начар сүзләрне сөйләүчеләргә нәфрәтле».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: سُئِلَ رسولُ الله ﷺ عَنْ أكثرِ مَا يُدْخِلُ النَّاسَ الْجَنَّةَ قَالَ: «تَقْوَى اللهِ وَحُسنُ الْخُلُقِ»، وَسُئِلَ عَنْ أكْثَرِ مَا يُدْخِلُ النَّاسَ النَّارَ فَقَالَ: «الفَمُ وَالفَرْجُ» [ أخرجه الترمذي، وقال: حديث حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайра ؓ әйтте: «Пәйгамбәребездән ﷺ, кешеләргә Җәннәткә керергә күбрәк нәрсә ярдәм итүе турында сорадылар, ул: ***«Тәкъвалык һәм күркәм холык»,*** — диде. Аннан соң аннан, кешеләрне Җәһәннәмгә күбрәк нәрсә илтүе турында сорадылар, ул: ***«Авыз һәм җенси әгъза»,*** — диде».

عن عائشة رضي الله عنها قالت: سَمِعْتُ رسولَ الله ﷺ يقول: «إنَّ المُؤْمِنَ لَيُدْرِكُ بحُسْنِ خُلُقِهِ دَرَجَةَ الصَّائِمِ القَائِمِ» [ أخرجه أبُو داود، صحيح ]

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Дөреслектә, күркәм холык — мөэминне ураза тотучылар һәм намаз укучылар дәрәҗәсенә ирештерә».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Яхшы сүз, матур мөгамәлә, кешеләргә сабыр итү һәм аларга ярдәм күрсәтү кебек күркәм әхлаклар Исламда бик зур урын алып тора. Пәйгамбәребез ﷺ иң күркәм холыклы кеше иде һәм мөселманнарны да ошбу сыйфатка өндәп, ул сыйфатның Аллаһка якынайта торган иң хәерле гамәлләр икәнен бәян итеп узды.

**Файдалар:**

**1)** Пәйгамбәребез ﷺ иң күркәм холыклы кеше иде.

**2)** Кыямәт көнендә мөселманнарның мизанында күркәм холык иң авыры булып килер.

**3)** Күркәм холык — Җәннәткә керүгә сәбәп.

## Оялчанлык хакында

عنِ ابن عمر رضي الله عنهما: أنَّ رسول الله ﷺ مَرَّ عَلَى رَجُلٍ مِنَ الأنْصَار وَهُوَ يَعِظُ أخَاهُ في الحَيَاءِ فَقَالَ رسولُ اللهِ صلى الله عليه وسلم: «دَعْهُ فَإنَّ الْحَيَاءَ مِنَ الإيمَانِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәр ﵁ әйтте: «Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ туганын оялчанлык өчен шелтәләп торучы әнсарларның берсе яныннан үтеп барганда, аңа: ***«Калдыр аны, чөнки, дөреслектә, оялчанлык — иманнан!»,*** — диде».

عن عمرانِ بنِ حصين رضي الله عنهما قَالَ: قَالَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «الْحَيَاءُ لاَ يَأتِي إلاَّ بِخَيْرٍ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Гыймран бин Хусайннән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Оялчанлык — игелек кенә китерә».***

عن أَبي سعيدٍ الخدري رضي الله عنه قَالَ: «كَانَ رسول الله صلى الله عليه وسلم أشَدَّ حَيَاءً مِنَ العَذْرَاءِ في خِدْرِهَا» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд әл-Худрий ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ пәрдә артында утыручы гыйффәтле кыздан да оялчанрак иде».***

عن أبي مسعودٍ الأنصاري رضي الله عنه قال: قال النبيّ ﷺ: «إنَّ مِمَّا أَدْرَكَ النَّاسُ مِنْ كَلامِ النُّبُوَّةِ الأولَى: إذَا لَمْ تَسْتَحِ فَاصْنَعْ مَا شِئْتَ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Мәсгуд әл-Әнсарийдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, кешеләргә әүвәлге пәйгамбәрләрдән ошбу сүзләр иреште: «Әгәр оялмасаң, нәрсә телисең шуны эшлә!».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Оялчанлык — иманнан һәм ул кешене әдәпсез сүзләрдән вә гамәлләрдән читләштереп, изгелеккә этәрә. Расүлебез ﷺ бик тә оялчан иде һәм шулай ук, оялчанлык әүвәлге пәйгамбәрләрдән мирас булып калды.

**Файдалар:**

**1)** Оялчанлык — иманнан.

**2)** Оялчанлык игелек кенә китерә.

**3)** Пәйгамбәребез ﷺ иң оялчан кеше иде.

**4)** Оялчанлык кешегә генә хас сыйфат.

## 🕮 Күп көлүдән тыелу хакында

عن عائشة رضي الله عنها قالت: «مَا رَأَيْتُ رسول الله صلى الله عليه وسلم مُسْتَجْمِعاً قَطُّ ضَاحِكاً حَتَّى تُرَى مِنهُ لَهَوَاتُهُ، إِنَّمَا كَانَ يَتَبَسَّمُ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: ***«Мин пәйгамбәребезнең ﷺ беркайчан да кече теле күренерлек итеп, бөтен авызын ачып көлгәнен күрмәдем, ул бары тик елмая гына иде».***

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «لاَ تُكْثِرُوا الضَّحِكَ فَإِنَّ كَثْرَةَ الضَّحِكِ تُمِيتُ الْقَلْبَ» [ أخرجه ابن ماجه، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Күп көлмәгез, хакыйкатьтә, күп көлү йөрәкне үтерә».***

عَنْ أَبِى ذَرٍّ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «تَبَسُّمُكَ فِى وَجْهِ أَخِيكَ لَكَ صَدَقَةٌ وَأَمْرُكَ بِالْمَعْرُوفِ وَنَهْيُكَ عَنِ الْمُنْكَرِ صَدَقَةٌ وَإِرْشَادُكَ الرَّجُلَ فِى أَرْضِ الضَّلاَلِ لَكَ صَدَقَةٌ وَبَصَرُكَ لِلرَّجُلِ الرَّدِىءِ الْبَصَرِ لَكَ صَدَقَةٌ وَإِمَاطَتُكَ الْحَجَرَ وَالشَّوْكَةَ وَالْعَظْمَ عَنِ الطَّرِيقِ لَكَ صَدَقَةٌ وَإِفْرَاغُكَ مِنْ دَلْوِكَ فِى دَلْوِ أَخِيكَ لَكَ صَدَقَةٌ» [ أخرجه الترمذي، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Зәррдән ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөселман кардашеңә елмаеп карау — садака, яхшылыкка өндәп яманлыктан тыю — садака, адашкан кешегә юл күрсәтүең — садака, сукыр яки начар күргән кешегә ярдәм итүең — садака, юлдан таш яки чәнечке яки сөяк (яки башка комачаулый торган нәрсәне) алып куюың — садака, үзеңнең чиләгеңнән мөселман кардәшеңнең чиләгенә салып ярдәм итүең — садака».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Күп көлү пәйгамбәребезнең ﷺ сыйфатыннан түгел иде һәм ул бу гамәлдән өммәтебезне кисәтте вә йөрәкне үтерә, дип бәян итте.

**Файдалар:**

**1)** Күп көлүдән тыелырга кирәк.

**2)** Күп көлү йөрәкне үтерүгә сәбәп.

**3)** Күп көлү пәйгамбәребезнең ﷺ сыйфаты түгел.

## 🕮 Рәхимлек хакында

•لَقَدْ جَاءَكُمْ رَسُولٌ مِنْ أَنْفُسِكُمْ عَزِيزٌ عَلَيْهِ مَا عَنِتُّمْ حَرِيصٌ عَلَيْكُمْ بِالْمُؤْمِنِينَ رَءُوفٌ رَحِيمٌ• التوبة: ١٢٨

Мәгънәсе: **«Тәхкыйк, сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, сезгә авыр булган нәрсә аңа да авырлык китерәдер, ул сезнең иманга килүегез өчен бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьле һәм рәхимле».**

•مُحَمَّدٌ رَسُولُ اللَّهِ وَالَّذِينَ مَعَهُ أَشِدَّاءُ عَلَى الْكُفَّارِ رُحَمَاءُ بَيْنَهُمْ• الفتح: ٢٩

Мәгънәсе: **«Мөхәммәд — Аллаһның расүле, ул расүл илә бергә булганнар кәферләргә катылар, ә үз араларында бер-берсенә рәхимлеләр».**

عَنْ جَرِيرِ بْنِ عَبْدِ اللَّهِ ﵁ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «لاَ يَرْحَمُ اللَّهُ مَنْ لاَ يَرْحَمُ النَّاسَ» [ البخاري ]

Мәгънәсе: Җәрир бин Габдуллаһтан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем кешеләргә рәхимле булмаса, Аллаһ тәгалә аңа рәхимле булмас».***

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ أَبَا الْقَاسِمِ صلى الله عليه وسلم يَقُولُ: «لاَ تُنْزَعُ الرَّحْمَةُ إِلاَّ مِنْ شَقِيٍّ» [ أخرجه الترمذي، تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Явыз кеше генә рәхимлелектән вә шәфкатьлелектән мәхрүм ителер».***

عن أُسَامَةَ بِن زيدٍ رضي الله عنهما قَالَ: أَرْسَلَتْ بِنْتُ النَّبيِّ ﷺ إنَّ ابْنِي قد احْتُضِرَ فَاشْهَدنَا، فَأَرْسَل يُقْرِىءُ السَّلامَ ويقُولُ: «إنَّ لله مَا أَخَذَ وَلَهُ مَا أعطى وَكُلُّ شَيءٍ عِندَهُ بِأجَلٍ مُسَمَّى فلتَصْبِرْ وَلْتَحْتَسِبْ» فَأرسَلَتْ إِلَيْهِ تُقْسِمُ عَلَيهِ لَيَأتِيَنَّهَا فقامَ وَمَعَهُ

سَعْدُ بْنُ عُبَادَةَ وَمُعَاذُ بْنُ جَبَلٍ وَأُبَيُّ بْنُ كَعْبٍ وَزَيْدُ بْنُ ثَابِتٍ وَرِجَالٌ رضي الله عنهم فَرُفِعَ إِلَى رَسُولِ الله ﷺ الصَّبِيُّ فَأَقْعَدَهُ فِي حِجْرِهِ وَنَفْسُهُ تَقَعْقَعُ فَفَاضَتْ عَيْنَاهُ ﷺ فَقَالَ سَعْدٌ: يَا رسولَ الله مَا هَذَا؟ فَقالَ: «هذِهِ رَحمَةٌ جَعَلَهَا الله تَعَالَى فِي قُلُوبِ مَنْ شَاءَ مِنْ عِبَادِهِ وَإِنَّما يَرْحَمُ الله مِنْ عِبادِهِ الرُّحَماءَ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Үсәмә бин Зәйд ﷺ әйтте: «Бервакыт пәйгамбәребезнең ﷺ кызы улының үлем хәлендә булуын хәбәр итү өчен һәм пәйгамбәребезне ﷺ үз янына чакырып бер кешене җибәрде. Пәйгамбәребез ﷺ бу кешегә, аларга сәлам юлларга һәм: ***«Дөреслектә, Аллаһ алган нәрсә дә, Ул биргән нәрсә дә Аллаһныкы, һәм бөтен нәрсә өчен Ул бер вакыт әҗәл билгеләде, шулай булгач ул сабыр итсен һәм Аллаһтан әҗер-савабын өмет итсен»,*** — дип әйтергә кушып, бу кешене кире җибәрде. Ләкин, бераздан соң ул аның артыннан янә чакыртып, аның килүен ялварып сорап кеше җибәрде, һәм шунда пәйгамбәребез ﷺ урыныннан торды, аның белән бергә Сәгъд бин Губәдә, Мүгаз бин Җәбәл, Үбәй бин Кәгъб, Зәйд бин Сәбит һәм кайбер башка кешеләр дә (ﷺ) тордылар. (Кызының өендә) пәйгамбәребезгә ﷺ баланы бирделәр, инде гырылдый башлаган баланы ул күкрәгенә кысты һәм күзләре яшь белән тулды. Сәгъд моны күреп: «Йә расүл Аллаһ, бу нәрсә?» — диде. Ул: ***«Бу — мәрхәмәтлек. Аллаһ аны Үзе теләгән колларының йөрәкләренә салган, хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә шәфкатьле бәндәләргә генә рәхимле була»,*** — диде».

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Ислам дине — рәхимлек динедер. Аллаһ тәгалә дә, пәйгамбәребез дә ﷺ мөселманнарга рәхимле, шулай ук мөселманнар да үзара рәхимлеләр. Рәхимлек сыйфаты — кешедә бик тә күркәм сыйфат, шуңа да Аллаһ тәгалә рәхимлеләргә карата рәхимле була дип пәйгамбәребез ﷺ хәдисләрендә бәян итте.

**Файдалар:**

**1)** Рәхимлелек — мөэминнәр сыйфаты.

**2)** Рәхимле булу — Аллаһның рәхмәтенә ирешүгә сәбәп.

**3)** Рәхимсезлек — кешенең явызлыгын күрсәтә.

## 🕮 Гайбәтнең хәрамлыгы хакында

•وَلا يَغْتَبْ بَعْضُكُمْ بَعْضًا أَيُحِبُّ أَحَدُكُمْ أَنْ يَأْكُلَ لَحْمَ أَخِيهِ مَيْتًا• الحجرات: ١٢

Мәгънәсе: **«Вә кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез, вә бәгъзегез бәгъзегезне гайбәт кылмасын! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме?».**

عن أَبي هريرة رضي الله عنه أنَّ رسُولَ الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «أَتَدْرُونَ مَا الْغِيبَةُ ؟» قالوا: اللهُ وَرَسُولُهُ أَعْلَمُ، قَالَ: «ذِكْرُكَ أَخَاكَ بما يَكْرَهُ» قِيلَ: أفَرَأيْتَ إنْ كَانَ في أخِي مَا أقُولُ؟ قَالَ: «إنْ كَانَ فِيهِ مَا تَقُولُ فقد اغْتَبْتَهُ وإنْ لَمْ يَكُنْ فِيهِ مَا تَقُولُ فَقَدْ بَهَتَّهُ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сез гайбәтнең нәрсә икәнлеген беләсезме?».*** Кешеләр әйттеләр: «Аллаһ һәм Аның илчесе моның турында яхшырак беләләр». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кардәшеңне, аңа ошамаслык итеп искә алуың».*** Аннан сорадылар: «Әгәр дә мин әйтә торган нәрсә кардәшемдә булса?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр син әйтә торган нәрсә анда булса, димәк, син аның турында гайбәт сөйлисең, ә әгәр син әйтә торган нәрсә анда булмаса, димәк, син аңа яла ягасың».***

عن أنس رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله صلى الله عليه وسلم: «لَمَّا عُرِجَ بي مَرَرْتُ بِقَومٍ لَهُمْ أظْفَارٌ مِنْ نُحَاسٍ يَخْمِشُونَ وُجُوهَهُمْ وَصُدُورَهُمْ فَقُلْتُ: مَنْ هؤُلاءِ يَا جِبريلُ؟ قَالَ: هؤُلاءِ الَّذِينَ يَأكُلُونَ لُحُومَ النَّاسِ وَيَقَعُونَ في أعْرَاضِهِمْ» [ أخرجه أَبُو داود، تحقيق الألباني: صحيح ]

Мәгънәсе: Әнәстән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мин күккә күтәрелгәч, үзләренең битләрен һәм күкрәкләрен тырный торган, бакыр тырнаклы кешеләр янынннан үтеп киттем һәм: «Кемнәр алар, йә Җибрил?» — дип сорадым.***

***Ул: «Бу — кешеләрнең итләрен ашаучылар һәм аларның намусларына тел тидерүчеләр», — диде».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه أنَّ رسُولَ الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «كُلُّ المُسْلِمِ عَلى المُسْلِمِ حَرَامٌ دَمُهُ وَعِرْضُهُ وَمَالُهُ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөселманга башка мөселманның каны, намусы һәм малы — хәрам!».***

عن أَبي الدرداء رضي الله عنه عن النبيِّ ﷺ قَالَ: «مَنْ رَدَّ عَنْ عِرْضِ أخيهِ رَدَّ الله عَنْ وَجْهِهِ النَّارَ يومَ القِيَامَةِ» [ أخرجه الترمذي، وقال: حديث حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Дәрдәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем кардәшенең намусын яклый, Аллаһ аны Кыямәт көнендә уттан саклый».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Гайбәт — зур гөнаһларга керә. Ул мөселманнар арасында фетнә вә дошманлык тудыра. Ләкин шуңа карамастан күп кешеләр моңа бик тә җиңел карыйлар һәм бер-берсен бу кабахәт гамәлдән кисәтмиләр һәм ошбу сәбәпле, ул — кешеләр арасында иң киң таралган гөнаһлардан. Гайбәтнең кабахәтлеген бәян итеп, Аллаһ тәгалә аны Коръәндә үле кардәшеңнең итен ашау белән чагыштырды.

**Файдалар:**

**1)** Гайбәт — хәрам һәм ул зур гөнаһларга керә.

**2)** Кешене үзе юкта, ул ошатмаган сүз белән искә алу — гайбәткә керә, хәтта ул сүздә хаклык булса да.

**3)** Гайбәт сүзләр тыңлау — хәрамга керә һәм кем ишетә икән, ул гайбәтчене туктатырга тиешле.

**4)** Гайбәтчеләрне кабердә дә, Кыямәттә дә җәза көтә.

## 🕮 Кешеләр арасын бозу нияте белән сүз йөртүнең хәрамлыгы хакында

عن حُذَيْفَةَ ﵁ قَالَ: قَالَ رسولُ الله ﷺ: «لا يَدْخُلُ الجَنَّةَ نَمَّامٌ» [ متفق عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Хүзәйфәдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Нәмиминче[20] Җәннәткә керми».***

عنِ ابن عباسٍ رضي الله عنهما: أنَّ رسولَ الله صلى الله عليه وسلم مرَّ بِقَبْرَيْنِ فَقَالَ: «إنَّهُمَا يُعَذَّبَانِ وَمَا يُعَذَّبَانِ في كَبيرٍ! بَلَى إنَّهُ كَبِيرٌ: أمَّا أحَدُهُمَا فَكَانَ يَمْشِي بِالنَّمِيمَةِ وأمَّا الآخَرُ فَكَانَ لاَ يَسْتَتِرُ مِنْ بَوْلِهِ» [ متفق عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ ике кабер янында үтеп барганда болай диде: ***«Дөреслектә, аларны газаплыйлар һәм зур гөнаһ өчен түгел, ләкин, хакыйкатьтә, ул зур гөнаһ: Аларның берсе кешеләр арасын бозып сүз йөрткән, ә икенчесе үз бәвеленнән сакланмаган».***

عن ابن مسعود رضي الله عنه أن النَّبيّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «ألاَ أُنَبِّئُكُمْ مَا العَضْهُ؟ هي النَّمِيمَةُ، القَالَةُ بَيْنَ النَّاسِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Ибен Мәсгудтан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сезгә «әл-‘адһ»ның нәрсә икәнен әйтимме? Ул — нәмимә, кешеләр арасында йөри торган сүзләр».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Нәмимә — зур гөнаһларга керә. Гайбәт кебек үк кешеләрне бер-берсенә дошманлаштыруга, туганнарның араларын өзүгә китерә торган иң зур вә иң кабахәт гамәлләрдән булган өчен, расүлебез ﷺ бу гамәлне кылучыларны бик тә каты газап көткәнлеге белән кисәтте.

**Файдалар:**

**1)** Кешеләр арасын бозу максаты белән сүз йөртү — хәрам эштер һәм ул зур гөнаһларга керә.

---

20 Кешеләр арасын бозу нияте белән ялган сөйләп, яла ягучы

**2)** Бу эш белән шөгыльләнүчеләрне бик тә каты җәза көтә.

**3)** Нәмимәчеләргә карата нәфрәтле булырга кирәк.

**4)** Кем дә кем нәмимәнең хәрам икәнлеген белә торып хәләл кылса, ул кеше Җәннәткә керми.

## 🕮 Ләгънәт кылудан саклану хакында

**Нәрсә ул ләгънәт?**

Ләгънәт — ул Аллаһ тәгаләнең рәхмәтеннән ташлауны, читләштерүне вә ераклаштыруны сорау. Мәсәлән, әгәр дә син «Йә Аллаһ! Бу кешегә ләгънәт яки ләгънәтең булсын» — дип әйтәсең икән, син ул кешене Аллаһ Үзенең рәхмәтеннән ташласын, читләштерсен — дигән мәгънәдә сораган буласың, Аллаһ сакласын мондый сүзләрдән!

عن ثابت بن الضَّحَّاك الأنصاريِّ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ الله صلى الله عليه وسلم: «مَنْ حَلَفَ عَلَى يَمِينٍ بِمِلَّةٍ غَيْرِ الإسْلاَمِ كاذِباً مُتَعَمِّداً فَهُوَ كَما قَالَ، وَمَنْ قَتَلَ نَفْسَهُ بِشَيءٍ عُذِّبَ بِهِ يَومَ القِيَامَةِ، وَلَيْسَ عَلَى رَجُلٍ نَذْرٌ فيما لا يَمْلِكُهُ، وَلَعْنُ المُؤْمِنِ كَقَتْلِهِ» [ متفق عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Сәбит бин әд-Даххәк әл-Әнсарийдан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем Исламнан башка дин белән ант итеп, юри ялган ант бирә икән, ул үзен ничек атаган булса шундый була[21]. Дөньяда кем үз-үзенә нәрсә белән кул салган булса[22], Кыямәт көнендә шул ук нәрсә белән газапланыр. Кешегә, үзенеке булмаган нәрсә белән нәзер әйтергә ярамый[23]. Мөэминне ләгънәт кылу — аны үтерүгә тиң».***

---

21 Мәсәлән: "Үаллаһи, әгәр дә мин шуны эшләмәсәм яһүд яки насара булыйм", яки "Ул шуны эшләмәсә – яһүд яки кәфер", – дип әйтү кебек. Аллаһ сакласын!

22 Пычакмы, агумы, баумы яки башка нәрсә

23 Мәсәлән: "Мин фәлән кешенең байлыгын садака итер бирергә нәзер итәм", – дигән кебек

عن أَبي هريرة رضي الله عنه أنَّ رسُولَ الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «لاَ يَنْبَغِي لِصِدِّيقٍ أنْ يَكُونَ لَعَّاناً» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﷺ риваять ителүенчә: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Тугры кеше — ләгънәтләүче булырга тиеш түгел!».***

عن أَبِي الدرداءِ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسُولُ الله صلى الله عليه وسلم: «لاَ يَكُونُ اللَّعَّانُونَ شُفَعَاءَ وَلاَ شُهَدَاءَ يَوْمَ القِيَامَةِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Дәрдәдән ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ләгънәт кылучылар Кыямәт көнендә шәфәгатьчеләр дә, шәһитлек итүчеләр дә булмаслар».***

Чөнки, кем бу дөньяда башкаларны ләгънәт кыла икән, ул фәсыйкъ кеше була, ә фәсыйкъның шәфәгате дә, шәһитлек бирүе дә кабул булмый, Аллаһу әгъләм.

عن ابن مسعود رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسُولُ الله صلى الله عليه وسلم: «لَيْسَ المُؤْمِنُ بالطَّعَّانِ وَلاَ اللَّعَّانِ وَلاَ الفَاحِشِ وَلاَ البَذِيِّ» [ أخرجه الترمذي، صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Мәсгудтан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин яманлаучы да, ләгънәт кылучы да, фәхеш эшләр вә әдәпсез сүзләр сөйләүче дә булмас».***

عن أَبِي الدرداء رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسُولُ الله صلى الله عليه وسلم: «إنَّ العَبْدَ إذا لَعَنَ شَيْئاً صعدَتِ اللَّعْنَةُ إلَى السَّماءِ فَتُغْلَقُ أبْوابُ السَّماءِ دُونَهَا ثُمَّ تَهْبطُ إلَى الأَرْضِ فَتُغْلَقُ أبوابُهَا دُونَها ثُمَّ تَأخُذُ يَميناً وَشِمالاً فَإذا لَمْ تَجدْ مَسَاغاً رَجَعَتْ إلَى الَّذِي لُعِنَ فإنْ كَانَ أهْلاً لِذلِكَ وإلاَّ رَجَعَتْ إلَى قَائِلِهَا» [ أخرجه أبُو داود، صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Дәрдәдән ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, Аллаһның колы нәрсәне дә булса ләгънәт кылса, бу ләгънәт күккә күтәрелә, ләкин күкнең капкалары аның алдында ябыла[24]. Аннан соң ул җиргә төшә, ләкин җирнең дә капкалары аның алдында ябыла, аннан соң бу ләгънәт уңга һәм сулга барып карый, башка бернинди дә юл тапмаган очракта, ләгънәт кылынган кешегә кайта, һәм әгәр ул моңа лаек булса — аңа барып***

24 Күкләрнең капкалары ләгънәтнең җирәнгеч вә кабахәт булуы сәбәпле ябыла, чөнки ул яхшы сүз вә изге гамәлләргә генә ачыла

***җитә, киресенчә булган очракта — ул әйтүчегә әйләнеп кайта».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Ләгънәт, ул Аллаһның рәхмәтеннән куылу, читләштерү вә ераклаштырудыр. Кемне дә булса тәгаенләп ләгънәтләү, бик куркыныч гамәл, чөнки әгәр дә ул кешегә ләгънәт тиешле түгел икән, бу вакытта ул ләгънәт әйткән кешенең үзенә кайта, Аллаһ сакласын. Бу мәсьәләгә күп кенә кешеләр җиңел карый, шуңа да бу гамәлнең бик тә хәтәр икәнлеген бер-беребезгә аңлатырга тиешлебез.

**Файдалар:**

**1)** Мөселманнар ләгънәт кылудан сакланырга тиешләр.

**2)** Әгәр дә ләгънәт хаксыз кешегә әйтелә икән, ул кире әйткән хуҗасына кайта.

**3)** Ләгънәт кылу — изгеләр вә тугры кешеләрнең сыйфаты түгел.

## 🕮 Җиһәднең фазыйләте

•يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا هَلْ أَدُلُّكُمْ عَلَى تِجَارَةٍ تُنْجِيكُمْ مِنْ عَذَابٍ أَلِيمٍ ۞ تُؤْمِنُونَ
بِاللهِ وَرَسُولِهِ وَتُجَاهِدُونَ فِي سَبِيلِ اللهِ بِأَمْوَالِكُمْ وَأَنْفُسِكُمْ ذَلِكُمْ خَيْرٌ لَكُمْ إِنْ
كُنْتُمْ تَعْلَمُونَ ۞ يَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَيُدْخِلْكُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الأَنْهَارُ
وَمَسَاكِنَ طَيِّبَةً فِي جَنَّاتِ عَدْنٍ ذَلِكَ الفَوْزُ العَظِيمُ• الصف: ١٠-١٢

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Сезгә, сезне каты газабтан коткара торган сәүдәне күрсәтимме? Аллаһка вә Аның расүленә иман китерегез һәм Аллаһ юлында, Ислам диненен куәтләр өчен, малыгыз, тәнегез вә җаныгыз белән кәферләр белән сугыш кылыгыз. Менә бу эш, сезнең өчен бик файдалыдыр, әгәр белсәгез! Аллаһ сезнең**

**гөнаһларыгызны ярлыкар һәм асларыннан елгалар ага торган Җәннәт бакчаларына, дәхи Гаден җәннәтләренең яхшы урыннарына кертер. Бу җәннәтләргә керү бик зур уңыштыр».**

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: سُئِلَ رسول الله ﷺ: أيُّ العَمل أفْضَلُ؟ قَالَ: «إِيمَانٌ بِاللهِ وَرَسُولِهِ» قيل: ثُمَّ مَاذا؟ قَالَ: «الجهادُ في سَبيلِ اللهِ» قِيلَ: ثُمَّ مَاذَا؟ قَال: «حَجٌّ مَبْرُورٌ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребездән ﷺ сорадылар: «Нинди гамәл иң хәерлесе?» Ул: ***«Аллаһка һәм Аның расүленә иман китерү»,*** — дип җавап бирде. «Ә аннан соң нәрсә?», — дип сорадылар. Ул: ***«Аллаһ юлында җиһәд кылу»,*** — дип җавап бирде. «Ә аннан соң нәрсә?», — дип тагын сорадылар. Ул: ***«Кабул булган хаҗ»,*** — диде».

عن أنس رضي الله عنه أنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «لَغَدْوَةٌ في سَبيلِ اللهِ أَوْ رَوْحَةٌ خَيْرٌ مِنَ الدُّنْيَا وَمَا فِيهَا» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әнәстән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, Аллаһ юлында иртән яки кичен чыгып җиһәд кылу, бу дөньядан һәм анда булган барлык нәрсәдән дә хәерлерәк!».***

عن عبد الرحمان بن جَبْرٍ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله ﷺ: «ما اغْبَرَّتْ قَدَمَا عَبْدٍ في سَبيلِ اللهِ فَتَمَسَّهُ النَّارُ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Габдуррахмән бин Җәбрдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ юлында аяклары тузанланган кешегә — Җәһәннәм уты кагылмас».***

عن أَبي هريرة ﷺ قَالَ: قيل: يَا رسولَ اللهِ مَا يَعْدِلُ الجهادَ في سَبيلِ اللهِ؟ قَالَ: «لاَ تَسْتَطِيعُونَهُ» فَأعَادُوا عَلَيْهِ مَرَّتَيْنِ أَوْ ثَلاثاً كُلُّ ذَلِكَ يَقُول: «لاَ تَسْتَطِيعُونَهُ» ثُمَّ قَالَ: «مَثَلُ المُجَاهِدِ فِي سَبيلِ اللهِ كَمَثَلِ الصَّائِمِ القَائِمِ القَانِتِ بِآياتِ الله لا يَفْتُرُ مِنْ صِيَامٍ وَلاَ صَلاَةٍ حَتَّى يَرْجِعَ المُجَاهِدُ في سَبيلِ اللهِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребездән ﷺ: «Әй расүл Аллаһ! Аллаһ юлында җиһәд кылуга нинди гамәл тиң булырга мөмкин?», — дип сорадылар. Ул: ***«Сез аны булдыра алмыйсыз!»,*** — диде. Аннан соң алар сорауларын ике яки өч мәртәбә кабатладылар һәм пәйгамбәребез ﷺ һәрберсендә:

***«Сез аны булдыра алмыйсыз!»,*** — дип җавап бирде, ә аннан соң: ***«Аллаһ юлында җиһәд кылучы мөҗәһиднең мисалы — ураза тотучы, намаз укучы һәм Аллаһның аятьләрен үтәп, Аллаһ юлында сугышучы мөҗәһид кире әйләнеп кайтканга кадәр уразасыннан да, намазыннан да туктамаучыга тиң».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Аллаһ юлында җиһәд кылу — иң хәерле гамәлләрдән санала. Чөнки, җиһәдтә бик зур авырлыклар вә мәшәкатьләр бар. Ул искиткеч сабырлыкка мохтаҗ, хәтта мөҗәһид Аллаһ юлында үзенең җанын да кызганмаска тиешле. Шулай ук җиһәд гамәле Ислам динен башкаларга җиткерүгә, кешеләрнең дингә керүенә сәбәп булуда һәм мөселманнарны кәферләрнең явызлыкларыннан саклауга бәйле. Әгәр дә Аллаһ юлында тузанланган аякларга гына да Җәһәннәм уты кагылмый икән, ә инде үзенең малын вә җанын бу юлда сарыф итүчене нинди савап көтә?!!!

**Файдалар:**

**1)** Аллаһ юлында җиһәд кылуның дәрәҗәсе бик зур.

**2)** Җиһәд кылу — иң хәерле гамәлләрдән.

## Мөҗәһидләрнең һәм шәһидләрнең әҗер-савабы хакында

•إِنَّ اللهَ اشْتَرَى مِنَ الْمُؤْمِنِينَ أَنْفُسَهُمْ وَأَمْوَالَهُمْ بِأَنَّ لَهُمُ الْجَنَّةَ يُقَاتِلُونَ فِي سَبِيلِ اللهِ
فَيَقْتُلُونَ وَيُقْتَلُونَ وَعْداً عَلَيْهِ حَقّاً فِي التَّوْرَاةِ وَالإِنْجِيلِ وَالْقُرْآنِ وَمَنْ أَوْفَى بِعَهْدِهِ
مِنَ اللهِ فَاسْتَبْشِرُوا بِبَيْعِكُمُ الَّذِي بَايَعْتُمْ بِهِ وَذَلِكَ هُوَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ• التوبة : ١١١

Мәгънәсе: **«Аллаһ тәгалә мөэминнәрдән Җәннәт бәрабәренә үзләрен вә малларын сатып алды. Алар**

**Аллаһ юлында сугышырлар, кәферләрне үтерерләр вә үзләре дә үлерләр. Аның Тәүратта, Инҗилдә вә Коръәндәге ошбу вәгъдәсе хак. Аллаһтан башка берәрсе биргән вәгъдәсен яхшырак үтиме әллә?! Кылган сәүдә килешүләрегезгә шатланыгыз! Әнә шулай малларыгызны вә җаннарыгызны биреп Аллаһтан Җәннәт алу сәүдәсе — олуг бәхеткә ирешү!».**

عَنِ الْمِقْدَام بْنِ مَعْدِي كَرِبَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «لِلشَّهِيدِ عِنْدَ اللَّهِ سِتُّ خِصَالٍ يُغْفَرُ لَهُ فِى أَوَّلِ دَفْعَةٍ وَيَرَى مَقْعَدَهُ مِنَ الْجَنَّةِ وَيُجَارُ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ وَيَأْمَنُ مِنَ الْفَزَعِ الأَكْبَرِ وَيُوضَعُ عَلَى رَأْسِهِ تَاجُ الْوَقَارِ الْيَاقُوتَةُ مِنْهَا خَيْرٌ مِنَ الدُّنْيَا وَمَا فِيهَا وَيُزَوَّجُ اثْنَتَيْنِ وَسَبْعِينَ زَوْجَةً مِنَ الْحُورِ الْعِينِ وَيُشَفَّعُ فِى سَبْعِينَ مِنْ أَقَارِبِهِ» [ أخرجه الترمذي، وقال: حديث صحيح غريب ]

Мәгънәсе: Әл-Микъдәм бин Мәгьдий Кәрибтән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Шәһидне Аллаһ хозурында алты табыш көтә: Иң беренче тамчы каны таму белән барча гөнаһлары да ярлыкана; Җәннәттәге урыны күрсәтелә; Кабер газабыннан котыла; Кыямәт көнендә имин була; Башына таҗ кидерелә, ул таҗның якуты бу дөньядан һәм дөньяда булган барча нәрсәдән дә хәерлерәк; Җитмеш ике хур кызына өйләндерелә һәм җитмеш туганына шәфәгать кыла».***

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: مَرَّ رَجُلٌ مِنْ أَصْحَابِ رسولِ الله صلى الله عليه وسلمِ بِشِعبٍ فِيهِ عُيَيْنَةٌ مِنْ مَاءٍ عَذْبَةٍ فَأعْجَبَتْهُ فَقَالَ: لَوِ اعْتَزَلْتُ النَّاسَ فَأقَمْتُ فِي هَذَا الشِّعْبِ وَلَنْ أفْعَلَ حَتَّى أسْتَأْذِنَ رسولَ اللهِ صلى الله عليه وسلم، فذَكَرَ ذَلِكَ لرسولِ الله صلى الله عليه وسلم فَقَالَ: «لاَ تَفعلْ! فَإنَّ مُقَامَ أَحَدِكُمْ فِي سَبيلِ اللهِ أفْضَلُ مِنْ صَلاَتِهِ فِي بَيْتِهِ سَبْعِينَ عَاماً، ألاَ تُحِبُّونَ أنْ يَغْفِرَ اللهُ لَكُمْ وَيُدْخِلَكُمُ الجَنَّةَ؟ اُغْزُوا فِي سَبيلِ الله، من قَاتَلَ فِي سَبِيلِ اللهِ فُوَاقَ نَاقَةٍ وَجَبَتْ لَهُ الجَنَّةُ» [ أخرجه الترمذي، وقال: حديث حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: «Бервакыт пәйгамбәребезнең ﷺ бер сахәбәсе бик тәмле сулы, кечкенә чишмәсе булган тарлавыктан[25] узды. Бу тарлавык аңа ошады һәм ул: «Кешеләрдән читләшеп бу куышта яшәсәм яхшы булыр иде, ләкин мин Аллаһның расүленнән рөхсәт сора-

25 Ике тау арасындагы тар аралык

ганчыга кадәр моны беркайчан да эшләмәм!» — дип әйтте. Ә аннан соң ул пәйгамбәребезгә ﷺ моның турында сөйләде һәм расүлебез ﷺ аңа: ***«Моны эшләмә, чөнки, дөреслектә, берегезнең Аллаһ юлында булуы, өендә җитмеш ел буена намаз укудан хәерлерәк! Аллаһ сезне ярлыкавын һәм Җәннәткә кертүен теләмисезме әллә? Аллаһ юлында сугышыгыз! Кем дә кем ике савым арасы кадәр үтә торган вакыт кына булса да Аллаһ юлында сугышса, аңа һичшиксез Җәннәт булыр!»,*** — диде».

عن أنس رضي الله عنه أنَّ النبيَّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَا أَحَدٌ يَدْخُلُ الجَنَّةَ يُحِبُّ أنْ يَرْجِعَ إِلَى الدُّنْيَا وَلَهُ مَا عَلَى الأرْضِ مِنْ شَيْءٍ إلاَّ الشَّهيدُ يَتَمَنَّى أنْ يَرْجِعَ إِلَى الدُّنْيَا فَيُقْتَلَ عَشْرَ مَرَّاتٍ، لِمَا يَرَى مِنَ الكَرَامَةِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әнәстән ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Җәннәткә кергәннәргә, хәтта җирдә булган барлык нәрсәне тәкъдим итсәләр дә, шәһидтән башка беркем дә дөньяга кире кайтырга теләмәс. Шәһид киткән кеше аны нинди дәрәҗә вә хөрмәт көткәнлеген күреп, дөньяга кире кайтып Аллаһ ризалыгы өчен тагын ун мәртәбә үтерелгән булуын теләр».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Аллаһ юлында сугышкан яки шәһид булып киткән кешене бик зур әҗер саваплар көтә. Аңа хөрмәт вә зур дәрәҗәләр булу сәбәпле һәм Аллаһ юлында сугышуның ләззәтен тойганлыктан, шәһид яңадан дөньяга кайтып Аллаһ ризалыгы өчен бик күп тапкырлар үләргә теләр. Башка хәдисләрдә бәян ителгәнчә, шәһиднең беренче тамчы каны таму белән, бурычтан башка барча гөнаһлары да кичерелер. Мондый хөрмәт, мондый әҗер-савап шәһидтән башка беркемгә дә бирелмәс.

**Файдалар:**

**1)** Аллаһ юлында җиһәд кылу, Җәннәткә керүнең иң зур сәбәпләреннән.

**2)** Шәһиднең әҗере бик зур, хәтта аның җаны да җиңел чыга.

**3)** Шәһиднең бурычтан башка, барча гөнаһлары да гафу ителә.

## Сахәбәләрнең җиһәд мәйданындагы хәле

عن أنس رضي الله عنه قَالَ: انْطَلَقَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم وَأَصْحَابُهُ حَتَّى سَبَقُوا الْمُشْرِكِينَ إِلَى بَدْرٍ وَجَاءَ الْمُشْرِكُونَ فَقَالَ رَسولُ اللهِ صلى الله عليه وسلم: «لاَ يَقْدمَنَّ أَحَدٌ مِنْكُمْ إِلَى شَيْءٍ حَتَّى أَكُونَ أَنَا دُونَهُ» فَدَنَا الْمُشْرِكُونَ فَقَالَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «قُومُوا إِلَى جَنَّةٍ عَرْضُهَا السَّماوَاتُ وَالأَرْضُ» قَالَ: يَقُولُ عُمَيْرُ بن الحُمَامِ الأَنْصَارِيُّ رضي الله عنه: يَا رسولَ اللهِ جَنَّةٌ عَرْضُهَا السَّمَاوَاتُ وَالأَرْضُ؟ قَالَ: «نَعَمْ» قَالَ: بَخٍ بَخٍ! فَقَالَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «مَا يَحْمِلُكَ عَلَى قَولِكَ بَخٍ بَخٍ؟» قَالَ: لاَ وَاللهِ يَا رَسُولَ اللهِ إِلاَّ رَجَاءَ أَنْ أَكُونَ مِنْ أَهْلِهَا قَالَ: «فَإِنَّكَ مِنْ أَهْلِهَا» فَأَخْرَجَ تَمَرَاتٍ مِنْ قَرَنِهِ فَجَعَلَ يَأْكُلُ مِنْهُنَّ ثُمَّ قَالَ: لَئِنْ أَنَا حَيِيتُ حَتَّى آكُلَ تَمَرَاتِي هَذِهِ إِنَّهَا لَحَيَاةٌ طَوِيلَةٌ فَرَمَى بِمَا كَانَ مَعَهُ مِنَ التَّمْرِ ثُمَّ قَاتَلَهُمْ حَتَّى قُتِلَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әнәс ؓ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ һәм сахәбәләр юлга чыктылар һәм Бәдергә мөшрикләрдән алдарак килеп җиттеләр, ә мөшрикләр күренгәч, пәйгамбәребез ﷺ: ***«Миннән башка берегез дә бернәрсә дә эшләмәсен!»,*** — дип әйтте. Мөшрикләр якынлашкач, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Киңлеге күкләр һәм җир шикелле булган Җәннәткә ашыгыгыз!».*** Әнәс ؓ әйтте: «Гомәйр бин әл-Хүмәм әл-Әнсарий ؓ сорады: «Йә расүл Аллаһ! Җәннәт киңлеге күкләр һәм җир шикеллемени?!». Пәйгамбәребез ﷺ : ***«Әйе»,*** — диде. Ә Гомәйр: «Әйбәт, әйбәт!» — дип кычкырып җибәрде. Пәйгамбәребез ﷺ аннан: ***«Ни өчен син: «Әйбәт, әйбәт!», — дип әйтәсең?»,*** — дип сорады. Гомәйр: «Аллаһ белән ант итәм! Йә Аллаһның расүле! Мин аның әһелләренең берсе булырга өметләнгәнгә генә!» — дип җавап бирде. Моңа пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, син аның әһелләреннән!».*** Шунда Гомәйр

ук савытыннан хөрмәләр алды да, аларны ашарга тотынды, ләкин: «Дөреслектә, мин хөрмәләремне ашарга өлгерерлек кадәр яшәсәм, гомерем артык озын булыр бит», — диде. Үзенең булган хөрмәләрен ыргытты да, яуга ыргылды һәм һәлак булганчы сугышты».

**Файдалар:**

**1)** Сахәбәләрнең иманнарының көчлелеге вә шәһидлеккә омтылулары чиксез булган.

**2)** Алар кыю һәм батыр булганнар.

**3)** Изгелектә бер-берсе белән ярышканнар.

## Төчкерү әдәпләреннән

عن أَبي هريرةَ رضِي الله عنه أنَّ النبيَّ ﷺ قَالَ: «إِنَّ الله يُحِبُّ العُطَاسَ وَيَكْرَهُ التَّثَاؤُبَ فَإِذَا عَطِسَ أَحَدُكُمْ وَحَمِدَ الله تَعَالى كَانَ حَقًّا عَلِى كُلِّ مُسْلِمِ سَمِعَهُ أَنْ يَقُولَ لَهُ: يَرْحَمُكَ الله وَأَمَّا التَّثَاؤُبُ فَإِنَّمَا هُوَ مِنَ الشَّيْطَانِ فَإِذَا تَثَاءبَ أَحَدُكُمْ فَلْيَرُدَّهُ مَا اسْتَطَاعَ فَإِنَّ أَحَدَكُمْ إِذَا تَثَاءبَ ضَحِكَ مِنْهُ الشَّيْطَانُ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, Аллаһ төчкерүне ярата һәм иснәүне яратмый. Әгәр дә берәрегез төчкерсә һәм Аллаһ тәгаләгә хәмд-сәнә әйтсә, моны ишеткән һәр мөселман төчкерүчегә: «Сине Аллаһ ярлыкасын!» /ярхәмүкАллаһ!/ — дип әйтергә тиеш. Иснәүгә килгәндә, дөреслектә, ул — шәйтаннан, һәм әгәр сездән кемнең дә булса иснәсе килсә, ул (иснәвен) булдыра алган кадәр тыеп торсын. Хакыйкатьтә, сезнең берәрегез иснәсә, аннан шәйтан көлә».***

عن أَبِي هرِيرة رضي الله عنه قَالَ: قَالَ النبيّ صلى الله عليه وسلم: «إِذَا عَطَسَ أَحَدُكُمْ فَلْيَقُلْ: الحَمْدُ للهِ وَلْيَقُلْ لَهُ أَخُوهُ أَوْ صَاحِبُهُ: يَرْحَمُكَ الله فإِذَا قَالَ لَهُ: يَرْحَمُكَ اللهُ فَلَيَقُلْ: يَهْدِيكُمُ اللهُ وَيُصْلِحُ بَالَكُمْ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез төчкерсә: «Аллаһ тәгаләгә мактау булсын!» /Әлхәмдүлилләһ/ — дип әйтсен, һәм аның кардәше яки аның юлдашы аңа: «Сине Аллаһ ярлыкасын!» /ЙәрхәмүкАллаһ!/ — дисен. Ә әгәр ул аңа: «Аллаһ сине ярлыкасын!» /ЙәрхәмүкАллаһ!/ — дип әйтсә, (төчкерүче аңа җавап итеп): «Аллаһ сезгә һидәять бирсен һәм барлык эшләрегезне яхшыртсын!» /Йәһдикүмуллаһ үә йуслих бәләкүм!/ — дип әйтсен».***

عن أَبي موسى رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ رسول الله ﷺ يقولُ: «إِذَا عَطَسَ أَحَدُكُمْ فَحَمِدَ اللهَ فَشَمِّتُوهُ فَإِنْ لَمْ يَحْمَدِ اللهَ فَلاَ تُشَمِّتُوهُ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Муса ﵁ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Әгәр дә берәрегез төчкерсә һәм Аллаһны мактаса[26], Аллаһка аның өчен дога кылыгыз[27], әгәр дә төчкерүче Аллаһны мактамаса[28], моны эшләмәгез[29]».***

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رضي الله عنه: «أَنَّ النَّبِيَّ صلى الله عليه وسلم كَانَ إِذَا عَطَسَ غَطَّى وَجْهَهُ بِيَدِهِ أَوْ بِثَوْبِهِ وَغَضَّ بِهَا صَوْتَهُ» [ أخرجه الترمذي، و قَال حَدِيثٌ حَسَنٌ صَحِيحٌ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ төчкергәндә битен кулы белән яки киеме белән каплый иде һәм шуның белән төчкергән тавышын әкренәйтә иде».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Пәйгамбәребез ﷺ бәян итүенчә, төчкерүнең сөннәтләре вә әдәпләре бар. Мөселман кешесе бу әдәпләргә бик тә игътибарлы булып, расүлебезнең безгә калдырган сөннәтенә муафыйкъ гамәлләр кылырга тиеш.

---

26 "Әлхәмдүлилләһ" – дип әйтсә
27 "Йәрхәмүкаллаһ!" – дисен
28 "Әлхәмдүлилләһ" – дип әйтмәсә
29 "Йәрхәмүкаллаһ!" – димәгез

**Файдалар:**

**1)** Кешенең төчкерүе Аллаһка сөйкемле.

**2)** Төчкергәндә битне каплау тиешле.

**3)** Төчкерүче «әлхәмдүлилләһ» — дип әйтмәсә, аңарга «йәрхәмүкАллаһ» — дип җавап бирергә кирәкми.

## Иснәү әдәпләреннән

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رضى الله عنه عَنِ النَّبِىِّ صلى الله عليه وسلم: «إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْعُطَاسَ وَيَكْرَهُ التَّثَاؤُبَ فَإِذَا عَطَسَ فَحَمِدَ اللَّهَ فَحَقٌّ عَلَى كُلِّ مُسْلِمٍ سَمِعَهُ أَنْ يُشَمِّتَهُ وَأَمَّا التَّثَاؤُبُ فَإِنَّمَا هُوَ مِنَ الشَّيْطَانِ فَلْيَرُدَّهُ مَا اسْتَطَاعَ فَإِذَا قَالَ: هَا ضَحِكَ مِنْهُ الشَّيْطَانُ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, Аллаһ төчкерүне ярата һәм иснәүне яратмый. Әгәр дә берәрегез төчкерсә һәм Аллаһ тәгаләгә хәмд-сәнә әйтсә, моны ишеткән һәр мөселман төчкерүчегә: «Сине Аллаһ ярлыкасын!» /ярхәмүкАллаһ!/ — дип әйтергә тиеш. Иснәүгә килгәндә, дөреслектә, ул — шәйтаннан, һәм әгәр сездән кемнең дә булса иснәсе килсә, ул (иснәвен) булдыра алган кадәр тыеп торсын. Әгәр дә ул кеше иснәгәндә «Һаа» — дип әйтсә, аннан шәйтан көлә».***

عن أَبِي سعيد الخدري رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسول الله صلى الله عليه وسلم: «إِذَا تَثَاءَبَ أَحَدُكُمْ فَلْيُمْسِكْ بِيَدِهِ عَلَى فِيهِ فَإِنَّ الشَّيْطَانَ يَدْخُلُ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез иснәсә, кулы белән авызын капласын, хакыйкатьтә, авызын капламаса шәйтан керә».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Иснәү — ялкаулык вә хәлсезлекнең нәтиҗәсе булып тора һәм ул шәйтаннан. Шуңа күрә дә мөселман иснәүдән тыелырга тырышырга тиеш, ә инде тыела алмаса кулы яки киеме белән капларга һәм тавышсыз гына иснәргә тиеш.

**Файдалар:**

**1)** Аллаһ тәгалә иснәүне сөйми, һәм ул ялкаулык вә сәлперәйгәнлек нәтиҗәсе.

**2)** Иснәүдән тыелырга тырышырга кирәк.

**3)** Иснәгәндә кул яки кием белән авызны капларга кирәк.

**4)** Иснәгәндә тавыш чыгарудан читләшергә кирәк.

## 🕮 Ашау әдәпләреннән (1)

عن حُذَيْفَةَ رضي الله عنه قَالَ: كُنَّا إِذَا حَضَرْنَا مَعَ رَسُولِ اللهِ صلى الله عليه وسلم طَعَاماً لَمْ نَضَعْ أَيدِينَا حَتَّى يَبْدَأَ رَسُولُ الله صلى الله عليه وسلم فَيَضَعَ يَدَهُ وَإِنَّا حَضَرْنَا مَعَهُ مَرَّةً طَعَاماً فَجَاءتْ جَارِيَةٌ كَأَنَّهَا تُدْفَعُ فَذَهَبَتْ لِتَضَعَ يَدَهَا فِي الطَّعَام فَأَخَذَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم بِيَدِهَا ثُمَّ جَاءَ أَعْرَابِيّ كَأَنَّمَا يُدْفَعُ فَأَخذ بِيَدِهِ فَقَالَ رَسُولُ اللهِ صلى الله عليه وسلم: «إِنَّ الشَّيْطَانَ يَسْتَحِلُّ الطَّعَامَ أَنْ لا يُذْكَرَ اسمُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِ وَإِنَّهُ جَاءَ بهذِهِ الجارية لِيَسْتَحِلَّ بهَا فأَخَذْتُ بِيَدِهَا، فَجَاءَ بهذا الأعرَابيّ لِيَسْتَحِلَّ بِهِ فَأَخذْتُ بِيَدِهِ والَّذِي نَفْسِي بِيَدِهِ إِنَّ يَدَهُ فِي يَدِي مَعَ يَدَيْهِمَا» ثُمَّ ذَكَرَ اسْمَ اللهِ تَعَالَى وَأَكَلَ [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Хузәйфә ﵁ әйтте: «Безгә пәйгамбәребез ﷺ белән бергә ашарга туры килсә, ул башламыйча без беркайчан да аннан алда беренче булып кулларыбызны сузмый идек. Бервакыт без аның белән бер табында булганда, артыннан кугандай ашыгып бер кыз килеп чыкты, шунда ук ризык янына килеп кулын сузды, ләкин Аллаһның расүле аның кулыннан тотты. Аннан соң шулай ук, кемдер артыннан кугандай, бер сахра кешесе килде һәм пәйгамбәребез ﷺ аның кулыннан

тотып: ***«Дөреслектә, шәйтан үзе өчен Аллаһ тәгаләнең исеме зикер ителмәгән ризыкны хәләл саный һәм ул, бу кыз ярдәмендә үзенә рөхсәт ителгән ризык алу өчен, аны монда китерде, ләкин мин аның кулыннан тоттым. Ә аннан соң ул үзенә ризыкны бу кеше ярдәмендә хәләл кылмакчы булды, ләкин мин аның кулыннан тоттым. Минем җаным Аның кулында булган Зат белән ант итәм! Дөреслектә, мин боларның кулларын тоткан-да, шәйтанның кулы минем кулымда иде!»,*** – диде һәм шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ Аллаһ тәгаләнең исемен әйтеп ашарга тотынды».

عن عائشة رضي الله عنها قالت: قَالَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «إِذَا أَكَلَ أَحَدُكُمْ فَلْيَذْكُرِ اسْمَ اللهِ تَعَالَى فإِنْ نَسِيَ أَنْ يَذْكُرَ اسْمَ اللهِ تَعَالَى في أَوَّلِهِ فَلْيَقُلْ: بسم اللهِ في أَوَّلِهُ وَآخِرِهُ» [ أخرجه أبُو داود والترمذي، وقال: حديث حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһәдән: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ашый башлаганчы сезнең һәркайсыгыз Аллаһ тәгаләнең исемен искә алсын[30], әгәр ул Аллаһ тәгаләнең исемен искә алырга онытса: «Әүвәлдә һәм ахырда Аллаһ исеме белән!» /бисмилләһи фи әүүәлиһи үә әхыйриһи!/ — дип әйтсен».***

عن جابرٍ رضي الله عنه قَالَ: سَمِعْتُ رسول الله ﷺ يقولُ: «إِذَا دَخَلَ الرَّجُلُ بَيْتَهُ فَذَكَرَ اللهَ تَعَالَى عِنْدَ دُخُولِهِ وَعِنْدَ طَعَامِهِ قَالَ الشَّيْطَانُ لأَصْحَابِهِ: لاَ مَبِيتَ لَكُمْ وَلاَ عَشَاءَ وَإِذَا دَخَلَ فَلَمْ يَذْكُرِ اللهَ تَعَالَى عِنْدَ دُخُولِهِ قَالَ الشَّيْطَانُ: أَدْرَكْتُمُ المَبِيتَ وَإِذَا لَمْ يَذْكُرِ اللهَ تَعَالَى عِنْدَ طَعَامِهِ قَالَ: أَدْرَكْتُم المَبِيتَ وَالعَشَاءَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Җәбир ؓ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Кеше үз өенә кергәндә һәм ашаганда Аллаһ тәгаләне зикер итсә[31], шәйтан үзенең иярченнәренә: «Сезгә монда торырга урын да, ашарга ризык та юк!», — дип әйтер. Әгәр ул кеше йортка Аллаһ тәгаләне зикер итмичә керсә, шәйтан: «Сез торырга урын таптыгыз», — дип әйтер. Әгәр ул ашаганда да Аллаһ тәгаләне зикер итмәсә, шәйтан: «Сез торыр урын да, ашарга ризык та таптыгыз!», — дияр».***

30 "Бисмилләһ" – дип әйтсен

31 "Бисмилләһ" – дип әйтсә

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Пәйгамбәребез ﷺ ашау әдәпләрен өйрәтеп, ашый башлаганда Аллаһның исеме белән башларга боерды, чөнки «Бисмилләһ» әйтеп ашый башлау шәйтанны читләштерә, ә кем инде ашый башлаганда «Бисмилләһ» әйтергә онытса, ул инде исенә төшү белән әйтергә тиешле.

**Файдалар:**

**1)** Ашый башлау алдыннан «Бисмилләһ» әйтергә кирәк.

**2)** Кем инде ашар алдыннан «Бисмилләһ» әйтергә онытса, исенә төшү белән әйтергә тиешле.

**3)** «Бисмилләһ» әйтмәгән кеше белән шәйтан йортка кереп яши һәм аның белән ашый, Аллаһ сакласын.

## 🕮 Ашау әдәпләреннән (2)

**Уң кул белән ашау һәм эчү хакында:**

عن ابن عمر رضي الله عنهما أنَّ رسُولَ الله ﷺ قَالَ: «لاَ يَأكُلَنَّ أَحَدُكُمْ بِشِمَالِهِ وَلاَ يَشْرَبَنَّ بِهَا فَإنَّ الشَّيْطَانَ يَأْكُلُ بِشِمَالِهِ وَيَشْرَبُ بِهَا» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Берегез дә сул кулы белән ашамасын һәм сул кулы белән эчмәсен! Дөреслектә, шәйтан сул кулы белән ашый һәм эчә».***

عن عمر بن أَبي سَلمَة رضي الله عنهما قَالَ: كُنْتُ غُلاماً في حِجْرِ رسولِ الله صلى الله عليه وسلم وَكَانَتْ يَدِي تَطِيشُ في الصَّحْفَةِ فَقَالَ لي رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «يَا غُلامُ سَمِّ الله تَعَالَى وَكُلْ بيَمِينِكَ وَكُلْ مِمَّا يَلِيكَ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Гомәр бин Әбү Сәләмә رضي الله عنه әйтте: «Бала чакта мин пәйгамбәребезнең ﷺ тәрбиясендә булдым. Гадәт буенча, мин уртак табакның төрле ягына кулымны суза идем, миңа пәйгамбәребез ﷺ : ***«Әй малай! «Аллаһ исеме белән!»***

***/бисмилләһ/ — дип әйт, уң кулың белән аша һәм сиңа якын булганны аша!»,*** — диде».

عن سلمةَ بن الأَكْوَع رضي الله عنه: «أنَّ رَجُلاً أَكَلَ عِنْدَ رَسُولِ الله صلى الله عليه وسلم بِشِمَالِهِ فَقَالَ: «كُلْ بِيَمِينِكَ» قَالَ: لا أَسْتَطِيعُ قَالَ: «لاَ اسْتَطَعْتَ!» مَا مَنَعَهُ إِلاَّ الكِبْرُ فَمَا رَفَعَهَا إِلَى فِيهِ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Сәләмә бин әл-Әкүәгъ ﷺ әйтте: «Бер кеше пәйгамбәребез ﷺ хозурында сул кулы белән ашый башлады. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Уң кулың белән аша!»,*** — диде. Бу кеше: ***«Мин булдыра алмыйм»,*** — диде. Һәм шунда пәйгамбәребез ﷺ : ***«Әйе, син (моннан соң да) булдыра алмассың!»,*** — диде. Аңа тәкәбберлегеннән башка бернәрсә дә комачауламады, һәм бу кеше чыннан да, уң кулын башка беркайчан да авызына якын китерә алмады».

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Пәйгамбәребез ﷺ уң кул белән ашарга кушты һәм бу хакта үзенең хәдисләрендә бәян итте. Шулай ук расүлебез сул кул белән ашаудан вә эчүдән катгый рәвештә тыйды, чөнки шәйтан сул кул белән ашый вә эчә. Шуңа күрә дә, без үзебезнең балаларыбызны да кечкенәдән үк уң кул белән ашарга өйрәтергә тиешбез.

**Файдалар:**

**1)** Сул кул белән ашарга катгый рәвештә тыела.

**2)** Сул кул белән ашауда шәйтанга охшарга тырышу бар.

**3)** Әгәр дә ризык барчасы да бер төрле булса, үзеңнең яныңнан ашарга кирәк.

## 🕮 Ашау әдәпләреннән (3)

عن كعب بن مالك رضي الله عنه قَالَ: «رأيتُ رسولَ الله صلى الله عليه وسلم يَأكُلُ بثَلاَثِ أصابعَ فإذا فَرَغ لَعِقَهَا» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Кәгъб ﵁ әйтте: ***«Мин расүлебезнең ﷺ өч бармак белән ашаганын һәм ашап бетергәч бармакларын ялап куйганын күрдем».***

عن أنس رضي الله عنه قَالَ: كَانَ رسولُ الله صلي الله عليه وسلم إِذَا أكَلَ طَعاماً لَعِقَ أصَابِعَهُ الثَّلاَثَ وقال: «إذَا سقَطَتْ لُقْمَةُ أحَدِكُمْ فَلْيَأخُذْهَا ولْيُمِطْ عنها الأذى وَلْيَأكُلْهَا وَلاَ يَدَعْها لِلشَّيْطَانِ». وأمَرَنا أن نَسْلُتَ القَصْعَةَ وقال: «إنَّكُمْ لا تَدْرُونَ في أيِّ طَعَامِكُمُ البَرَكَةُ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әнәс ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ ашап туйгач, өч бармагын ялап куя иде һәм: ***«Әгәр сездән берәүнең ризыгының кисәге төшсә, аны алып пакьләсен һәм шәйтанга калдырмыйча ашасын»,*** — диде. Һәм ул безгә тәлинкәне сөртергә әмер итеп: ***«Дөреслектә, сез ризыгыгызның кайсы кисәгендә бәрәкәт булганын белмисез»,*** — диде».

عن معاذِ بن أنسٍ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسولُ اللهِ ﷺ: «مَنْ أكَلَ طَعَاماً فَقال: الحَمْدُ للهِ الَّذِي أطْعَمَنِي هَذَا وَرَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ حَوْلٍ مِنِّي وَلاَ قُوَّةٍ غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ» [ أخرجه أبو داود و ابن ماجه والترمذي، وقال: حديث حسن ]

Мәгънәсе: Мүгаз бин Әнәстән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Берәү ашаганнан соң: «Минем хәлем һәм көчем кулланылмыйча, мине моның белән ашатучы һәм ризыкландыручы Аллаһка мактау булсын!» /әлхәмдү лилләһи әлләзи әтгамәни һәзә үә разаканиһи мин гайри хәүлин минни үә лә куүәһ!/ — дисә, аның алдагы гөнаһлары гафу ителә».***

عن جَابِرِ بن عَبْدِ اللَّهِ رضى الله عنهما يَقُولُ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه و سلم: «إِذَا كَانَ جُنْحُ اللَّيْلِ - أَوْ أَمْسَيْتُمْ - فَكُفُّوا صِبْيَانَكُمْ فَإِنَّ الشَّيَاطِينَ تَنْتَشِرُ حِينَئِذٍ، فَإِذَا ذَهَبَ سَاعَةٌ مِنَ اللَّيْلِ فَحُلُّوهُمْ فَأَغْلِقُوا الأَبْوَابَ وَاذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ فَإِنَّ الشَّيْطَانَ لاَ يَفْتَحُ بَابًا مُغْلَقًا وَأَوْكُوا قِرَبَكُمْ وَاذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ وَخَمِّرُوا آنِيَتَكُمْ وَاذْكُرُوا

اسْمَ اللَّهِ وَلَوْ أَنْ تَعْرُضُوا عَلَيْهَا شَيْئًا وَأَطْفِئُوا مَصَابِيحَكُمْ» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһтан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә кич җитсә, балаларыгызны урамга чыгармыйча үзегезнең яныгызда тотыгыз, чөнки, хакыйкатьтә, бу вакытта шәйтаннар тарала. Ә инде күпмедер билгеле вакыт узгач, балаларыгызны яныгыздан җибәрегез һәм «Бисмилләһ» әйтеп ишекләрегезне ябыгыз, хакыйкатьтә, ябылган ишекләрне шәйтан ача алмый. «Бисмилләһ» әйтеп турсыкларыгызны[32] бәйләгез, «Бисмилләһ» әйтеп савыт-сабаларыгызны каплагыз, капларга бернәрсә дә булмаса, өстенә аркылы берәрнәрсә куегыз һәм кәндилләрегезне[33] сүндерегез!».***

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ ﵁ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ: «إِذَا وَقَعَ الذُّبَابُ فِى إِنَاءِ أَحَدِكُمْ فَلْيَغْمِسْهُ كُلَّهُ ثُمَّ لِيَنْزِعْهُ، فَإِنَّ فِى إِحْدَى جَنَاحَيْهِ دَاءً وَالأُخْرَى شِفَاءً» [ أخرجه البخاري ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегезнең савытына чебен төшсә, әүвәл ул аны тулысы белән батырсын, аннары алып ташласын, чөнки аның бер канатында авыру, ә икенчесендә шифа».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Пәйгамбәребез ﷺ ашау әдәпләрен бәян итеп, кул белән ашаганнан соң бармакларны һәм савытта калган ризыкларны ялап куярга кушты. Пәйгамбәребез ﷺ өч бармак белән ашый торган иде һәм әгәр дә ризыкның берәр кисәге төшсә, аны алып пакьләргә вә ашарга боерды. Шулай ук, әгәр дә ризыкка чебен төшсә, аны ялт алып ташларга кирәкми, ә бәлки тулысы белән батырганнан соң гына алып ташларга кирәк, чөнки аның бер канатында чир булса, икенче канатында дәва.

**Файдалар:**

**1)** Өч бармак белән ашарга тырышырга кирәк.

32 Саба (су, сөт яки кымыз кебек эчемлекләр өчен тире яки күннән тар авызлы кечкенә капчыкка охшатып эшләнгән савыт, урысча "бурдюк" диелә)

33 Берничә шәм куела торган шәмдәл

**2)** Ашап беткәннән соң бармакларны ялап кую тиешле.

**3)** Савытта калган ризыкны сөртеп ашап бетерергә кирәк.

**4)** Төшкән ризыкны ташламыйча, алып ашарга кирәк.

**5)** Савыт-сабадагы ризыкларны шәйтаннан саклау өчен «Бисмилләһ» әйтеп капларга кирәк.

**6)** Ашка яки эчемлеккә чебен төшсә, ул чебенне тулысы белән батырып алып ташларга һәм ризыкны ашарга кирәк.

## Алтын һәм көмеш савыт-сабадан ашарга вә эчәргә ярамаганлыгы хакында

عن حذيفة رضي الله عنه قَالَ: قال النبيُّ ﷺ: «لاَ تَلْبَسُوا الْحَرِيرَ وَلاَ الدِّيبَاجَ وَلاَ تَشْرَبُوا فِى آنِيَةِ الذَّهَبِ وَالْفِضَّةِ وَلاَ تَأْكُلُوا فِى صِحَافِهَا، فَإِنَّهَا لَهُمْ فِى الدُّنْيَا وَلَنَا فِى الآخِرَةِ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Хүзәйфәдән ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ефәк һәм дибәҗ[34] кием кимәгез! Алтын һәм көмеш савытлардан эчмәгез һәм ашамагыз! Дөреслектә, болар бу дөньяда алар өчен[35], ә сезнең өчен — ахирәттә»***.

عن أُمِّ سلمة رضي الله عنها: أَنَّ رسول الله صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَنْ شَرِبَ فِى إِنَاءٍ مِنْ ذَهَبٍ أَوْ فِضَّةٍ فَإِنَّمَا يُجَرْجِرُ فِى بَطْنِهِ نَارًا مِنْ جَهَنَّمَ» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Үммү Сәләмә радый Аллаһу ганһәдән: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем алтын яки көмеш савыттан эчә икән, хакыйкатьтә, аның карынында Җәһәннәм уты шаулар».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Алтын һәм көмеш савытлардан ашау вә эчү шәригатебездә хәрам санала. Кем бу кисәтүдән тыелмый икән, аны каты газап көтә.

---

34 Дибәҗ – нигезендә ефәк булган кыйммәтле тукыманың исеме

35 Ягъни, кәферләр өчен

**Файдалар:**

**1)** Алтын һәм көмеш савытлардан ашау вә эчү — хәрам.

**2)** Бу төрле савытларны кулланучыларны каты газап көтә.

## 🕮 Ата-анага игелек хакында

•وَقَضَى رَبُّكَ أَلا تَعْبُدُوا إلا إيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِنْدَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلاهُمَا فَلا تَقُلْ لَهُمَا أُفٍّ وَلا تَنْهَرْهُمَا وَقُلْ لَهُمَا قَوْلا كَرِيمًا ۞ وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُلْ رَبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا• الإسراء : ٢٣-٢٤

Мәгънәсе: **«Аллаһ сезгә фәкать Аңа гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә боерды. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә вә кычкырма да, бәлки аларга, һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә! Вә аларга шәфкать итеп, рәхимлек канатларыңны җәй! Вә әйт: «Ий, Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә рәхимле бул!».**

•وَوَصَّيْنَا الإنْسَانَ بِوَالِدَيْهِ حُسْنًا• العنكبوت: ٨

Мәгънәсе: **«Без кешегә ата-анасына игелекле булырга боердык».**

عن عبد الله بن مسعود رضي الله عنه قَالَ: سألت النَّبيّ صلى الله عليه وسلم : أيُّ العَمَلِ أحَبُّ إلَى اللهِ تَعَالَى؟ قَالَ: «الصَّلاةُ عَلَى وَقْتِهَا» قُلْتُ: ثُمَّ أي؟ قَالَ: «بِرُّ الوَالِدَيْنِ» قُلْتُ: ثُمَّ أيٌّ؟ قَالَ: «الجِهَادُ في سبيلِ الله» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгуд ﵁ әйтте: «Бервакыт мин пәйгамбәребездән ﷺ: «Аллаһ нинди эшне барысыннан да күбрәк ярата?» — дип сорадым. Ул: ***«Вакытында укылган намаз»,*** — дип җавап бирде. Мин: «Ә аннан соң нәрсә?», — дип сорадым. Ул: ***«Ата-анага игелекле булу»,*** — диде. Мин:

«Ә моннан соң нәрсә?», — дип сорадым. Ул: ***«Аллаһ юлында җиһәд»,*** — диде».

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَال: جاء رجل إِلى رَسُول الله صلى الله عليه وسلم فَقَالَ: يَا رَسُولَ الله مَنْ أَحَقُّ النَّاسِ بِحُسْنِ صَحَابَتِي؟ قَالَ: «أُمُّكَ» قَالَ: ثُمَّ مَنْ؟ قَالَ: «أُمُّكَ» قَالَ: ثُمَّ مَنْ؟ قَالَ: «أُمُّكَ» قَالَ: ثُمَّ مَنْ؟ قَالَ: «أَبُوكَ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ﵁ әйтте: «Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде дә: «Әй расүл Аллаһ! Мин яхшы мөнәсәбәт тотуга кешеләрнең кайсысы лаеклырак?» — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Синең анаң»,*** — диде. (Бу кеше): «Ә аннан соң кем?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Синең анаң»,*** — диде. (Бу кеше): «Ә аннан соң кем?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Синең анаң»,*** — диде. (Бу кеше янә): «Ә аннан соң кем?», — дип сорады, һәм шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Синең атаң»,*** — дип әйтте».

عن أَبي هريرة رضي الله عنه عنِ النَّبيّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «رغِم أنفُ ثُمَّ رَغِمَ أنْفُ ثُمَّ رَغِمَ أنْفُ مَنْ أدْرَكَ أبويهِ عِنْدَ الكِبَرِ أحدهُما أوْ كِليهما فَلَمْ يَدْخُلِ الجَنَّةَ» [ أخرجه مسلم ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Үзенең ата-анасының берсенең яки икесенең дә картлыгын күреп, һәм моннан соң Җәннәткә кермәгән бәндәгә хурлык, хурлык һәм тагын бер тапкыр хурлык[36]!».***

**Аятьләргә вә хәдисләргә кыскача аңлатма:**

Ата-ана хакының зурлыгын бәян итеп Аллаһ тәгалә аны Коръәндә Үзенә гыйбадәт кылу белән янәшә искә алды. Шулай ук ата-анага карата ихсәнле вә игелекле булырга боерды.

**Файдалар:**

**1)** Ата-анага игелекле булырга һәм аларга авыр сүз әйтүдән читләшергә кирәк.

36 Ягъни, картайган ата-анасына тиешенчә игътибар һәм кирәкле ярдәмне күрсәткән өчен Җәннәт булуы, әмма ата-анасына карата үз вазифаларын үтәмәгән кешене хурлык һәм каты җәза көтүе турында әйтелә

**2)** Аларга игелекле булу Аллаһка сөекле гамәлләрдән һәм гөнаһларның ярлыкавына вә Җәннәткә керүгә сәбәп.

**3)** Ананың хакы атага караганда күбрәк.

**4)** Аларга рәхимлек сорап дога кылу тиешле.

**5)** Ата-анасы зур яшькә җитеп, аларга игелекле булмаган кешегә расүлебез хурлык сорап дога кылды.

# Йомгаклау

Әлхәмдүлилләһ, Аллаһның теләге һәм ярдәме илә хәерле вә изге гамәлләр тәмамлана. Пәйгамбәребезгә (ﷺ) вә аның әһле бәйтенә, сахәбәләренә һәм аңа Кыямәткә кадәр ияргән барча мөэминнәргә салават вә сәламнәребез булсын!

Аллаһ Раббыбыз барча кимчелек вә хаталарыбызны ярлыкап, тәүбәләребезне кабул итсен! Һәммәбезне дә файдалы гыйлем, тәкъва, ихласлык вә саф йөрәклелек илә зиннәтләсен!

Хөрмәтле укучылар! Шушында без китабыбызның беренче өлешен тәмамлыйбыз. Бу китаптагы мәсьәләләргә карата кемнәрнең дә булса башка фикерләре бар икән, аларны безгә язма рәвештә җиткерсәгез, без бик тә шатланып кабул итәрбез.

Вә ахыргы сүзебез: «Барча мактаулар галәмнәрнең раббысы Аллаһка!!!».

# Эчтәлек


Кереш сүз.......................................................3

📖 Ихлас һәм ният хакында....................................6

📖 Гыйлемнең фазыйләте хакында.........................9

📖 Кешеләрне изгелеккә өндәүнең фазыйләте хакында.........................................................11

📖 Аллаһ исеме зикер ителмәгән җыеннардан вә утырышлардан саклану хакында...............................13

📖 Телне саклау хакында.......................................15

📖 Пәйгамбәребезгә итагатьлек хакында...........17

📖 Тәүбә һәм аның фазыйләтләре хакында......19

📖 Иманның нигезләре хакында............................20

📖 Тәүхиднең фазыйләте хакында........................23

📖 Ширек һәм аннан саклану хакында...............24

📖 Риядан саклану хакында..................................26

📖 Күз тиюдән һәм башка явызлыклардан саклану өчен төймәләр вә бөтиләр тагуның ярамаганлыгы хакында...........................................................29

📖 Күрәзәчеләргә, сихерчеләргә һәм башка төрле шарлатаннарга баруның хәрамлыгы хакында.........30

📖 Тәвәккәллек хакында.........................................32

📖 Сәламләшү хакында...........................................33

📖 Бәдрәфтә хаҗәтләрне үтәү әдәбеннән.........35

📖 Таһәратнең фазыйләтләре хакында..............37

📖 Намазның фазыйләтләре хакында...............38

📖 Азанның фазыйләтләре хакында.................40

📖 Азан ишеткәндә әйтелә торган сүзләр.........41
📖 Йорттан чыкканда укыла торган догалар.....43
📖 Сәфәр әдәпләреннән (1).................................44
📖 Сәфәр әдәпләреннән (2).................................46
📖 Кәферләргә охшарга ярамаганлык хакында.48
📖 Кыямәт көнендә кеше үзенең яратканы белән бергә була......................................................49
📖 Эт һәм сурәт хакында...................................50
📖 Йокы әдәпләреннән........................................52
📖 Аллаһ ризалыгы өчен бер-береңне ярату хакында.............................................................53
📖 Чакырган җиргә бару хакында......................55
📖 Керергә рөхсәт сорау әдәпләреннән............57
📖 Шәйтанның мөселманнар арасына фетнә салуыннан саклану хакында.................................58
📖 Сабырлык хакында.........................................60
📖 Авырулар һәм чирләр — гөнаһларга ярлыкау.................................................................62
📖 Аллаһтан курку хакында...............................64
📖 Монафикъларның сыйфатлары.....................65
📖 Дуслар һәм иптәшләр сайлау хакында.........67
📖 Ачуны тыю хакында һәм ачуланганда нәрсә әйтергә кирәклеге турында..................................68
📖 Уң тарафның өстенлеге хакында..................70
📖 Каберләрне зиярат кылу хакында.................71
📖 Хәмернең хәрамлыгы хакында.....................73
📖 Бәхәсләрдән читләшү хакында.....................74

Ялган сөйләүнең хәрамлыгы һәм аннан саклану хакында....76
Күркәм холык хакында....79
Оялчанлык хакында....80
Күп көлүдән тыелу хакында....82
Рәхимлек хакында....83
Гайбәтнең хәрамлыгы хакында....85
Кешеләр арасын бозу нияте белән сүз йөртүнең хәрамлыгы хакында....87
Ләгънәт кылудан саклану хакында....88
Җиһәднең фазыйләте....90
Мөҗәһидләрнең һәм шәһидләрнең әҗер-савабы хакында....92
Сахәбәләрнең җиһәд мәйданындагы хәле...95
Төчкерү әдәпләреннән....96
Иснәү әдәпләреннән....98
Ашау әдәпләреннән (1)....99
Ашау әдәпләреннән (2)....101
Ашау әдәпләреннән (3)....103
Алтын һәм көмеш савыт-сабадан ашарга вә эчәргә ярамаганлыгы хакында....105
Ата-анага игелек хакында....106
Йомгаклау....109